Безнен
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
МИРАС
11
ноябрь 2020
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

«И Ходаем, тәңгә сихәт, саулык бир!»

12 бит

Туфан Миңнуллин юксындыра

96 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең мирас

12 +

11 (323)

ноябрь 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.



Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битлә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Җәүдәт Дәрзаман

ТАРИХИ МИРАС

4 Үткән юллар. *Х.Хисмәтуллин*
12 Мирхәйдәр Фәйзи: «И Ходаем, тәнгә сихәт, саулык бир!»
16 Зәй-Каратай: революциягә кадәрге тарих. *Җ.Рәхимов*
24 Олы мирасны барлаганда. *Л.Гайнанова*
26 Галимҗан Ибраһимов һәм «Аң» журналы. *Р.Гайнанов*
30 «Аваз» газетасы. *Р.Шәрәфиева һәм Л.Гобәйдуллин*
34 Мәмәтхуҗаның борынгы ташъязмалары. *И.Һадиев, Р.Мәрданов*
36 Тарихи Чишмә һәм Зәй буйлары. *А.Борһанов*

ТАТАР ГАМЕ

42 Рәгать Хөсәенов: «Лениногорск – минем өчен дөньяда иң яхшы шәһәр!»

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан, Лениногорск муниципаль районы администрациясеннән, Лениногорск туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

48 Бәхет биргән авылым
50 «Хикмәт белән эшләргә кирәк!»

ДИНИ МИРАС

56 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
63 Мәүлид ае – хәзрәти Мөхәммәд(с.г.в.)нең туган аедыр. *Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин*

ӘДӘБИ МИРАС

66 Олуг мәгърифәтчебез Хәсән Хәмидулла. *Х.Миңнегулов*
71 Утыз-Имәни һәм «Госман Коръәне». *Р.Исламов*
76 Әдәби калейдоскоп. *Т.Галиуллин*
81 Үткәннән хатлар

ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

84 Таш батыр турында риваять. *А.Сарманбәтов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
96 Туфан Миңнуллин юксындыра. *И.Вәлиуллина*
102 Истә, һаман да истә!
104 Җәмит Рәхимовның фотомирасы

СӘНГАТИ МИРАС

106 Борынгы татар милли музыка уен кораллары. *Р.Гыйләҗев*
110 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*
112 «Шахта» җыры

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Ноябрь*

Заказ №А-2842. Тираж – 2205 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 02.11.2020. Чыгу көне: 11.11.2020.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: язучы Җәүдәт Дәрзаман кызы Резидә белән. 1989 ел

Орлык булып кайда төшсәк тә без,
Татар булып кабат яралдык.

Җәүдәт Дәрзаман

Җәүдәт Дәрзаман хатыны Тәслимә, кызлары Гөлназ һәм Резидә белән. Гагра, 1984 ел

безнең мирас №11 ноябрь 2020

Җәүдәт Дәрзаман

(13.10.1945-25.02.2019)

Сибелә чәчем

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелә чәчем җилләрдә...
Татар халык җырыннан

Сибелә чәчем, диеп җыр җырладык,
Сибелгәндә чәчләр җилләргә.
Чәчләр түгел, үзебез сибелдек шул,
Чәчелдек шул ерак илләргә.
Сәйлән идек юкса, бәйләм идек,
Ефәк җепне безнең өзделәр,
Өзделәр дә, ялган ташлар кушып,
Үз дигәнчә кабат тезделәр.
Асылташтай газиз безнең башлар
Ни күрсә дә күрде – түзделәр!
Сибелә чәчем, диеп җырлый-җырлый,
Җилдә түгел, җирдәаралдык.
Орлык булып кайда төшсәк тә без,
Татар булып кабат яралдык.
Читтә түгел, хәтта туган илдә
Калганда да кайчак ят булып,
Изге кыйбла безгә терәк булды,
Иман нуры булды яктылык.
Яманлыкны байтак татысак та,
Күңелләрдә булды яхшылык!
Сибелә чәчем, диеп җырлый-җырлый,
Бәлки, тагын өзелү кирәктер?
Болгардан ук килгән ефәк җепкә
Яңабаштан тезелү кирәктер?!
Сибелә икән, әйдә, сибелсеннәр
Көмеш чәчләр җәйге җилләрдә.
Без сибелмик, тезелик дисбе булып,
Туфрак булыйк туган җирләрдә.
Олтан түгел, мәгърур солтан булыйк
Татарстан дигән илләрдә! ■

Хәй Хисмәтуллинның тууына 125 ел

Үткән юллар*

Хәй Хисмәтуллин

Хәй Хисмәтуллин

Хәй Хисмәтуллин (Габделхәй Хисмәтулла улы Хисмәтуллин) (1895-1977), тел галиме буларак, Мөхәммәтхан Фазлуллин белән берлектә «Дөрес язу күнегүләре» (1932), Мөхетдин Корбангалиев белән «Синтаксис» (1938), «Тыныш билгеләре буенча күнегүләр» (1941), Шиһаб Рамазанов белән «Татар теле грамматикасы: фонетика һәм морфология» (1954) исемле китаплар яза.

Текстолог буларак, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Каюм Насыйри, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гомәр Толымбай кебек классик язучыларның әсәрләрен барлый, текстологик яктан әзерләп, томлыкларын укучыларга җиткерүдә күп хезмәт куя.

Әдәбият галиме буларак, «Фатих Әмирхан», «Шиһап Мәрҗани», «Галиәсгар Камал», «Фатих Кәрими» исемле монографик хезмәтләр яза. Закир Һади, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури турындагы беренче фәнни-тикшеренү хезмәтләрен дә ул иҗат итә. «XX гасыр башында татар әдәбияты» (1954), «Татар совет әдәбияты тарихы (очерклар)» (1960), «Борынгы татар әдәбияты» (1963) кебек китапларда фәнни мәкаләләре басыла.

Игътибарыгызга галимнең 1975 елда язган истәлекләрен тәкъдим итәбез.

...Октябрь революциясен мин Казанда каршыладым. Беренче атышкан көн минем кебек өйрәнмәгән кешегә куркыныч булды. Икенче көнне Кабан күле буена чыгып, шәһәр өстеннән снарядлар очканын карап тордык.

Шәһәргә зур зыян килмәде. Кешеләр урамда йөрүдән дә бөтенләй үк туктамадылар. Тик университетның бер колоннасына снаряд эләгеп, яртысын умырып китте.

Октябрьдә власть Советлар кулына күчсә дә, 1917-1918 нче елларда мәктәп-мәдрәсә эше элеккечә калды. Күрәсең, совет органнары әле мәгариф эшләрен үз кулларына тулысынча алып өлгермәделәр – башка эш һәм көрәш күп иде.

---

* Мәкалә «Казан арты» тарих-этнография музее фонды материаллары нигезендә әзерләнде.



Археографлар (сулдан уңга): Хәй Хисмәтуллин, Альберт Фәтхи һәм Сәгыйть Исәнбаев

Совет идарә органнары Казанда мәгариф эшләрен яңабаштан кору эшенә 1918 елның җаендә керештеләр. Татар уку йортларын үзгәртеп кору өчен, шәһәр советы каршында Мөселман мәгариф шогъбәсе төзелде. Урта (ул чакта икенче баскыч) мәктәпләргә укытучылар әзерләү өчен, Казанда 6 айлык курслар ачылды. Мин дә шул курсларга укучы булып кердем. Анда, төрле фәннәр укыту белән бергә, безне русча да җырларга өйрәтәләр иде. Укытучы безне тезеп куя да:

«*Во поле берёзонька стояла,*
Во поле кудрявая стояла;
Люли, люли стояла,
Люли, люли стояла»,

– дип җырлата һәм «стояла» сүзен әйткәндә, авызны ике бармак сыярлык итеп ачарга куша, шуңа без авызга ике бармак тыгып җырлый идек.

Дөресен әйтим, бәлки, минем наданлыктыр, үзем авызны алай зур ачып җырлауны әле дә яратмыйм, Тукай әйтмешли, иреннәрне кәгазь сыярлык итеп җырлау миңа күбрәк ошый.

Курста укыган чакта, мин, ни сәбәптәндер, авылга кайтып киттем. Шул чакта Казанга чехлар кергәннәр.

Казан чехлар кулында булса да, аларның властьлары төньякка таба 10 чакрым ераклыктагы Киндерле авылыннан уза алмады. Ул чакта Арчада берничә волостьны берләштергән район мәгариф бүлеге бар иде. Бу бүлекнең җитәкчесе – өлкән буын большевик Анатолий Машкин, мәктәптән тыш мәгариф эшләренең җитәкчесе партиясез педагог Николай Смолин иде. Болар һәр икесе гаҗәп культуралы гуманистлар булып хәтердә калган. Мин чехлар вакытында Казанга бармадым, шул мәгариф бүлеге җитәкчелегендә авылларда совет мәгарифе урнаштыру, совет мәктәпләре, көтепханәләре оештыру эшләре белән шөгыльләндем. Нәкъ шул чакта мәктәпләрне челтәргә кертү дигән бер термин (школьная сеть) туды. Моны әле авыл кешесе белми. Беркөнне авылда

Хәй Хисмәтуллин хатыны Маһруйбикә һәм кызы Ләйлә белән. 1932 ел

кичке сәгать 9да йокларга ятарга әзерләнгәндә, ике кеше менеп, мине җыенга чакырдылар. Бардым. Халык шау килә. Алар мәктәпне челтәргә кертүне зур челтәр әзерләп, шуның белән мәктәпне каплап кую дип аңлаганнар һәм бу күренеш аларның акылларына сыймаган. Аңлаткач, тиз төшенделәр. Шул чакта ике мәктәп – берсе ир балалар, берсе кыз балалар өчен ачарга булдылар. Шул елның көзендә мин Яңа Кенәр авылында беренче тапкыр (бөтен волостька) көтепханә ачтым. Бу көтепханә «волость көтепханәсе» дип атала иде. Әлеге Арчадагы мәгариф бүлеге мине көтепханә эшчеләре әзерләү курсларына җибәрде. Шулай итеп мин мәктәптән тыш мәгариф эшчесе булып киттем.

«

Бу чакта Казанда тормыш авыр, ашау-эчү бик кысынкы булды. Икмәкне һәртөрле орлык – арыш, бодай, солы, арпа, тагын, белмим, нинди орлыклар кушып тарткан оннан пешерәләр, икмәк кибәкле, күкле-яшелле төстә була.

1919 елда укый-яза белмәүне бетерү турында хөкүмәт декреты чыкты. Шул уңай белән ликбез пунктлары ачылды. Мин инде бу чакта волостьта мәктәп һәм мәктәптән тыш эшләр буенча мәгариф инструкторы идем. Ликбез мәктәпләре оештыруда актив катнаштым.

1919 елның көзендә мине мәктәптән тыш мәгариф эшчеләре әзерләү курсларына Казанга җибәрделәр. Бу чакта Казанда тормыш авыр, ашау-эчү бик кысынкы булды. Икмәкне һәртөрле орлык – арыш, бодай, солы, арпа, тагын, белмим, нинди орлыклар кушып тарткан оннан пешерәләр, икмәк кибәкле, күкле-яшелле төстә була. Безгә столовойда ашарга 10 тиенгә талон бирәләр. Кашыкны, тозны да үзең белән алып барасың, чөнки аш тозсыз пешерелә. Икенчесенә – солы ярмасыннан пешкән ботка. Солы ярмасын кибәктән әрчү өчен, тегермәндә

ике кат әйләндереп чыгарырга кирәк. Ә безнең ботканың ярмасы бер генә кат әйләндерелгән, шуңа күрә яртысы кибәк. Һәркем ботканы авызына алып чәйни дә кибәген чыгарып өстәлгә өя, ашаучыларның алдында кечкенә генә солы кибәге өеме кала. Мәктәптән тыш мәгариф эшчеләре курсларында без шулай укыдык. Шул чакта мин, беренче тапкыр кулга каләм алып, «Эш» газетасына «Мәктәптән тыш мәгариф эшләре» исемле мәкаләләр бирдем. Мәкаләләр «Укытучы» имзасы белән басылып чыктылар. Курслардан соң Халык мәгарифе институтына укырга кердем. Әмма тәртипле укып булмады. Сәбәбе һаман шул тормыш кыенлыклары иде. Ул чакта институтларда лекцияләргә йөрү мәҗбүри түгел, укыган өчен акча да (стипендия) бирмиләр. Шулай да мин, читтән торып укучы рәвешендә I курсны тәгәлләп, II курска күчтем, шуннан артык барып булмады. Тагын Яңа Кенәргә кайттым. Мәктәп һәм мәктәптән тыш мәгариф эшләре буенча волость инструкторы итеп билгеләндем.

Шул чакларда без Яңа Кенәрдә беренче сәхнә оештырдык. Ул болай булды: Яңа Кенәр волость идарәсе өчен салынган йортның яртысы олы писарьга квартирага бирелгән иде. Олы писарь, күптән урыныннан төшерелгән булса да, һаман шунда тора иде. Без беркөнне аны квартирасыннан чыгардык та балтапычкы белән кирәкмәгән бүлемнәрен кистек, сәхнә ясадык. Арча мәгариф бүлегеннән чаршаулык, төрле буяулар (грим өчен) алып кайттык, менә дигән сәхнә килеп чыкты. Шунда Шамил Усмановның «Канлы көннәрдә», «Беренче адым», Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесаларын куйдык. Халык театрга күп йөрде, артистлар – укытучылар, авыл егетләре исә катнашмыйлар иде.

Нил Юзеев, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты:

«Хәй ага автор буларак катнашкан «Синтаксис» дәреслегенең – 23 тапкыр, «Морфология» дәреслегенең 22 тапкыр басылуын искә алу да күп нәрсә турында сөйли. Хәй ага озак еллар дәвамында әдәбият дәреслекләре язу, хрестоматияләр төзү, башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен программалар, методик кулланмалар төзүдә актив катнашып килә».

Нур Гыйззәтуллин, әдәбият галиме:

«Татар әдәбиятының берничә йөз еллык бай тарихын яхшы белүе, гарәп, фарсы, төрек телләрендәге китапларны иркен укый алуы аңа Шиһап Мәрҗанинең сайланма хезмәтләрен, татар әдәбиятының борынгы язма истәлекләре булган «Дастаны Бабахан», «Нәһҗел-фәрадис» кебек әсәрләрне матбугатта бастырып чыгару өчен хәзерләүгә нык ярдәм итте».

Шакир Абилов, әдәбият галиме, профессор:

«Ул Габдулла Тукайның ялкынлы сүзләрен тыңлаган, кичләрендә авыру Фатих Әмирхан янында утырган, Мәҗит Гафури белән чәй эчкән, Г.Ибраһимовның фатихасын алган, ярсу йөрәкле Г.Кутуй белән бергә эшләгән, Ш.Мөдәрриснең беренче шигырьләренә юл күрсәткән...»



Хәй Хисмәтуллинның басылып чыккан кайбер китаплары

Яңа Кенәр (Мәмсә) волосте ничектер өч волостьны (Яңа Кишет, Олы Мәңгәр һәм Мәмсә) берләштерә. Өч волость укытучылары айга бер тапкыр Яңа Кенәргә киләләр, Сәмигулла бай йортында җыелыш була иде. Ул чакта әле мөгаллим һәм мөгаллимәләр аерым утыралар, алар арасы ширма белән бүленгән була иде. Без беркөнне шул җыелыш алдыннан әлеге ширманы алып куйдык. Өй ике ишекле иде. Бер ишектән – мөгаллимнәр, берсеннән мөгаллимәләр керәләр. Без ширманы алып куйган көнне мөгаллимә туташларыбыз үз ишекләреннән керәләр дә, ширма юклыгын күргәч, аптырап: «Бәлеш!» – диләр дә урыннарына барып утыралар. Шуның белән мөгаллимәләрнең бездән йөз яшерү мәсьәләсе чишелде, ширма яңадан куелмады.

Кенәр – дүрт мәчетле зур авыл. Дүрт мәчеткә дүрт мәктәп. Нормаль булмаган бу хәлне бетерү өчен, без зур гына итеп салынган почта бинасын мәктәпкә алдык. Почтаны каядыр күчерттек. Сугыш, ачлык еллары нәтиҗәсендә, ятим калып соранып йөрүче балалар күп, шуларны тәэмин итү өчен, бер байның йортын алып, балалар йорты оештырдык. Балалар бакчасы да төзелде. Гомумән, Мәмсә волостенда өч урында балалар йортлары ачылды. Кантон мәгариф бүлеге кушуы буенча, һәрбер балалар йортына 50шәр бала, шуларны карау, ашату кебек эшләр өчен 5әр кеше бирелә иде. Бу балалар йортларында тәрбия эшләрен алып баручылар да – укытучылар. Гомумән, бу елларда укытучылар, эшләгән өчен акча-фәлән бөтенләй диярлек түләнмәсә дә, зур дәрт һәм энтузиазм белән эшләделәр, һичбер авырлыктан курыкмадылар, читенсенмәделәр. Моның сәбәбе нәрсә? Сәбәбе ирексезлектән, ябылып ятудан туйган яшьләргә революция биргән ирек иде. Бу хәл бер бездә генә түгел, барлык волостьларда шулай баргандыр, шуның белән авылларда советчылык идеясе таралуга, иске, йомык тормышның әкренләп бетә баруына юл сызылды.

Әгәр материаль тормыш кыенлыкларын исәпкә алмасаң, Кенәрдә тормыш күңелле иде. Мәгариф эшчеләре коллективы зур, үзара дус яши идек, халык

Хәй Хисмәтуллинның вафатына бер ел кала төшкән фотосурәте

арасында да авторитет югары, үзебез кирәк тапкан чараларны үткәрә ала идек. Танцы түгәрәге оештырдык. Үзара җыелышып, арыш онынннан чумар пешереп булса да, бергәләп күңелле итеп утырыша идек. Яшь чаклар!

...Арчада укытучыларның профсоюз җитәкчесе булып эшләгән чакта, без укытучыларның политик әзерлекләрен дә тикшереп йөрдек. Бу яктан эшләр шәп түгел иде. Мәсәлән, бер авыл укытучысыннан СССРда дәүләт идарәсе системасын сораган идек, җавап бирә алмый аптырап калды. Аннары сүзне кантонга күчердек, кантонда властьның кем, нинди учреждение кулында булуын сорадык. Ул, уйлап торды да: «Ибраһим абзый Якупов кулында булырга кирәк», – дип җавап бирде. Моның хикмәте шунда иде: Ибраһим Якупов – элекке учитель, бу чакта кино мөдире урынбасары. Ул элек-электән дисциплинага өйрәнгән кеше. Арчада дүшәмбе көн базар була, шунда базарга килгән укытучыларны: «Ник мәктәбегезне ташлап йөрисез?!» – дип куа иде. Шуннан безнең әлеге укытучыбыз да куркып калган һәм Арчада власть шул Ибраһим Якупов кулындадыр дип уйлаган. Тикшерү вакытында мондый кызыклар аз булмады, әмма алыштырырга мөмкин түгел, кадрлар юк. Аеруча кыенлык мәктәптән тыш мәгариф эшчеләре – көтепханәчеләр, избачлар, клуб мөдирләре тирәсендә туа иде. Бу группа эшчеләрнең белем дәрәҗәләре аеруча түбән, шуңа күрә алар бик еш алыштырылалар, ә профсоюз әлеге мәсьәләгә катнашмый кала алмый.

Арчада эшләгәндә, күптөрле конференцияләр, съездлар, җыелышлар үткәрелде. Шулар арасында иң зур әзерлек белән үткәне кантондагы барлык укытучыларның съезды булды. Бу съезд, партия Үзәк Комитеты карары нигезендә, чакырылачак Беренче бөтенсоюз укытучылар съездына делегат сайлау өчен, 1924 елның кышында җыелды.

1925 елның 1 апрелендә мине Казанга күчерделәр. Мин – Казанда татар балалар шәһәрчегендә укыту-тәрбия бүлеге мөдире, Арча кыры районында мәгариф эшчеләре месткомы председателе, Өлкә мәгариф эшчеләре союзы правлениесе члены, татар телен гамәлгә кую (РТЯ) курсларында укытучы булдым. 1926 елда Бөтенсоюз мәгариф эшчеләре съездында катнаштым. Съездда Луначарский, Украина мәгариф комиссары Рьяппо, Татарстан мәгариф комиссары Ш.Әхмәдиев иптәшләрнең докладлары

«

Әгәр материаль тормыш кыенлыкларын исәпкә алмасаң, Кенәрдә тормыш күңелле иде. Мәгариф эшчеләре коллективы зур, үзара дус яши идек, халык арасында да авторитет югары, үзебез кирәк тапкан чараларны үткәрә ала идек.

булды. Без Шәһид Әхмәдиев белән бергә бер кунакханәдә яшәдек. Шәһид Әхмәдиев гаҗәп ягымлы, гади, югары культуралы кеше иде.

Казанга килеп урнашкач, миңа Казанның галимнәре, укымышлылары, театрлары белән якыннан танышу, әдәбият дөньясына якынаю өчен киң юл ачылды. Казанга килеп урнашуның беренче елында ук РТЯ курсларының укыту бүлеге мөдире, яхшы педагог һәм организатор Фазылҗан Хәмидуллин (хәзер пенсионер) һәм башка укытучылар, ул чакта Мәгариф эшчеләре өлкә союзының культура бүлеге мөдире, гаҗәп ягымлы һәм культуралы иптәш Удалов һ.б. белән якыннан аралаштым. Казанда башланып та, өзелеп калган язу эшләре дә әкренләп кузгала башлады. «Безнең юл» журналында – бер хикәя, соңрак «Мәгариф» журналында мәкаләләр чыга башлады. 1925-1926 нчы елларда инде татар язуын латин нигезендәге яңалифкә күчерү турында көчле бәхәс кузгалган иде. «Яңалиф» җәмгыяте төзелде, «Яңалиф» исемле журнал чыга башлады. Мин дә шул яңалифләшү хәрәкәтенә актив катнашып киттем.

Укыту эшләрен яңалифкә иң элек күчерүче безнең 18 нче мәктәп булды. Моның кайбер объектив җиңеллеге шул: аның укучыларының зур күпчелеге татар балалар шәһәрчегеннән булганга, ата-аналар арасында бу мәсьәлә буенча барган бәхәс балаларга тәэсир итми, алар барысы да безнең карауда иделәр.

18 нче мәктәп тәҗрибәсен популярлаштыру йөзеннән, Наркомпрос миңа авыл мәктәпләре өчен бер табак методик хат язарга кушты. Хат, брошюра булып басылып, мәктәпләргә таратылды. 1928-1929 нчы уку елы өчен без, педагог Шакир Нигъмәтуллин белән бергә, яңалиф хәрефләре белән басылган тел дәреслекләре чыгардык. Гаяз Байкиевның «Обществоведение» буенча V сыйныфлар өчен төзегән дәреслеген дә мин яңалифкә күчереп бастырдым. 1932 елда профессор М.Фазлуллин белән бергә яңалифне олы яшьтәге кешеләргә өйрәтү өчен дәреслек-кулланма төзедек.

> «
> **1925-1926 нчы елларда инде татар язуын латин нигезендәге яңалифкә күчерү турында көчле бәхәс кузгалган иде. «Яңалиф» җәмгыяте төзелде, «Яңалиф» исемле журнал чыга башлады.**

1929 елның көзендә мин, 18 нче мәктәптән китеп, рабфакка күчтем. Шул керүдән 10 ел (рабфак ябылганчы) укыттым. Рабфакны әле дә бик сагынам. Андагы үзләре теләп укырга килгән эшче-крестьян яшьләре белән эшләү сагындыра. Хәзер инде олы яшьтәге кешеләр, хәтта пенсионерлар минем белән: «Мин – Сезнең шәкертегез!» – дип килеп күрешәләр, ә мин шатмын.

1929 елны Наркомпрос мине пединститутка белем күтәрү өчен җибәрде. Тел-әдәбият дөньясына нык-лап кереп китүем әнә шул елдан башланды. Пединститутта мин әдәбият һәм тел галимнәре – Габдрахман Сәгъди, Галимҗан Нигъмәти, Гали Рәхим, Җамал Вәлиди, Галимҗан Шәрәф, Гомәр Толымбай, шулар аркылы Сәлах Атнагулов, Фатих Сәйфи, Гомәр Гали һ.б. белән таныштым.

Габдрахман Сәгъди әдәбият дөньясына күптән, 1908 нче еллардан ук килгән кеше. Аның белеме нигезендә Көнчыгыш (фарсы, гарәп, төрек) әдәбиятчылары концепциясе ята. Ләкин без укыган чакта ул аны рус һәм көнбатыш әдәбият белеме белән тулыландырган иде. Үзенең әдәби-тарихи-политик карашларында Галимҗан Ибраһимовка нык таяна иде.

Хәй Хисмәтуллинның оныгы, РФАнең Механика һәм машина төзелеше институты галимәсе, физика-математика фәннәре кандидаты Наилә Хисмәтуллина (уртада) бабасының туган нигезенә кайткач. Арча районының Кысна авылы. 2015 ел

Габдрахман Сәгъди үзен эре тота, ә Галимҗан Нигъмәти гади, садә кеше. Без соңрак, 1932-1933 нче елларда аның белән бергәләп әдәбият тарихы да яза башлаган идек. Мин Закир Һади, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури хакында язган идем. М.Гафури турында язганым Мәҗит аганың 1932 елда чыккан сайланма әсәрләре өчен сүз башында файдаланылды. З.Һади турында язганым югалды, С.Рәмиев турында язылганын институт архивына тапшырдым. Без моны ник төгәлли алмадык? Белмим.

Пединститутта фольклорны безгә Гали Рәхим укыта иде. Бераз чатанлап йөрүче, ләкин гаҗәп пөхтә киенә торган бу укытучы фольклор материалын җыюга зур әһәмият бирә, һәр лекциясендә укучыларга кәгазьләр өләшә һәм үзләре белгән җыр, бәет, мәкаль һ.б. язып килүне үтенә иде. Институтта укытканда, ул илнең төрле почмагыннан килгән укучылардан күп кенә материал туплады.

Фәнни грамматиканы без Җамал Вәлидидән укыдык. Җамал Вәлиди – 1908 нче еллар тирәсендә матбугат дөньясына килгән кеше. Ул күп еллар «Вакыт» газетасы редакциясендә эшләде. 1917 елның октябрендә (Ф.Кәрими «Вакыт»тан киткәч) аның җаваплы редакторы булды, Оренбургта Халык мәгарифе институты ачылгач (1919 елдан соң), шунда укытты, аннан Казанга килде. Җамал Вәлиди – Тукайның беренче биографы һәм аның әсәрләренең шактый тулы җыентыгын беренче чыгаручы (1914 елда), 1913-1914 елда Г.Тукайны «халык шагыйре» дип бәяләүче өч кешенең берсе (калган икесе – Фатих Әмирхан белән Фатих Кәрими). Җ.Вәлиди тел галиме генә түгел, аның әдәбиятка бәйләнешле хезмәтләре дә шактый.

Фонетика буенча лекцияләрне мәшһүр тюрколог, профессор Богородицкийның шәкерте Галимҗан Шәрәф укый иде. Шулай итеп бу елларда пединституттагы тел-әдәбият кафедрасы тирәсенә татарның иң танылган кешеләре тупландылар, без шулардан дәрес алдык. ■

Мирхәйдәр Фәйзи: «И Ходаем, тәнгә сихәт, саулык бир!»*

Мирхәйдәр Фәйзи



М.Фәйзи. «Урал суы буенда». Пьеса

Уфа, 1923, март

2сендә доктор Татариновка барып күрендем. «Нервныйлык, кан азлык», – ди. «Үпкәң дә бик сау түгел», – ди. Чахотка түгел дип ышандыра. Незнай инде. Бу күкрәкнең авыртып торуы эчне бик пошырды. Нервалар бозылганга нигә күкрәк авырта икән соң?..

Акча да бетте. Дару алырга да акча юк. Гади расходка акча җиткерә алмый аксап калганда, бу даруы белән докторына кайдан табарга кирәк инде… Ансат түгел дөнья көтү.

3есендә Казанда чыккан «Кызыл Шәрык яшьләре»н сатып алдым. Минем «Табигать серләре»м басылган. Бик нәфис, бай, матур итеп чыгаралар журналларын. Маладис!

Кич Ислам белән театрга бардык. «Керәшен» куелды. Зөбәйдә туташ, Мәрфуга ханым, Кушай, Габдрахмановлар белән йөрдем. Сәхнә артында күз һәм күңелем

---

* Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – ***Ред.***

кәгъбәләре тирәсендә дәверан сөрдем. Партшкола шәкерте Йосыф Фәйзуллинның күзге каршында торганын күреп: «Бик матурсың!» – дип көлгән идем, «Безгә матурлык кайда инде», – ди. «Яшьлек – үзе матурлык!» – дидем.

5есендә Мөхәммәтгали Дашкин үлеп калган. Бу һәйбәт, матур, белемле, үземә ярдәмнәре тигән егетне бик кызгандым. Порок сердца авыруына нервный расстройствомы кушылып, егетне һәлак иткәннәр. Мин дә шул ук авыруларга мөбталя *(дучар)* бит. Шулай үлеп китә күрмим дип куркып, мөмкин кадәр сакланырга карар бирдем. Үлә күрмим, яшәп маташыйм әле.

6сында язуымны туктаттым. Бераз ял итеп карарга уйладым. Гел күкрәк авыртып борчый бит, нәгълләт. Ашау ягын да тәрбиялерәк итәсе иде дә, акча юк.

7сендә «Урал суы буенда»мны Академцентрга кертеп, Сәгыйть Сүнчәләйгә калдырдым. Д.Юлтыйга укып китәргә кушты. Алар үткәрсә, Башкнигага тагы бер теләнеп карарга тормышым мәҗбүр итә.

Кич театрга бардык. «Бәхет эзләүчеләр» белән «Артист» куелды. Касыйм Хәбиров белән күбрәк йөрдем.

8ендә. Саулык юграк, малай. Теләгәнчә тәрбияләнергә акчасызлык ирек бирми, чукынган. Чынлап та, күмәчкә дә акчам калмый бара. Килер урыны күренми. Ничек була соң инде ул? Саулыкны саклап каласы иде бит.

Кич Нәсимә апайларга бардым. Габдрахман, Муса, Касыймнар, Гайшә һәм Фатыйма ханымнар да булды. Зыя карточкалар күрсәтте. Озак утырдым. Белен белән чәй эчтек. Бигрәк тә шикәр белән коенган балан бәлеше ашау миңа зур бәхет булды. Бу тәмле ашны күп еллардан бирле ашау тигәне юк иде. Бик тәмле, бик күңелле булды. Нәсимә апайдан мендәр-юрганнар алып кайтып рәхәтләндем.

9ында. Нервалар яхшы ук какшаган. Төнлә төш белән гаҗиз булып беттем. Үлгән-үлмәгән, туган-тумаганнарның бөтенесе белән чуалып, йокым саф йокы – истирахәт булып чыкмый. Яхшы ук җитди истирахәткә мохтаҗлык бар. Савыгу насыйп булсын!

10ысында. Акча җиткерә алмый гаҗиз булдым. Ахыры иске тунымны сүтеп чыгарып, 65 миллионга сатып җибәрдем. Яңасын таласалар дип саклап карасам да, булмады инде. Аптекка йөгереп, даруымны алдым. 19 миллион гына тора, малай! Әйдә, шифасы булсын инде!

15ендә. Башкнига пьесамны бастырырга булган. Бүген барып договор языштым. Алты ай эчендә бастыра, бер миллиард сум гонорарның яртысын хәзер, яртысын бер айдан бирә. Шулай килештек. 500 миллион сум алып чыктым. Саулыкта хәерен күрү насыйп, куанычлы табыш булсын! «Галиябану»дан соң язылган «Урал суы буенда»мның сатылышы да аның белән рәттән килде. Басылып чыгуын саулыкта күрим инде!

Бу турыда Мирсәет Сафинның зур ярдәме тиде. Акчам беткән генә иде, аның булышлыгы белән акча җалганып китте, шөкер!

19ында Тәүфикъ белән урамнарда йөреп, язгы ягымлы җиңел хәбәрләр сөйләшеп, аннан Художественный музейга кердек. Уфаның иң матур йортындагы

бу музей, чынлап та, художественный, анда матур, сөйкемле, нәфис әйберләр күп, күңелле. Бер сәгатьтәй йөреп, өстән генә карап чыктык. Күз матурлыкларга ярлырак калган чакларда анда кереп бәйрәм итеп чыгарга ярый.

20сендә. *К*үз ачкысыз буран. Ел да шулай озак микән бу Уфаның кышы? Моннан нәкъ өч ел элек бу көндә Юлыкта Самат туен үткәреп, кияү егете булып йөридер идек. Их, күңелле чаклар иде!

Авыруым хакында бер, чахоткадыр, дип кисәтеп бетә язам, бер, түгелдер, дип җуанам. Доктор тыныч булырга куша. Шулай булгач, ничек тынычланырга кирәк инде?.. Какырыкка анализ ясатып, түгеллеген белсәм, тынычланыр идем дә, бәлки, ә признать итсәләр?.. Менә бәла, билләһи. Үзем көннән-көн ябыгам. Күкрәгем тирәли нык кына авырта, йөткерәм, төш белән интегәм, кулларым оеп калгалый. Кайчагында кабыргаларым, сөяк авырткан төсле була. Савыга күрим инде берүк.

И Ходаем, кулъяулык бир! Аякка чолгаулык бир!

Долой, кулъяулык, чолгаулык – тәнгә сихәт, саулык бир!

Кич доктор Татариновка бардым. «Чахотка түгел, анализ да кирәкми», – дип кисәтте. Кан азлыктан укол ясатырга кушып, рецепт бирде. Рухланып чыктым.

21ендә укол ясатырга марҗа эзләп йөрдем. Якыннан гына табып, айга 100 миллионга килештем.

22сендә базардан май, күкәй, какао, шикәр, ит, кәрәсин, шырпылар алдым. Утын да алдым. Әйткәндәй, кичә рәсем алдырдым бит әле. Ямьсез чыккан ла утырышым. Фельдшерицама барып, тәүге уколны кадаттым. Хәерле, шифалы эш булсын! Марҗам бик игътибар белән карады, күп киңәшләр бирде. «Үпкәң бөтенләй үк сау да түгел, чахотка булмасын өчен сакланырга кирәк», – ди.

Тәүфикъ, Әдһәмнәр белән кар атышып уйнадык. Һавада күп кенә йөрүне ихтыяр иттем. Кич Габбасовларга бардым. Риза да анда иде. Мәгариф комиссары Габдулла Әдһәмов, Җәмилә ханымнар да анда. Бергә чәй эчтек. Хәмит кайтармады. Риза да, мин дә аларда кундык. Йомшак урыннарда эреп йокладым. Теге төшләр дә күп җөдәтмәде.

24ендә, тәвәккәлләп, туберкулезга хас диспансерга бардым. Элек номер алып бер бүлмәгә кереп чират көттем. Гел йөткерә торган ябык кешеләр утыра. Сәгыйть Рәмиев тә шуңа эләгеп калган икән. Доктор признать иткән. Көчле йөткерә, нык ябыккан. Гел бергә утырып, сөйләштек. «Бәхетсез кәсепкә тотынганбыз, толчокчы буласы гына калган икән», – ди.

Номер буенча бер бүлмәгә чакырып, градусник куйдылар. Аннан энәсеннән җебенә кадәр тикшереп, ата-баба, нәсел-нәсәпнең тормышын, кәсебен,ниләр белән авырганнарын язып алдылар. Ыстанга мендереп, буйны үлчәделәр, гергә утыртып, авырлыкны үлчәделәр. Аннан соң, теге залга чыгып, докторга чират көттек. Доктор шушы авыруда мәшһүр специалист икән. Бик сөйкемле, йомшак сүзле, ак чәчле урыс. Бик җентекләп йөткертеп-төчкертеп, гимнастикалар ясатып, ялангачландырып карап, Татаринов сүзен тасдыйк итте *(раслады)*. Туберкулез-чахотка юк, диде. Уф, дип, тын алып җибәрдем. Куанып чыктым. Инде чахотка түгеллегенә канәгатьләнергә мөмкин табып, рухландым. Башка авыруларым да серьезный булса да, чахотка тагы да куркыта шул, каһәр. Хәерле сәламәтләнүләр насыйп булсын!

Уколга барып чыктым. Марҗа диспансер нәтиҗәсе белән миннән болайрак куанды. Мин дә аңа киңәше өчен рәхмәт укыдым.

Элеккеге Зур Казан, хәзерге Октябрь революциясе урамы. Уфа

Урамда язгы җылы, кояшлы һавада күп кенә йөрдем. Тәгътыйль *(каникул)* вакыты булганга, Тәүфикъ та безгә еш керә. Аның белән уйнап, шаярып бетәбез. Ул бик җанлы, дәртле бер малай, дуңгыз. (Үзенә, дуңгыз, дисәң, бик майлап торып сүгенә дә ул.)

Кич партклубка партшкола куйган спектакльгә бардым.

Уфа, 1923, апрель

5есендә обком-рескомга бардым. Кушай, Г.Габдрахманов, Д.Юлтый, Әхмәт Хәбиби, Әсгать Айдаровларны күрдем. Әллә нинди, дингә каршы язмалар сорыйлар, комсомол гаиденә бер антирелигиозный пьеса язып бирергә кушалар. Нык бәйләнеп калдылар. Ай, сау булып, җимерттереп эшләсәң икән!

7сендә кич Сафин белән «Тукайны тану» кичәсенә, рабфакка бардык. Бу журналистлар, шагыйрь-әдипләр, укучылар тарафыннан ясалды. Рабфакның залы, сәхнәсе бик матур, кеше күп, күңелле. Беренче бүлемдә Газыйм Касыйм доклады булды. Ул Тукайны пролетариат шагыйре булырга үрләүче итеп чыгарды. Исмәгыйль Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нурәгъзам Таһирлар чын пролетариат шагыйре дип дәгъва итеп, Хөсни Кәриев – аумакай, юлсыз бер шагыйрь иде дип, Камал Фәхретдинов – халык шагыйре, Муса Йосыпов чыкырдап торган милләтче, динче дип нәтиҗә чыгардылар. Тукайны шагыйрьлектә Сәгыйть Рәмиевтән ким санап йөргән мин, идеология ягыннан да аның аумака *(ягъни бер идеологиядән)* ерак булуын, могтәдилрәк *(уртача)* юл белән фәкать халык шагыйре исеменә генә лаек бер зат кебек хис итәм.

Концерт бүлемендә «Ысул кадимче»не һич репетициясез чыгып сөйләдем. Әлбәттә, бик яхшы булмагандыр. «Шәп икәнсең» дип, купа итүчеләргә *(ягъни купайтучыларга, арттырып әйтүчеләргә)* очрадым һәм Муса Йосыпов та кулымны кысып торып рәхмәт әйтте, һәйбәт сөйләдең, диде. Номерлар күңелле генә барды.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Зәй-Каратай: революциягә кадәрге тарих

Җәмит Рәхимов

Туйкиннарның әниләре Гайшә Фәхри кызы уллары Кәбирнең (уң якта) һәм Фазылның гаиләләре (сул якта) белән. Бөгелмә, 1928 ел

Зәй-Каратай турындагы һәр истәлек, риваять һәм легендалар кешеләр күңелендә кадерләп саклана бирәдә. Ул гына да түгел, авылның язма тарихы да булдырылган. Зәй-Каратайның беренче совет укытучысы, аның бәрәкәтле җирендә гасырга якын гомер иткән могтабәр шәхесе Ибраһим ага Туйкин үз күз алдында булган хәлләрне теркәп барган, ил агаларыннан сорашып, авылның үткәне турында язып калдырган.

Авылга кайчан нигез салынган?

Сүз дә юк, Ибраһим ага Туйкин язмаларында үзе яшәгән чорны, XIX гасыр азагын һәм XX гасырның беренче яртысын гадел һәм дөрес яктырткан. Әлеге язмаларда мине шаккатырганы – Ибраһим аганың авылның нигезләнүе хакында дөреслеккә бик якын торган датаны күрсәтүе булды. Ул Зәй-Каратайның нигезләнү

чоры итеп XVIII гасыр башын күрсәтә. Бу исә минем, әлеге язмаларны күргәнче үк, Мәскәү архивында эшләгәндә килгән нәтиҗәмә бик якын. Хикмәт шунда ки, Минзәлә волостенда 1723 елда үткәрелгән Беренче ревизиядә (ә ул чакта безнең төбәк тулысы белән Уфа өязенең Минзәлә волостена керә) Ык елгасы буендагы Мөслим, Актаныш, Кырымсарай кебек 42 авыл һәм аларда яшәүче 2200 җан ир-ат теркәлсә дә, Зәй һәм Шушма елгаларының үрге агымында утрак тормыштагы авыллар булмавы бик ачык күренә. Димәк, әле 1723 елда да безнең район биләмәсендә утрак тормыштагы бер генә авыл да, шул исәптән Зәй-Каратай да булмаган. Ә менә 1746 елда үткәрелгән Икенче ревизиядә (безнең төбәк өчен Беренче ревизия) хәзерге Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә, өлешчә Азнакай һәм Сарман районнарындагы 50ләп авыл, шул исәптән Каратай да беренче тапкыр телгә алына. Ревизия көненә (1746 елның җәе) Каратай авылында 42 ир-ат теркәлгән. Авылда шул чама ук, хәтта артыграк та хатын-кыз да булуын искә алсак, димәк, монда инде 100ләп кеше яшәгән. Менә шуннан һәм күршедәге кайбер авылларны нигезләүчеләрнең ревизия көненә инде үлгән булуларыннан чыгып, бу авылларда яшәүчеләр (шулай ук Каратай да) ревизия елында гына килеп утырмаганнар, бәлки, бiредә инде ун-унбиш ел гомер сөргәннәр, ягъни авылларын 1730 нчы еллар тирәсендә нигезләгәннәр дигән нәтиҗә килеп чыга. Каратай суы буена утырганлыктан, авылга Каратай дигән исем бирелгән. Каратай – борынгы төрки кеше исеме. Аның булачак авылның урынын карап кайткан яисә башлап килеп утырган кеше исеме булуы бик ихтимал. Чөнки элегрәк утрак тормышлы авыллары булмаган бу яклардагы бәләкәй елгаларга исемнәр авыл нигезләнү белән бер үк вакытта (мәсәлән, Шөгер суы һәм Шөгер авылы) бирелү фактлары еш булган. Шунысын да әйтик: XVIII гасырда авыл Каратай дип кенә аталган. Гасыр ахырына таба төбәктә шундый ук исемдәге икенче авыл (Мөэмин-Каратай) барлыкка килгәч, аларны бутамау өчен, аңа «Зәй» сүзе өстәлгән.

Авылда кемнәр һәм кайчан нигез корган?

Бүгенге Зәй-Каратай җиренә XVIII гасырның 30 нчы елларында килеп төпләнгән бу кешеләр кемнәр булганнар да әлеге бәрәкәтле җирләргә каян килеп чыкканнар соң? XIX гасырда (1864, 1883, 1900 һәм 1910 нчы еллар) басылып чыккан рәсми белешмә-китапларның (алар Рәсәйнең статистика комитеты тарафыннан нәшер ителгән) барысында да Зәй-Каратай халкы турында «типтәрләр һәм башкортлар» диелгән. Авылның үзендә сакланып килгән язма һәм телдән истәлекләрдә дә «безнең бабаларыбыз башкорт булганнар» (мәсәлән, Туйкиннарның нәсел башы Туйкә бабайдан башланган) дигән кебегрәк сүзләр очрый. Әнә шулардан чыгып, Башкортстан матбугаты (әйтик, «Агыйдел» журналы) Зәй-Каратай авылын – «башкорт авылы», халкын «башкортлар» дип яза. Әмма бу сүзләр чынбарлыкка туры киләме соң?

Фараз-юрауларны читкә куеп, архив документларына мөрәҗәгать итик. Менә 1746 елда язылган, 1748 елда төпләп куелган «Ясаклы татар крестьяннарын исәпкә алу кенәгәсе» (БАҮДА, 350 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 3793 нче китап, 19-34 нче битләр). Без сүз алып бара торган авыл турындагы мәгълүматлар мондый сүзләр белән башлана: *«В деревне Каратаево, что на речке Каратае. Татара»*. Шуннан инде авылда яшәүчеләрнең (башлап килеп утыручыларның дисәк тә була) исем-фамилияләре бирелә.

Ә менә документның түбәндәрәк китерелә торган өлеше безнең өчен аеруча кызыклы. Тәрҗемәдә нинди дә булса хата җибәрмәү өчен, аларны документтагыча китерәбез: *«Перешедшие собою с того же Казанской дороги с разных деревень: из деревни Куяше, что на речке Куяше. Написано в первой переписи (ягъни Беренче ревизиядә Кояш авылында теркәлгән булган) Халил Мрясов (Мөрәстән) – 34. У него сын после переписи рожденный (исеме танылмый) – 2. Написано в прежней переписи Баки Мрясов – 28. У него сын после переписи рожденный. Умер – году (бер яшьтә дигәне). Умершего написанного в прежней переписи Сулеймана дети после переписи (сүз Беренче ревизия турында бара) рожденные Исмаил – 14, Исхак – 7.*

Из деревни Каргалов, что на речке Каргале. Умершего, написанного в прежней переписи Мукима Резяпова дети написанно в прежней переписи Амин – 43, после переписи рожденный Байрамгуль – 14» һ.б.

Сүзебезгә аз гына ачыклык керде кебек. Зәй-Каратай халкының байтагы Казан юлындагы төрле авыллардан, шул исәптән Кояш һәм Каргалы авылларыннан күчеп килгәннәр икән. Ә Уфа өязенең Казан юлы авылларының Уфа белән Кичү (Әлмәт районы) арасындагы авыллар икәнен без тарихи әдәбияттан беләбез инде. Авылда шушы көнгә кадәр яшәп килгән риваятьләрдә күчеп килгән кешеләрнең кайберәүләре көтү-көтү елкы һәм башка мал-туар куып алып килгәне хәбәр ителә. Бу инде күчеп килүчеләрнең байтагы бай, хәлле булуы турында сөйли. Димәк, алар Казан ягыннан түгел. Казан өязеннән булсалар, ач, хәерче һәм ялангач булырлар иде (XVIII гасырдагы колониаль һәм милли изү аларны шул хәлгә төшергән). Инде аңлашылды: Зәй-Каратайга башлап күчеп килүчеләрнең күбесе Уфа ягындагы авыллардан булганнар. Ләкин моңа карап, аларны «башкортлар» дип атарга ашыкмыйк, документларны карауны дәвам итик.

Алдыбызда чираттагы перепись – 1762 елның 9 июлендә Уфа өязенең Казан юлы Нәдер волостенда үткәрелгән Өченче ревизия документы (БАҮДА, 350 нче фонд, 2 тасвирлама, 3794 нче китап). Бу юлысында Зәй-Каратай авылы ясаклы типтәр-бабуллар исемлегендә телгә алына. Без инде типтәрләрнең, башкорт сахраларына килеп, килешү белән җир алганлыгын һәм шул килешүнең дәфтәргә (тэфтэр) язылулары аркасында «типтәр» дип аталуларын беләбез. Димәк, зәй-каратайлылар бернинди дә башкорт түгел, ә үзебезнең типтәрләр икән. Дөрес, араларында нинди дә булса юллар белән бу якларда җиргә ия булган, шуның өчен «башкорт» сословиесенә (милләтенә түгел) язылганнары да булгандыр. Ләкин андыйлар күп түгел, башлыча типтәрләр. Әнә бит, Өченче ревизиядән күренгәнчә, исемнәре башкортка якын да килмәгән: «Абдулла Шайматов – 56, аның хатыны Гөлбикә – 50».

Зәй-каратайлыларның башлап килеп утырган бабаларының кемнәр булуында шик-шөбһә калмасын өчен, тагын бер документка – безнең төбәктә (Казан юлы, Бөгелмә өязе, Нәдер волосте) 1785 елда үткәрелгән Дүртенче ревизия документларына (Санкт-Петербург үзәк дәүләт тарих архивы, 538 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 294 нче китап, 67 нче бит) мөрәҗәгать итик. *«Каратай авылында: типтәрләр һәм бабуллар (иң хәерче кешеләр дигәне) – 80, исәпкә алына торган йомышлы татарлар (болары мишәрләр була) – 30, ясаклы*

«

Авылда шушы көнгә кадәр яшәп килгән риваятьләрдә күчеп килгән кешеләрнең кайберәүләре көтү-көтү елкы һәм башка мал-туар куып алып килгәне хәбәр ителә.

татарлар – 43. Җәмгысы – 153 кеше» (сүз ир-атлар хакында бара, әлбәттә). Документтан күренә ки, авылда бер генә дә «башкорт» дигән кеше юк: типтәр-бабуллар, йомышлы татарлар һәм ясаклы татарлар. Бу урында шунысын да әйтик: бер генә авылның, шул исәптән Зәй-Каратайның да, халкы бер генә компоненттан тормый. Безнең як татарларын шәкелләндерүче төп компонентлар: Казан татарлары, типтәрләр һәм чукынмаган чуаш, мукшы, чирмеш-арлар. Соңрак Зәй-Каратайга да бер урам булып чукынмаган чуашлар күчеп утыруы турында мәгълүмат бар.

> **«Без инде типтәрләрнең, башкорт сахраларына килеп, килешү белән җир алганлыгын һәм шул килешүнең дәфтәргә (тэфтэр) язылулары аркасында «типтәр» дип аталуларын беләбез.**

Инде нәтиҗә ясыйк. Димәк, Зәй-Каратайга башлап килеп утыручылар – Башкортстан җирендә яшәгән типтәрләр, ягъни Казан өязеннән алданрак күпкан шул ук Казан татарлары. Тора-бара алар мишәрләр һәм чукынмаган чуашлар белән дә аралашканнар. Укучыда хаклы рәвештә сорау туарга мөмкин: нишләп әле бөтен Казан, Зөя, Чистай һәм Сембер өязләре татарлары авыллары-авыллары белән хөр-иркен башкорт сахраларына качкан вакытта зәй-каратайлыларның бабалары тискәрегә таба килеп төпләнгәннәр?

Моның җавабы бик гади. Петр Беренче хакимлек иткән XVIII гасыр башында татарларны чукындыру һәм милләт буларак юк итү өр-яңа куәт белән башланып китә, һәм ул Казан епархиясендә архиепископ Лука Канашевич (Аксак Каратун) башбаштаклык иткән 30-40 нчы елларда үзенең иң югары ноктасына җитә. Нәкъ шушы елларда Казан өязендәге 536 мәчетнең 418е вәйран ителә. Гомумән, XVIII гасырның беренче яртысында татар халкын кысу һәм изү коточкыч дәрәҗәгә җитә. Моңа җавап итеп, татарлар бөтен нәсел-ырулары, авыллары-авыллары белән кояш чыгышындагы буш җирләргә качып китәләр. Бу хәлгә аптыраган патша Башкортстанга качкан типтәрләрне кире Идел буена кайтару турында Указ чыгара. 1722 елда граф Головкин 5 мең чамасы (19815 ир-ат) гаиләне кире Казан губернасына кайтаруга ирешә дә. Байтак кына крестьяннар исә тотып кайтарганны көтеп ятмыйлар, үзләре Казан губернасына якынрак буш яткан җирләргә (Зәй һәм Шушма елгаларының үрге агымнарына) качучыларга кушылып күчеп китәләр. Бу якларга килеп, Зәй-Каратай авылын нигезләүчеләр әнә шундый кешеләр булган.

Халыкның кәсебе һәм социаль хәле

Район биләмәсендәге башка бик күп авыллар кебек үк, Зәй-Каратайда да дәүләт крестьяннары яши. Җир исә крестьяннарга һәр 15 ел саен (бу тәртип бик еш бозылган) гаиләдәге ир-атлар саныннан чыгып бүлеп бирелгән. Өстәвенә, урманнар һаман саен төпләнеп, сөрү җирләре арта барган. Әнә шул сәбәпләр аркасында (чагыштырмача ирекле булу һәм җирләрнең артып торуы) безнең якларда крестьяннар чагыштырмача күбрәк (7,2 дисәтинәдән алып 16шар дисәтинәгә кадәр) җиргә ия булганнар. Бабаларыбыз үзләренә тигән җирләрдә арыш, борай, арпа, солы, борчак, тары һәм карабодай, соңрак бодай иккәннәр. Җирне болгар сабаны һәм сука белән йомшартканнар, тубалдан кул белән сибеп чәчкәннәр, агач тешле тырма белән тырмалаганнар, урак белән урганнар

Хезмәт ветераны
Банат Нуретдинова

һәм чабагач белән сукканнар. Игенчелектә өч басулы чәчү әйләнеше хакимлек иткән. Басуларның бер өлешенә – уҗым арышы, икенчесенә сабан ашлыклары чәчкәннәр, өченче өлеше исә пар җире итеп калдырылган. Безнең төбәктә татар крестьяннары яшелчәчелек һәм бакчачылык белән шөгыльләнмәгәннәр диярлек. Алай да авылда сирәк-мирәк шалкан, кыяр, кәбестәише яшелчәләр үстереп һәм шуны сатып көн итүчеләр дә булган. Шундыйларның берсен Зәй-Каратайда «Шалканчы Латыйп» дип йөрткәннәр.

Әнә шул рәвештә тереклек кылган авылда күпчелекне үз көнен үзе күрүче урта хәлле крестьяннар тәшкил иткән. Алай да, төрле сәбәпләр аркасында (кызларының яки улларының күп булуы, ялкаулык, уңганлык һ.б.), Зәй-Каратайда да сыйнфый катлау чуар булган. Монда Хафиз Хәлимов кебек урта хәлләләре, Кашшаф бабай кебек ярлылары да байтак яшәгән. Алар, үз хуҗалыкларын алып бару белән беррәттән, Горкиноише күрше авылларга «урыс урагы»на да барып йөргәннәр. Әнә шулай очын-очка ялгап яшәүчеләр белән беррәттән, төрле елларда староста булып сайланган Уразов Бәдретдин, Вахитов Кәлимулла, Уразов Шәңгәрәй, Казаков Сәлимгәрәй, Дәүләтшин Нәүширван, Исхаков Вафа, Хөснетдинов Баһаветдин, Шәрәпов Шиһап, Әләмколов Сабит, Җәлмиев Динмөхәммәт, Шаһиев Минәхмәт, Гыйззәтуллин Шәмсулла, Мөлеков Мөхәммәди, Әхмәтшин Шәрәп, Галиев Гәрәй, Гатауллин Сәмәрхан кебек таза тормышлы крестьяннар, волость старшинасы дәрәҗәсенә күтәрелгән Мөхәммәтшин Шәрәп, Зыякаев Шиһап, Әхмәтҗанов Җиһанша, Сабитов Гарифулла, Сәйфетдинов Бәдретдин кебек баеп китүчеләр, Вильданов Ногман, Рәфыйков Гәрәй, Фәхретдинов Тәкытдин, Вәлиев Фәрзетдин, Галиев Мөхәммәтгалиләр кебек кибет тотып, чәй-шикәр, керосин, кызыл мал һәм башка товарлар белән сату итүчеләр, ниһаять, Рәхмәтуллин Сәгъди, Мөхәммәтҗанов Әхмәтҗан, Мөлеков Фаварис, Сәгъдиев Гайфулла, Исмәгыйлов Якуп, Рәхмәтуллин Гатаулла, Мөлеков Әхмәтҗан, Кәримов Мөхәммәтсафа, Габденасыйров Ногман, Ишмөхәммәтев Вәли, Фәтхетдинев Бәдретдин кебек бай-

Колхозның беренче рәисе, сугыш инвалиды Хәсән Ихсанов

лар да яшәгән. Байларның кайберләре эшне зурдан йөрткән. Мәсәлән, XIX гасыр азакларында яшәгән Рәхмәтуллин Сәгъдинең аерым елкы көтүе (2 мең башка кадәр ат), XX гасыр башында яшәгән Сәгъдиев Гайфулланың үзенең сарык көтүе була. Әнә шуңа да, ягъни социаль катлауның төрле булуы аркасында, Зәй-Каратайда тормыш тыныч кына акмый, еш кына төрле буталыш, ризасызлык, ыгы-зыгы чыгып тора. XVIII һәм XIX гасырларда авыл халкының «башкорт»ларга һәм татарларга бүленеп йөртелүе, һәр ике халыкның (типтәрләрнең һәм татарларның) үз старосталарын сайлап куюлары да төрле ызгыш-талашларга, дәгъваларга нигез булган. Яңа гасыр башында авылга бер генә староста сайлап куя башлагач, каршылыклар кими төшкән, бу инде авыл халкының татарлар булып формалашып бетүен аңлаткан.

«

XVIII һәм XIX гасырларда авыл халкының «башкорт»ларга һәм татарларга бүленеп йөртелүе, һәр ике халыкның (типтәрләрнең һәм татарларның) үз старосталарын сайлап куюлары да төрле ызгыш-талашларга, дәгъваларга нигез булган.

Зәй-каратайлылар 1878-1879 нчы еллардагы крестьяннар чуалышында актив катнашалар, 1889 елда, күмәкләшеп, рөхсәтсез, казна урманын кисәләр. Бу исә турыдан-туры «хөкүмәткә каршы чыгу» дип бәяләнгән. Бирелә 1897 елгы халык санын алу вакытында да халык аңа теше-тырнагы белән каршы чыга. Бөгелмәдән 190 атлы казак килеп, халыкны котыртучы Вафин Фазыл, Ризванов Нури, Икътисамов Фазыл, Дәүләтшин Нәүширван һәм Мөхәммәтшин Әхмәткәримнәргә 60-80шәр чыбык суктырылгач һәм кайберләре өч айга төрмәгә ябылгач кына, переписьны эттем-төрттем үткәрәләр.

Зәй-Каратай авылы музеендагы кулъязма мирас

Революциягә кадәр нинди генә вакыйга-хәлләр булмасын, Зәй-Каратай үзенең мул тормышы, авылның төзеклеге, халкының уңган-булганлыгы белән аерылып торган. Төбәктә беренче тимер сабаннар, җилгәргечләр, ашлык сугу һәм башка машиналар нәкъ менә Зәй-Каратайда кулланыла башлаган. Кредит ширкәтләренең дә берсе Зәй-Каратайда оештырылган (идарә рәисе – Иоан Степанович Столяров һәм авыл советы рәисе – Гарифулла Сабитов).

Авыл мәгарифе

Зәй-Каратай үзенең матди яктан ныграк яшәве белән генә түгел, халкының зыялылыгы, мәгърифәткә омтылышы белән дә аерылып торган. Аның борынгы тарихында әлеге омтылыш кызыл җеп булып сузылып бара. Халык мәгарифе ветераны Ибраһим ага Туйкин үзенең язмаларында әле XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында ук авылда 225 гыйлемле кеше (укый-яза белүче) булуын хәбәр итә. Бу инде заманасына күрә начар түгел.

Дөрес, кызлар һәм малайлар аерым-аерым укый торган мәктәпләр безнең төбәктә беренче авыллар нигезләгәннән бирле (XVIII гасырның 30-40 нчы еллары) булган. Мәгәр уку-укыту эшләре һәр авылда диярлек аерым кешеләрнең шәхси йортларында барган. Зәй-Каратайда исә XIX гасыр уртасында ук мәчет янында мәктәп өчен махсус алтыпочмаклы йорт салынган. Анда мулла Габделлатыйф Туйкин малайларны укыткан. Аның остабикәсе Мәрхабә исә кызларга үзләренең өйләрендә белем биргән. Алардан соң авылда халык мәгарифе эшен мулла Әхмәткәрим һәм аның остабикәсе Гайшә, Мәүлет суфи, мулла Закир Туйкин һәм аларның хатыннары дәвам иткән.

XIX гасыр ахырында (1898-1899) Харис мулла шул ук бинада беренче җәдит мәктәбен ачып җибәрә. Мәктәптә тәүге мәртәбә парталар, кара такта, акбур һ.б. барлыкка килә. Монда махсус әзерлекле мөгаллим сабак бирә.

1904 елда бертуган мөгаллимнәр – Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар һәм мулла Һади Фәрхетдинев авылда мәктәп салу өчен акча җыюны оештыра. Нәтиҗәдә, Зәй-Каратайда өчәр бүлмәле ике мәктәп барлыкка килә. Аларда укыту гел яңача, әлифба һәм башка дәреслекләр, уку әсбаплары ярдәмендә алып барыла. Мөгаллимнәр Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар, Нәбиулла Надыйров һәм Закир Әкбәрев балаларга дүрт класс күләмендә белем бирәләр. Мәктәпләрдә, дин сабагыннан тыш, арифметика, география, тарих, табигать белеме һәм башка фәннәр дә укытыла. Ибраһим ага Туйкин әлеге мәктәпләрдә йөзләрчә балаларның белем алуын әйтә. Бер үк вакытта авылдагы тагы ике мәхәллә мәктәбендә дә укулар бара. Аларында Арслан Гыймадиев белән Давыт Сөләйманов мөгаллимлек итә. Ә муллалар Габдрахман Ногманов белән Хөсәен Латыйповларның остабикәләре Мөсәббихә белән Хөршидә элеккечә үз өйләрендә кызларга сабак бирә.

Зәй-Каратайда шул вакытта ук заманча мәктәп эшләве һәм анда дөньяви фәннәр укытылуы карагруһчыларның һәм урыс шовинистларының кытыкларына тия, өязгә бер-бер артлы шикаятьләр ява. Ниһаять, 1909 елда авылга жандармнар килеп төшә. Алар яңача укытыла торган мәктәпләрне вәйран итәләр. Кәбир Туйкинны исә кулга алалар һәм төрмәгә утырталар.

Инде сүз халык мәгарифе турында бара икән, бераз алгарак китеп булса да, шуларын да әйтик. 1917 елда биредә, район биләмәсендә, дүртенче булып земство (дәүләт) мәктәбе ачыла. Инкыйлабтан соң ул авылда беренче совет мәктәбенә әверелә һәм аның мөдире Ибраһим Туйкин була. Башта анда ике сыйныф,тора-бара өч сыйныф, ә 1922-1923 уку елыннан биш сыйныф күләмендә белем бирелә. Авылда балаларны укытырга теләүчеләр бихисап, ә кантон мәгариф бүлегенең укытучыларга түләргә акчасы булмый. Менә шуңа да 1924-1925 уку елыннан крестьяннар, үзләре түләп, укытучылар яллыйлар. Мөгаллим һәм мөгаллимәләр Зәйнәп Мисбахова (Иске Иштирәктән), Шәфига Туйкина һәм Ибраһим Мәүлетевләр, укытуны кантон мәгариф бүлеге программасы нигезендә алып барсалар да, хезмәт хакын авыл халкыннан алалар.

Табигый ки, мәгърифәткә әнә шундый зур игътибар бирелгән Зәй-Каратай кебек авылда крестьяннар Совет властен хәерхаһ кабул итәләр. Дөньяның астын-өскә китергән революция булып узуга ук, 1917-1918 елның кышында авыл зыялылары Кыям Сираев, Хәмит Сабитов, Һади Гыймадиев, Ризатдин Сираев, Закир Миңнеголов, Шәймәрдан Һидиятов, Дәүләтгәрәй Әһлиуллин, Кәрам Рәфыйков, Закирҗан Маһиянов, Кәбир, Фазыл, Ибраһим һәм Фатыйх Туйкиннар авыл җыеннарында һәм башка урыннарда аңлату эшләрен даими алып баралар, халыкка революциянең әһәмиятен, большевиклар партиясенең сәясәтен, Совет властеның декретларын һ.б. тәфсилләп аңлаталар. Әнә шул эшнең нәтиҗәсе буларак, авыл крестьяннары Закир Миңнеголов, Дәүләтгәрәй Әһлиуллин, Насыйбулла Гыйниятов, Шаһимәрдән Һидиятов һәм башка бик күпләр кызылгвардиячеләр сафына иреклеләр булып язылалар. Әнә шул даулы еллардан соң күп еллар үткәч, зәй-каратайлылар үзләренең авылларыннан Гражданнар сугышында катнашучыларны барлыйлар һәм 148 исем язып алалар. Ә аларның күпмесе сугыш кырларында ятып калган һәм онытылганнар бит әле!.. ■

Галим Рашат Гайнановның тууына 95 ел

Олы мирасны барлаганда

Лена Гайнанова



Р.Гайнанов «Азат хатын»ның җаваплы сәркатибе. 1959 ел

Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең беренче фәнни басмасы 1974-1986 нчы елларда басылып чыкты. Ул башта унтомлык итеп планлаштырылса да, ниндидер сәбәпләр табылып, сигез томга калдырылды (соңыннан әдипнең хатлары, документлары, өстәмә 9 нчы том булып, 2000 елда дөнья күрде).

Сигезтомлыкның 1-6 нчы томнарында төп эшне Рашат Гайнанов башкарды. Бигрәк тә 5-6 нчы – тәнкыйть һәм публицистика томнарын төзүгә аның көче күп керде. 6 нчы томга язылган керештә төзүче галим болай әйтергә мәҗбүр: *«Әлбәттә, күләме 8 том белән чикләнгән әсәрләр җыелмасына әдипнең барлык язмалары да керә алмады. Публицистикасының, мәсәлән, яртысы чамасы гына бу томда урын тапты»*. Әзерләнгән материалларның басмага керми калуы үкенечле иде, әлбәттә. 2018 елда мин Р.Гайнанов әзерләп, машинкада бастырып куйган шул бер томлык публицистик материалларны хәзерге вакытта Г.Ибраһимовның 15 томлыгын төзүче текстологлар кулына тапшырдым.

Тарихи материалларны эченә алган 7 нче томны Сәлам Алишев, ә тел гыйлеменә караган 8 нче томны Лена Гайнанова әзерләде. Соңгы томдагы әсәрләргә искәрмәләрне Фазыл Фәсиев язды. Г.Ибраһимовның архивы юкка чыккан, аның һичнинди библиографиясе дә юк иде. Шуңа күрә томнарны төзүчеләргә әдип иҗат иткән чорда гарәп язуында басылып чыккан бөтен газета-журналларның һәр санын җентекләп карап чыгарга туры килде. Бу эштә безгә Р.Гайнановның гомере буе җыйган, Миркасыйм Госманов «хикмәтле» дип атаган картотекасы бик булышты. Мин үзем, мәсәлән, газета-журналларның Казан китапханәләрендә булмаган саннарын тикшерү өчен, Мәскәүгә, Ленинградка,

Р.Гайнанов Себердә экспедиция вакытында

Р.Гайнанов хатыны Фәния һәм кызы Ләйлә белән. Васильево бистәсе. 1955 ел

СССРның спорт мастеры, РСФСРның шахмат чемпионы Рәшит Нәҗметдиновның «Совет Татарстаны» редакциясендә берьюлы 23 тактада сеансы. Уңнан өченче – Рашат Гайнанов, дүртенче – Зәет Мәҗитов, бишенче – Шәйхи Маннур. 1954 елның 7 апреле. *Б.Денисов фотосы*

Уфага командировкаларга бардым. Тел томына материал җыю белән бергә, Рашат абый төзеп җибәргән исемлек буенча да мәкаләләр күчереп алып кайта идем. Р.Гайнанов үзе дә командировкаларга йөрде. Нәтиҗәдә, 5 нче томга кергән материалларның дүрттән өч өлеше, ә 6, 7 һәм 8 нче томдагылары исә тоташ хәзерге язуда беренче тапкыр басылды.

Р.Гайнанов Г.Ибраһимов әсәрләренә зур күләмдә гаять бай мәгълүматлы комментарийлар бирү белән генә чикләнмәде, ул әдипнең бай мирасын туплады, аерым газета-журналлардагы эшчәнлеге турында фәнни мәкаләләр дә язды. Укучыларга шуларның берсен тәкъдим итәбез.

Бертөркем татар галимнәре өмәдә. Сулдан: Рашат Гайнанов, Флүн Мусин, Нил Юзеев, Мәсгуд Гайнетдин, Шакир Абилов. 1985 ел

Р.Гайнанов оныгы Салават белән

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

Галимҗан Ибраһимов һәм «Аң» журналы

Рашат Гайнанов

1912 елның декабрендә «Русиядә татар телендә ике атнага бер чыга торган иң киң программалы әдәби, фәнни, сәяси, иҗтимагый, рәсемле» «Аң» журналы тарала башлау татар матбугаты һәм әдәбияты дөньясында күренекле вакыйга булды.

«Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын «Аң» белән»

Мәгълүм ки, «Аң»ның дөньяга килүе даһи Тукай исеме белән бәйләнгән. Әдәби журнал чыгару турында беренче сүз салучы да, аңа исем кушучы да ул. Бу әһәмиятле вакыйгага багышлап язган һәм журналны ачып җибәргән «Аң» дигән тирән мәгънәле шигырендә Тукай татарның уянуын турыдан-туры бишенче ел белән бәйләве, шуның дәвамы буларак, хәзер аң кирәк диюе, «Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын «Аң» белән», дип өндәве югарыда әйтелгән фикерне расласа кирәк.

«Аң» тиз арада демократик язучыларны үз тирәсенә туплый. Журналның һәр саны диярлек Тукай шигырьләре белән ачыла. Аның битләрендә без Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г.Ибраһимов, Н.Думави, С.Рахманколый, Г.Рәхим, Г.Газиз, С.Сүнчәләй, Г.Алпаров, Г.Кәрәм, Х.Кәрим һ.б.ларның исемнәрен еш күрәбез.

Әмма журналның җанын тәшкил итәргә тиеш Тукай бу вакытта инде соңгы чиктәге авыру була. Ул шигырьләре, киңәшләре белән журнал эшендә катнашса да, анда «Яшен» яки «Ялт-йолт»тагы кебек янып эшли алмый. Ф.Әмирхан исә «Аң» белән бер үк вакытта чыга башлаган «Кояш» газетасына эшкә керә, көндәлек журналистлык эшенә чума. Шуларның нәтиҗәсе буларак, берничә номердан соң «Аң» эчтәлеге белән саега, ваклана, авторлар даирәсе тарая, анда әһәмиятсез тәрҗемә әйберләр, дини-романтик язмалар күбрәк урын ала башлый.

«Аң»га Галимҗан Ибраһимов килә

Менә шундый шартларда 1913 елның октябрендә «Аң»га Галимҗан Ибраһимов килә. Бу хакта журналның 1913 елның 20 октябрендә чыккан 20 нче санында мондый белдерү бар: *«Аң»ның сәркатиплек ләвазимене (вазыйфасын) мөхәррирләребездән Галимҗан әфәнде кабул итте. Журнал киләчәк саннан игътибарән (алып) аның каравында чыгачактыр»*. «Аның каравында чыгачактыр» дигән сүзләргә игътибар итеп, Ибраһимовның, гәрчә ул «сәркатип» дип аталса да, журналга фактик редактор булып килгәнлеген башта ук әйтеп китик. Бу елларда күп очракта нашир-издатель мөхәррир дип аталган. Ул редакцияне матди яктан тәэмин итү, газета-журналны сату-тарату эшләре белән шөгыльләнә, властьлар алдында җаваплы кеше ул була. «Аң»ның рәсми редакторы – «Гасыр» исемле көтепханә (нәшрият) хуҗасы, Тукай, Әмирханнарның якын дусты Әхмәтгәрәй Хәсәни. Ул үзе яңа карашлы, белемле, югары культуралы, татар демократик әдәбиятын бастыру, тарату эшендә шактый гайрәт күрсәткән кеше булса да, кайбер тәрҗемәләрен һәм компелятив характердагы пьесаларын исәпкә алмаганда, журналист яки язучы булмый.

«Аң»га секретарь булып килгән Г.Ибраһимов бу вакытта инде байтак хикәяләрен, «Яшь йөрәкләр» романын бастырган тиз үсеп килүче әдип, татар вакытлы матбугатында үткен, анык каләме белән актив катнашкан әдәби тәнкыйтьче, ялкынлы публицист булып танылган. Мәгълүм ки, Киев вакыйгаларының эчендә кайнап, патша төрмәсе «сый-хөрмәтен» дә татып өлгергән, революцион эше өчен патша властьлары тарафыннан яшерен күзәтү астына алынган. Кыскасы, яшь әдипнең каләм тәҗрибәсе дә, сәяси көрәш тәҗрибәсе дә хәйран гына.

Г.Ибраһимов үзенә хас дәрт һәм ялкын белән әдәби журнал эшенә бирелә. Архив документларыннан күренгәнчә, ул Киевтан, полиция теле белән әйткәндә, «иң сул юнәлештәге» газета чыгару нияте белән кайта, үзенә теләктәшләр дә таба, ләкин күп сәбәпләр аркасында бу максатына ирешә алмый. Шуннан соң ул «Аң» идарәсе тәкъдимен кабул итә. («Әл-Ислах» газетасы редакторы Вафа Бәхтияровның безгә сөйләгән истәлекләренә караганда, Г.Ибраһимовны чакырырга Ә.Хәсәнигә Фатих Әмирхан тәкъдим итә. Һәм эшкә тотынып алдыннан алар, Әмирхан квартирасында озаклап утырып, киңәш-табыш итәләр.) Ибраһимов, «Аң»да эшли башлагач та, «иң сул юнәлештәге» газета аша халыкка җиткерергә теләгән караш-фикерләреннән, әлбәттә, ваз кичми. Хәзер инде аның алдына сәяси-публицистика теле белән татар җәмәгатьчелегенә ирештерергә тиешле фикерләрен әдәби журнал битләре аша, башлыча әдәби әсәрләрдә һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә чагылдыру бурычы килеп баса. Г.Ибраһимовның «Аң»ны чыгаруга зур дәрт белән тотынуының сәбәпләреннән берсе дә шул, әлбәттә.

«Аң»дагы үзгәрешләр нидән гыйбарәт?

Чыннан да, Г.Ибраһимов үз җаваплылыгына алганнан соң чыккан 1913 елгы 21 нче саннан башлап журналның йөзе тамырдан үзгәрә. Беренчедән, журналның тагын да ныграк демократлашуга йөз тотуын күрәбез. Баштарак актив язышып та, соңга таба журнал битләрендә күренми башлаган Ф.Әмирханның һәр санда диярлек яңа әсәрләре урнаштырыла. Ибраһимов килгәнче аз язышкан М.Гафури әсәрләре еш басыла. Журналга Ш.Камал, М.Фәйзи, Ф.Сәйфи, Ш.Әхмәдиев кебек язучылар килә. Тукай поэзия мәктәбе шәкертләре дип йөртелгән Габдулла Харис, Габдрахман Сөнгати һ.б. шагыйрьләр «Аң»да Г.Ибраһимов эшләгән дәвердә басыла башлыйлар. Киев чоры буенча Галимҗанның көрәштәше – яшьли үлгән кыю революционер һәм шагыйрь Сәетгәрәй Еникиев, шундый ук фаҗигале язмышка очраган Ибраһим Башмаков шигырьләре дөнья күрә.

21 нче саннан ук журналның тышкы кыяфәте, бизәлеше, материалларны урнаштыру тәртибе дә, хәтта версткасы-битләргә салу да үзгәрә; гомумән, структурасы төзек, анык бер тәртипкә салына. Әйтергә кирәк, бу санга кадәр журналда бүлекләр, рубрикалар юк дәрәҗәсендә, материаллар бер-бер артлы тезелеп бара, журнал төрле ризыктан болгаткан винегретны хәтерләтә иде. Моңа кадәр ике табак күләмендә басылып килгән «Аң» 21 нче саннан өч табак итеп чыгарыла, ә 24 нче сан инде икеләтә зурая – баштагы 16 бит урынына 32 битле булып чыга.

Болары – журналның тышкы күренеш-кыяфәтендәге үзгәрешләр. Ләкин моның артында эчке үзгәреш, мәгънәви яңарыш ята. Болар нәрсәдә күренә соң?

Барыннан да элек, яңа секретарь, ягъни фактик редактор, «Аң»ның колачын, диапазонын нык киңәйтү бурычын куя. Шул ният белән ул моңарчы журналда күренмәгән бүлекләр булдыра. Менә алар: «Әдәбият», «Матбугат», «Яңа әсәрләр», «Шигырьләр», «Тәнкыйть», «Театр һәм музыка», «Фәнни вә фәлсәфи мәсьәләләр», «Хатын-кыз галәменнән», «Үз хәятыбыздан», «Җыентык» (яки «Всякая-всячина») һ.б. Күренә ки, «Аң» калын журналларга хас кыяфәткә керә. Укучы бер табакка өелгән винегрет түгел, төрле савытларга пөхтәләп аерып салынган җан азыгы ала, үзен кызыктырган почмакны бер карауда ук таба.

Махсус исем белән аталган бүлек, рубрика бар икән, аның материалы да булырга тиеш, әлбәттә. Менә монда инде Г.Ибраһимовка гаять зур оештыру эше алып барырга туры килә. Ул хатлар яза, авторлар белән сөйләшә, редакция почтасын мөмкин кадәр тулы файдаланырга тырыша, социаль заказлар бирә. Әйе, социаль заказлар да бирә. Менә бер генә мисал: *«Аң»да татар ысуле тәрәккыйсе вә кичерелгән дәверләр хакында бернәрсә кирәк иде,* – дип яза Г.Ибраһимов журналда эшли башлау белән үк яшь язучы Хөсни Кәримгә 1913 елгы 8 ноябрь хатында. – *Моны «Бәдәвам» вә «Фәзаилешшөһүр»ләрдән, Каюм Насыйри, Заһир Бигиевләрдән башлап хәзерге минутка тәрәргә лазем булыр иде».* Аңлашыла ки, Г.Ибраһимов татардагы әдәбият, мәдәният, мәгърифәт тарихы хакында хыяллана һәм, шул темага язучы булмасмы, дип, авторларны капшап карый. Аның 1913 елда ук бу мәсьәләне күтәрергә уйлавы зур әһәмияткә ия.

> «
> **21 нче саннан ук журналның тышкы кыяфәте, бизәлеше, материалларны урнаштыру тәртибе дә, хәтта версткасы-битләргә салу да үзгәрә; гомумән, структурасы төзек, анык бер тәртипкә салына.**

Яңа секретарьны бүлекләр ачу гына да канәгатьләндереп бетерми, ул теге яки бу әһәмиятле мәсьәлә буенча каләм әһелләренең, халыкның фикерен белү һәм укучыларга җиткерү өчен анкета юлын да кулланырга омтыла. Мәсәлән, «Миллиятне ничек аңлыйсыз?» дигән темага анкета таратылып һәм журнал битендә дә басылып, аңа килгән җаваплар күп саннарда урнаштырыла. Без хәзер ул җаваплар белән танышып, шул чор татар язучылары, зыялылары-интеллигентлары, җәмәгать эшлеклеләренең милли мәсьәләне ничек аңлаганлыкларын ачыклый алабыз.

«Ф.Әмирхан: «Яңа ел мөнәсәбәте белән милли талантларыбызга күбрәк илһам килүен, зыялыларыбызга идеалларының мөгаенләнүен (ачыклануын), гомуми халкыбызга милли мәктәпләребез мәсьәләсенең киләчәгебез өчен файдалы сурәттә хәл ителүен телим», – дигән җавапны бирә.

Яңа – 1914 ел алдыннан журнал редакциясе күренекле әдипләргә, сәнгать, мәдәният, мәгариф эшлеклеләренә «Яңа елда ни телисез?» дигән анкета белән мөрәҗәгать итә. Аңа җаваплар журналда басылып та чыга. Биредә без Г.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Кариев, Г.Газиз, Г.Кәрәм, Ф.Агиев, И.Терегулов һ.б.ларның җавапларын табабыз. *«Милли театрыбызның мәдәни бер шәкелгә керүен, халкыбызның театрга җитди күз белән карый башлавын, театр сәнгате гражданлык алып, уйнаучыларның да, театрга язучыларның да күбәюен һәм камилләнүен телим»,* – ди анкетага җавабында татар театрының атасы *Галиәсгар Камал*. Ф.Әмирхан: *«Яңа ел мөнәсәбәте белән милли талантларыбызга күбрәк илһам килүен, зыялыларыбызга идеалларының мөгаенләнүен (ачыклануын), гомуми халкыбызга милли мәктәпләребез мәсьәләсенең киләчәгебез өчен файдалы сурәттә хәл ителүен телим»,* – дигән җавапны бирә. Анкетага бүтән җавапларда да шундый тирән фикерләр, яхшы теләкләр әйтелә.

Журналда Г.Ибраһимов ачкан тагын ике бүлек турында аерым әйтергә кирәк. Үзенә кадәр игъланнар белән тулып яки буш килеш чыгарылган тышлыкның икенче һәм өченче битләрендә 21 нче саннан алып «Укучылар белән мосахабә *(аралашу. – **Ред.**)*», «Идарәдән» (җаваплар) дигән яңа бүлекләргә очрыйбыз. Моңа кадәр буш яткан чирәм җиргә чәчелгән бу бүлекләрнең әһәмияте гаять зур. Әлегә чаклы «Аң»ның шушы бүлекләре турында матбугатта сүз күренгәне юк, күрәсең, аңа игътибар итүче булмагандыр. Ә бит болар – журнал битләреннән гади укучы күңеленә Галимҗан Ибраһимов сузган җепләр. Нәрсә турында гына язылмый, нинди генә сораулар юк ул бүлекләрдә!

Г.Ибраһимов укучылар белән чын мәгънәсендә диалог башлый, җанлы әңгәмә алып бара. Моны ул журнални – халыкка, халыкны журналга якынайту максаты белән эшли, әлбәттә. Бу бүлекләр, номердан-номерга зурая барып, тышлыктан журналның эченә керәләр, анда да сыеша алмый башлыйлар. Укучылардан хатлар күбәйгән саен, бүлекләрнең тематикасы да киңәя, эчтәлеге дә кызыклырак була бара. «Укучылар белән мосахәбә» чын мәгънәсендә консультация почмагына әверелә. Г.Ибраһимовка укучыларның күптөрле, җитди сорауларына җавап бирү өчен әдәбият белгече дә, телче дә, тарихчы да булырга туры килә...

1970 ел ■

Татар матбугаты тарихы

«Аваз» газетасы


Мусульманская Соціалистическая рабочая газета.

«Аваз» газетасы. 1917 ел

Шәһид Гыймадетдин улы Әхмәдиев – 1888 елның 29 декабрендә Чистай районының Татар Ялтаны авылында туа. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укый, шунда Галимҗан Ибраһимов белән дуслаша. Февраль революциясе көннәрендә Мулланур Вахитов белән бергә Үзәк Мөселман социалистлар комитетын оештыруда да зур көч куя, Казан сәүдә хезмәткәрләре һәм конторщикларының профсоюз оешмасын җитәкли. «Аваз» газетасын чыгарганчы, 1913-1914 нче елларда «Хокук вә хәят» журналының сәркатибе буларак тәҗрибә тупларга өлгерә. ТАССР Мәгариф халык комиссары булып эшли. 1930 елның 12 августында Казанда вафат була.

Шәһид Әхмәдиев – «Суга баткан килен» (1912), «Хат һәм җаваплар» (1912), «Шагыйрь моңая» (1913), «Мөгаллим» (1913), «Татар кызына» (1914), «Сагыш» (1914), «Ай алдады», «Канатлы тай», «Хан кызы» исемле хикәя һәм нәсерләр авторы.

Газета 1917 елның 8 апрелендә Казанда чыга башлый. Басманың үзендә язганча, «Аваз» – эшче һәм крестьяннар файдасын күзәтүче мөселман социалистик газетасы. Шигаре – «Берләшеңез, бөтен дөньяның эшчеләре! Берләшүдә, көрәшүдә генә табарсыз үз теләгеңезне! Нашире – Казан сәүдә хезмәткәрләре бюросы. Газетаның мөхәррире Шәһид Әхмәдиев (1888-1930) була.

Басма хакында Исмәгыйль Рәмиев менә ниләр яза: *«Моның иң күп язганы мөселман сәүдә хезмәткәрләренең тормышларын яхшырту мәсьәләсе булды. Гаять тә озын мәкаләләр язучы бердәнбер гәзит шушы иде. Алтышар-җидешәр баганалы мәкаләләрне моңарда номер саен диярлек очратып була. Атнасына ике тапкыр, дүрт битле булып чыкты. Технический матур, басылуы ачык, яхшы ук кәгазьдә».*

Газетаның максаты – мөселман эшчеләрен, крестьяннарны оештыру, алар арасында социализм идеяләрен тарату. Шул ук вакытта Казан сәүдә хезмәткәрләре бюросы эшчәнлегенә дә яктыртыла. Сәхифәләрендә милли үзбилгеләнү, азатлык мәсьәләләре дә күтәрелә. *«Татар социалистлары, бигрәк тә инде революционныйлары милли, дини азатлыкның беренче кирәк икәнен, һәрбер милләт үз башына яшәгәндә генә бөтен адәм баласының киләчәктәге матур тормышка ирешә алачагын бик яхшы белгәнгә, милли, дини теләкләрне икътисади теләкләрдән бер дә артка куймыйлар, бәлки, беренче урын иттереп алып баралар иде»,* – дип яза ул.

Газетаның таралуына Казанның эшче, солдат һәм крестьян вәкилләре советы да ярдәм иткән. *«Чын халык файдасын күздә тотучы һәм социализмга хезмәт итүче бер гәзитә дип табып, әлегә мөселман авылларына тарату өчен мең нөсхә алырга булды»,* – дип әйтелә бер хәбәрдә.

«1918 ел байлары бетерелгәннән соң, приказчиклары да бетте. Шулар артыннан «Аваз» да тукталды», – дип яза Исмәгыйль Рәмиев. Газетаның идарәханәсе һәм канторасы Казандагы «Болгар» мосафирханәсенең 28 нче номерында урнашкан була. Соңрак Тихвинский һәм Варламовский урамнары чатындагы Маркелычев йортына күчә.

Игътибарыгызга әлеге газетадагы кайбер язмаларны тәкъдим итәбез.

Гаскәри тәшкилат

Идарәмезгә алынган мәктүбкә *(хатка)* караганда, сугыш мәйданында 690 нчы полктагы мөселман солдатлары тарафыннан полк комитеты тәшкил ителгән вә аны 173 нче дивизия начальнигы тасдыйк кыйлган *(раслаган)*. Шул ук дивизия начальнигы үз кулы астындагы башка полкларда шундый ук комитетлар ясарга фәрман кылган. Дивизиядә дә шундый ук мөселман гаскәрләре комитеты тәшкил ителәчәк. Мөселман комитетыннан һәр полк советына – бер вәкил, дивизия советына дивизия комитетыннан бер вәкил сайланачак. Мәзкүр *(әлеге)* 690 нчы полктагы комитет эшкә керешкән вә беренче мәҗлесендә ошбу карар чыгарган: 1) җомга көннәрдә вә башка мөселман бәйрәмнәрендә мөселман солдатларын хезмәттән азат итәргә; 2) кич белән кычкырганда мөселман солдатларын руслардан аерым тотарга һәм үзләренчә гыйбадәт кылдырырга; 3) һәр полкта мелла *(мулла)* булырга тиеш. Мелла, гаскәр хезмәтеннән азат ителеп, околодокта торырга йибәреләчәк; 5) меллалыкка Мостафа Әхмәдовны куярга вә аны дини китаплар һәм мөселман киемнәре алу өчен Казанга йибәрергә; 6) һәр жалуния алганнан соң, полкта мөселман комитеты файдасына акча җыярга вә аңа кадәр җыелган 101 сумны комитетның баш сәрмаясе *(капиталы)* дип хисапларга; 7) комитетка 12 данә «Аваз», 12 данә «Йолдыз» һәм 6 данә «Ирек» газеталарын алырга.

Аваз. – 1917. – №8. – 27 май.

Хәрби комитеттан

Казанның хәрби мөселман комитеты тарафыннан хатиблар *(ораторлар)* йитештерер өчен ачылачак хатиблар курсы шимбә көн 27 нче майда ачылып, һәр көн иртә сәгать уннан лекцияләр укыла башлаячак. Курсларны идарә итүчеләр: **Хәлил Әбелханов, Габделгазиз Монасыйпов.**

Аваз. – 1917. – №8. – 27 май.

Провокатор

Сәүдә хезмәткәрләренең бюросында әгъза һәм «Мәгариф» матбагасының мөдире булган **Касыйм Туйбактин** Әстерхан охранкасында 1910 елдан бирле аена 75 сум жалуния бәрабәренә хезмәт иткән, имеш, дигән хәбәрләр йөри иде. Әстерхан мөселман бюросы бу хәбәрне тасдыйк итә *(раслый)*. Шул сәбәпле, сәүдә хезмәткәрләре, Касыйм Туйбактинны нәфрәт белән араларыннан чыгарып, аның исемен кырып ташлыйлар.

Аваз. – 1917. – №14. – 7 июль.

Кружка көне

Рамазан гаеденең икенче вә өченче көннәрендә Казан мөселман хәрби комитеты файдасына кружка белән иганә җыю булачак. Мөмкин кадәр туташлар һәм укучы яшьләребезнең дә катнашуы матлуб булганлыктан, хезмәт итәргә теләүче әфәнделәр һәм туташларның 28 июньнән башлап түбәндә күрсәтелгән урыннарда языла башлауларын үтенәмез. 1) Екатеринский урамдагы Казан мөселман хәрби комитетында; 2) Большой Мишчански урамда Садретдин Йосыпов йортында; 3) Бишбалтада Тулупофка урамында Әхмәдбаев йортында, Габдулла Исмәгыйлев йортында; 4) Пороховойда, Троицкий урамда Вильданов йортында; 5) Иске зират өстендә, **Кыйвам карый Зөлфәкаров** йортында.

Аваз. – 1917. – №14. – 7 июль.

Корылтайга вәкил

Эстәрлетамакның өяз Милли шурасы Учредительный Собраниегә өяз исеменнән беренче итеп мәшһүр мөхәррирләремездән социаль революционер **Галимҗан әфәнде Ибраһимов**ның кандидатурасын билгеләгән.

Аваз. – 1917. – №24. – 3 сентябрь.

Татар социаль революционерлар конференциясе

2 нче гомуми мөселманнар съездында Русиядә татар эсерларының оешмасы мәйданга чыкканы хакында язылган һәм революционерларның конференция ясаулары да әйтелгән иде. Конференциянең әле кайчан булачагы мәгълүм түгел, шулай булса да, сентябрь урталарыннан калмаска. Инде каралачак мәсьәләләр шулар: 1) Русиядә рәсми рәвештә татар социалист революционерлары партиясе тудыру; 2) гомуми социалист революционерлар программасын нигез итеп алып, хосусый үз хәятебездән *(тормышыбыздан)* туган аерым хосусиятләргә гаид *(караган)* маддәләрне арттыру; 3) моңарчы бергә эшләп килгән рус эсерларына мөнәсәбәт; 4) **аерым татар җөмһүрияте;** 5) милләт; 6) йир мәсьәләсе хакында арттырылачак маддәләр.

Аваз. – 1917. – №24. – 3 сентябрь.

Казан, Екатеринская урамы (хәзерге Тукай) Татар укытучылар мәктәбе

Учительский ышкулның уңайсыз хәле

Бу ел Татарский учительский ышкулның хәле бик уңайсызлыкка төште. Хәзинә хисабына кабул ителгән шәкертләрне пансионда тәрбия кылырга ышкулның акчасы юк. Ышкул идарәсе, акча сорап, Мәгариф вәзарәтенә *(министрлыгына)* мөрәҗәгать иткән иде. Һич тә җавап ала алмагач, Петроградка махсус вәкил йибәрде. Ләкин, вәзирләр алмашынган вакытка туры килү сәбәпле, барган вәкилләр дә рәтле эш чыгара алмады. Хәзерге көндә ышкулның язмышы билгесез хәлдә тора. 23 сентябрьдә шәкертләр җыелганнар иде. Аларга, ышкулда тотылмаячакларын әйтеп, фатир эзләргә куштылар. Бу ел Казанда бүлмәләр айга 50-150 сум торганлыктан һәм ашау-эчү нәрсәләре дә гаять кыйммәт булганлыктан, шәкертләрнең фатирларда торып укырга кулларыннан килми. Шул сәбәптән, шәкертләр таралып китәргә уйлыйлар. Әгәр дә Казанның зыялы мөселманнары катгый тәдбирләр *(чаралар)* кыйлмасалар, без иң мохтаҗ вакытта 80 кадәр учительдән мәхрүм булачакбыз*.

Аваз. – 1917. – №26. – 24 сентябрь.

Милли полклар хакында

قزانده
مسلمان اشچیلر قلوبی
نه اعضا بولوب یازلگز!
قلوبقه اورن آلندی. آطنه - اون کون اچنده آچیلادر.
یازلورغه ممکن: مسلمان سانسیالیستلاری کامیتیتنده (تیخوینسکی هم وارلامسکی
اوراملاری چاتنده‌غی مارکیلیچوف یورطنده) هر کون کیچکی ۷ دن ۹ غه‌چه.

«Мөселман эшчеләре клубы»на әгъза булып язылу турында игълан. Клуб 1917 елның 8 сентябрендә оеша.

Хәрби шураның рәисе **Ильяс әфәнде Алкин**ның телеграмына караганда, тиз көндә милли полкларны ясау хакында хөкүмәтнең рәсми приказы чыгачак икән. Бу шатлыклы хәбәрне чын күңелдән шатланып каршы аламыз.

Аваз. – 1917. – №26. – 24 сентябрь.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

---

* Шулай итеп, тюрколог-галим Вильгельм Радлов башлангычы белән 1876 елда ачылган, Шиһабетдин Мәрҗани укыткан данлыклы мәктәпнең эшчәнлеге туктатыла.

Мәмәтхуҗаның борынгы ташъязмалары

Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов

Татарстан Республикасы Югары Ослан районындагы Татар Мәмәтхуҗасы авылының көньяк тарафындагы басуда Казан ханлыгы чорына нисбәтле борынгы ике ташъязма (кабер ташы) саклана. Алар икесе бер чардуган эчендә. Берсенең (алга таба №1) өске өлеше сынык булса да, язуларын укырга мөмкин, ә икенчесенең (№2), шәкеле төзек булса да, язулары шактый җуелган. Әлеге истәлекләрне без 2018 елның көзендә һәм 2019 елның язында махсус барып өйрәндек. Укучылар игътибарына аларның текстларын һәм фоторәсемнәрен тәкъдим итәбез.

№1. Йөзәй Айбак улына куелган таш. 1548 ел

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1) [калә Аллаһу Тәгалә] вә ма [тәдри]

2) нәфсүн би-әйи арди тәмүтү вә калә Аллаһу Сөбханәһә

3) вә Тәгалә көллү нәфсин заикател-мәүт

4) тарих тукуз йөз иллик бишдә

*5) Айбак угылы Йөзәй мөхәррәм аенда**

6) дәре фәнадән дәре бәкага рихләт

7) ...

Уң ягында (күпертмә язулы):

1) калә ән-нәби гәләйһиссәлам әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти

Сул ягында (күпертмә язулы):

1) калә ән-нәби гәләйһиссәлам әд-дөнья сәгатүн фә-әҗгальһә тагатән

Арткы ягында (күпертмә язулы):**

1) Йөзәйгә бу ләүхне [гыялы ...] җан [бина кыйлды]

Үлчәмнәре: 120х59х15 см.

№2. Кемгә куелганлыгы билгесез таш. XVI гасыр уртасы

Алгы ягында (күпертмә язулы):

1-2) ...

3) заикател-мәүт ...

4) калә ән-нәби гәләйһиссәлам әд-дөнья ...

5) ... тарих тукуз

6-7) ...

Уң ягында (күпертмә язулы):

1) күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары

Сул ягында (күпертмә язулы):

1) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари

Үлчәмнәре: 96х46х18 см.

---

* Һиҗри 955 елның мөхәррәм ае 1548 елның февраль-март айларына туры килә.

** Арткы ягында, язудан тыш, бик нәфис бизәк-орнамент та ясалган.

СҮЗЛЕКЧӘ:

әд-дөнья мәзрагатул-ахирәти – дөнья – ахирәтнең иген кыры;

әд-дөнья сәгатүн фә-әҗгальһа тагатән – дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр;

әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, мәңгелек түгел – Аллаһның аңа әмере юк;

вә – һәм;

вә ма тәдри нәфсүн би-әйи арди тәмүтү – кеше үзенең кайсы җирдә үләчәген һич белмәс;

даре фәнадән даре бәкага рихләт – вакытлы дөньядан мәңгелек дөньяга күчте;

иллик – илле;

калә Аллаһу Тәгалә – бөек Аллаһ әйтте;

калә Аллаһу Сөбханәһә вә Тәгалә – һичбер кимчелексез һәм бөек Аллаһ әйтте;

калә ән-нәби галәйһиссәлам – Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламнәре булсын) әйтте;

көллү нәфсин заикател-мәут – һәр җан үлем ачысын татыр;

күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс йук карары – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, мәңгелек түгел – Аллаһның аңа әмере юк;

тукуз – тугыз.

Беренче таш

Икенче таш

Авылның гамәлдәге зиратында да гарәп язулы кабер ташлары саклана, алар XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында вафат булган кешеләргә куелган. Гомуми саны ике дистәгә якын булган әлеге ташларның уникесендәге язулар укыла, калганнарыныкы җуелган.

Нәсел җепләре Татар Мәмәтхуҗасына бәйле **Раил Рәис улы Касыймов** шушы авылның тарихи урыннарын кайгыртуга һәм чишмәләрен төзекләндерүгә үзеннән зур өлеш кертеп килә. Борынгы кабер ташларын өйрәнү дә аның соравы белән башкарылды, чөнки бу фидакяр милләттәшебез, аларның тарихи әһәмиятен яхшы аңлап, киләчәктә сакланышын тәэмин итәргә ниятли. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

Тарихи Чишмә һәм Зәй буйлары

Альберт Борһанов

Лениногорск шәһәренең «Юность» стадионы

Татарстанның Лениногорск районы, 1930 елда гына оешуына карамастан (1955 елга кадәр ул Писмән районы дип атала), шактый борынгы һәм бай тарихка ия. Төбәкнең елга үзәнлекләре белән челтәрләнүе, ерымнары һәм ерганакларының күп булуы кешеләрне чал заманнарда ук бирегә тартып китергән.

Район җирлеге аша Чишмә, Зәй елгалары һәм аларның Куак, Урман Чишмәсе ише бихисап кушылдыклары агып уза.

Чишмәләр саны ягыннан (270тән артык) Лениногорск районы Татарстанда беренче урынны тота. Төбәк файдалы казылмаларга да бай: нефть, битум, известьташ, доломит...

Районның дүрттән бер өлешен урманнар били, аларда имән, өрәңге, юкә һәм каен агачлары үсә. Биредә шулай ук 110 төрдән артык үсемлек бар, аларның 27се Татарстанның Кызыл китабына кертелгән.

Төбәктә 68 төр кош тереклек итә: тургай, бытбылдык, сиртмәкойрык, бөркет, мәче башлы ябалак, тукран... Имезүчеләр арасыннан үр куянын, төлкене, байбакны, көзәнне аерым атап үтәргә мөмкин.

Гомуми мәйданы 1843 квадрат метр тәшкил иткән җирдә 86 мең кеше гомер кичерә: татарлар – 52 процент, урыслар – 36 процент, мордвалар – 6 процент, чуашлар – 5 процент һ.б.

Язма чыганаклар һәм археологик табылдыклар раслаганча, IV-VII гасырларда ук бу җирләрдә күчмә һәм ярымкүчмә төрки кабиләләр яшәгән, XII-XV гасырларда борынгы бабаларыбыз дәүләт корган. Хәзерге татар торак пунктлары 16-17 нче йөзләрдә оеша башлаган. Урыс, чуаш, мордва халкының күпләп күченүе XVIII гасырга карый.

Борынгы торак пунктлар арасыннан Бәкер (Бәкер-Иштирәк), Сарабиккол, Иске Шөгер һәм XVIII гасырда нигезләнгән Яңа Писмән (хәзерге Лениногорск шәһәре) салаларын аерым әйтеп үтәргә кирәк.

Узган гасырның 20 нче елларына кадәр бу биләмә Бөгелмә өязенә кергән.

Лениногорск районы – археология, эпиграфика һәм архитектура җәһәтеннән аз өйрәнелгән төбәкләрнең берсе. Галимнәр мондагы борынгы, урта гасырлар һәм яңа заман тарихы эзләрен системалы рәвештә тикшермәгән диярлек. Кайбер очраклы табышлар һәм сирәк экспедицияләр генә искәрмә булырлык.

Әйтик, 1928 елда Шөгер бистәсе янындагы курган ачыла, аннан бронза чорына караган балчык савыт-саба чыга. 1955 елда Иске Шөгер авылы читендәге казу эшләре барышында юлыгылган савыт-саба исә Татарстан АССРның дәүләт музеена (хәзерге Милли музейга) тапшырыла. 1985 елда археолог Р.С.Габәшев тарафыннан берничә археологик һәйкәл табыла: имәнкискә мәдәнияте һәйкәле (V-XII гасырлар), Сарабиккол авылы янындагы һәйкәл һәм Спиридоновкага терәлеп торган курганнар. 1985 елда В.Н.Марков, Юлтимер һәм Воздвиженка авыллары тирәсендәге курганнарны ачып, бронза чоры керамикасына тап була.

«Язма чыганаклар һәм археологик табылдыклар раслаганча, урта гасырларда бу җирләрдә күчмә һәм ярымкүчмә ырулар яшәгән. Биредә тәүге татар торак пунктлары 16-17 нче йөзләрдә оеша башлаган.

Бераз соңрак, 1986 елда, М.Ш.Галимова Сарабиккол һәм Яңа Шөгер авыллары янында бронза һәм Алтын Урда чорларына караган табылдыкларга юлыга, аннан ары Бәкер шифаханәсе янындагы курганнарны исәпкә алып, теркәп куя.

«Археологические памятники Татарской АССР» (Казан, 1987 ел) китабы Лениногорск районында бары тик бер археология объекты – Шөгер курганы – булуын күрсәтә. «Археологические памятники Восточного Закамья» (Казан, 1989 ел) фәнни-экспедицияләр җыентыгында 11 археологик объект турында бәян ителә: бишесе – бронза чорына, берсе – имәнкискә мәдәниятенә һәм өчесе – Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда дәверенә карый. Калганнарының төгәл кайсы заманга каравы билгеле түгел.

«Свод памятников археологии Республики Татарстан» (Казан, 2007 ел) китабында да Лениногорск районының кайбер археологик объектларына кагылышлы мәгълүмат урнаштырылган.

Лениногорск районындагы тарихи-мәдәни мирасны өйрәнүгә бәйле янә берничә әсбапка тукталып үтәргә кирәк: Тимәш һәм Иске Шөгер авылларындагы 2 объект Р.Р.Салихов һәм Р.Р.Хәйретдинов нәшер иткән «Республика Татарстан: памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII-начало XX вв.)» (Казан, 1995 ел) китабында да урын алган. «Республика Татарстан: памятники истории и культуры» (Казан, 1993 ел) белешмәлегендә Лениногорск районының 13 объекты турында мәгълүмат бар.

Сарабиккол авылы зиратындагы эпитаграфик мирас

ТР ФАнең Тарих институты һәм КФУ хезмәткәрләреннән торган экспедиция (җитәкчесе – А.Ә.Борһанов) 2015 елда бу якларга килеп, элгәре мәгълүм булган һәм соңгы елларда гына ачыкланган археология объектларын тикшерү буенча зур эшләр башкарды. (Әйтергә кирәк, аларны оештыруда ул вакытта Лениногорск районы Башкарма комитетын җитәкләгән Н.Р.Залаков бик нык ярдәм итте.) Тикшерүләр нәтиҗәсе берничә фәнни мәкаләдә һәм конференция материалларында, шулай ук А.Ә.Борһановның «Древности Восточного Закамья (археологические, эпиграфические, историко-культурные памятники Юго-Восточного Татарстана» (Казан, 2017 ел) монографиясендә чагылыш тапты; Азнакай, Казан, Мәскәү шәһәрләрендә узган халыкара конференцияләрдә дә аерым фәнни чыгышлар һәм күргәзмәләр рәвешендә дөнья күрде.

Бу эшләр Лениногорск районында 4 илкүләм конференция уздыруга этәргеч бирде. Аларда галимнәр, белгечләр, төбәкне өйрәнүчеләр, укытучылар, музей хезмәткәрләре, ветераннар, мәктәп укучылары, матбугат вәкилләре һ.б. катнашып, археологик һәм эпиграфик табылдыкларга багышланган материаллар белән якыннан танышты. Лениногорск, Зәй-Каратай һәм Шөгер җирлегендә үткәрелгән бу чаралар туган якны өйрәнү мәсьәләләренә игътибарны арттырды, җирле музейларга, аларның эшчәнлегенә хәлкадәри фәнни-методологик ярдәмлек булды.

Бу юнәлештә, һичшиксез, эшне дәвам итү зарур. Соңгы елларда «кара эзләүчеләр»нең аерата активлашканын күрә торып (алар Лениногорскиның үзеннән дә, күрше Самара өлкәләреннән дә күпләп килә), бигрәк тә ашыгырга кирәк! Иске татар зиратларындагы эпиграфик объектларны өйрәнү эшен дә туктатырга ярамый. Болар барысы да, – әлбәттә, хакимият, галим-голамә, җирле үзидарә органнары һәм халык бергәләп, бер-берсен аңлап,

«

Иске татар зиратларындагы эпиграфик объектларны өйрәнү эшен дә туктатырга ярамый. Болар барысы да, – әлбәттә, хакимият, галим-голамә, җирле үзидарә органнары һәм халык бергәләп, бер-берсен аңлап, ярдәмләшеп эшләгәндә генә башкарып чыгарлык эшләр.

ярдәмләшеп эшләгәндә генә башкарып чыгарлык эшләр.

Җөмләдән, А.Ә.Борһанов җитәкчелегендәге экспедиция 2015 елда Тимәш һәм Сарабиккол авыл җирлекләрендәге кабер ташларын да тәфсилләп өйрәнде.

« А.Ә.Борһанов җитәкчелегендәге экспедиция 2015 елда Тимәш һәм Сарабиккол авыл җирлекләрендәге кабер ташларын да тәфсилләп өйрәнде.

Безнең мәгълүматлар буенча, Лениногорск районында 20 археологик объект исәпләнә, 13е бронза чорына карый. Шул ук чорга нисбәтле аерым курганнар һәм башка табылдыклар (нигездә, керамика) Бәкер, Воздвиженка, Писмән, Шөгер, Спиридоновка, Юлтимер һәм Яңа Шөгер авыллары янында да очрады.

Сарабиккол, Мөэмин-Каратай, Яңа Сережкино, Иске Писмән авыллары тирәсендә табылган урта гасыр объектлары да (имәнкискә мәдәнияте һәм болгар-урда чоры табылдыклары) игътибарга лаек.

Хәзерге Мөэмин-Каратай һәм Иске Куак авыллары читендәге, Чишмә елгасы буендагы борынгы (урта гасырга караган) Мөэмин-Каратай шәһәрлеге дә җәмәгатьчелекнең зур кызыксынуын уятырлык. 2015 елда уздырылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә, әлеге торак пунктның XIII-XIV гасырларда нигезләнүен икърар итәргә мөмкин. (Аңарчы, 2014 елда ук, җирле халык монда бихисап балчык һәм металл савыт-сабага юлыга; табылдыкларның бер өлеше Лениногорск төбәкне өйрәнү музеена тапшырыла, икенче өлеше шәхси коллекциядә яисә Яңа Сережкино авыл клубында кала.)

Мөэмин-Каратай шәһәрлегендә табылган археологик мирас

Сарабиккол мәктәбе директоры Гатина Сәлимә, археолог Альберт Борһанов һәм шагыйрь, педагог Таһир Шәмсуаров

Табылдыклар арасында тимердән ясалган кирәк-ярак шактый. Болар – ук очлары, йөгән, өзәңге, дага, ачкыч һәм йозаклар, металл савыт-саба кисәкләре, пинцетлар, кармаклар, энәләр, кадаклар һ.б. Бронза һәм бакырдан ясалган асма бизәкләрне дә санап узыйк: кыңгырау, йөзекләр, бизәнгечләр, көмеш каймалы күзге калдыклары... Балчыктан ясалган эшләнмәләр арасында орчык башлары, болгар-урда чоры керамикасы ватыклары бар.

Яңа Сережкино янында А.Н.Ванюков (шушы авыл кешесе) тарафыннан да Идел Болгарстаны һәм Алтын Урда чорларына караган берничә әйбер табыла: ук очлары, кадаклар, кармаклар, балталар, чылбырлар...

Лениногорск районында тарихи-мәдәни кыйммәткә ия тагын берничә һәйкәл бар. Алар арасында иң күренеклеләре – XIX гасырда Иске Шөгер авылында корылган мәчет, Иске Куак авылы чиркәве һәм Тимәш авылындагы атаклы шагыйрь, галим Габдерәхим Утыз-Имәни (1754-1834 нче елларда яшәгән) каберлеге.

Габдерәхим Госман углы башлангыч белемне туган авылы Утыз Имәндә (хәзерге Чирмешән районы) ала. Аннары Оренбургта укый. Белемен арттыру максатында соңрак Урта Азиягә һәм Әфганстанга юл тота. Габдерәхим Утыз-Имәни, туган якларына әйләнеп кайткач, Исләй (хәзерге Чистай районы), Сарабиккол һәм Куакбаш (хәзерге Лениногорск районы) мәдрәсәләрендә укыта. Ул алтмыш еллык гомерендә йөзгә якын хезмәт язып калдыра. Алар арасында шигъри әсәрләр, проза һәм фәнни язмалар бар. Һәммәсе дә XIX гасыр татар тормышында (һәм, һичшиксез, бүген дә) гаять зур урын тоткан иҗат җимешләре. Әдип 1834 елда әтисенең туган авылы булган Тимәштә вафат була.

Бүген Габдерәхим Утыз-Имәнинең төрбәсе – Лениногорск районының күз өстендәге кашы. Аның ишек өстендәге ак мәрмәр ташына мондый сүзләр уел-

Археологик казу эшләре

ган: «Бу урында татар халкының бөек шагыйре һәм мәгърифәтчесе Габдерәхим Утыз-Имәни әл-Болгари җирләнгән, 1754-1834». Төрбәнең үзәгендә – 73х31х16 см үлчәмендәге кабер ташы.

Диварда – шигъри юллар:

Йегет булсаң,
Йегетлек күргәз илгә,
Мәхәббәтлек путасын
Багла билгә.
Гаделлек кыл,
Ул имди әһле вафа,
Берәүгә бер тузан
Тик кылма җәфа.

Төрбә әйләнәсендә һәм авыл зиратында А.Ә.Борһанов тарафыннан 104 кабер ташы (XVIII-XX гасыр башы) исәпкә алынып теркәлде. Сарабиккол зиратында андый каберлекләрнең саны 537гә (XVII-XX гасырлар) җитте.

* * *

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: соңгы елларда җирле халык һәм эшмәкәрләр тарихи-мәдәни объектларны өйрәнү һәм саклау буенча изге гамәлләр кылса да, Лениногорск төбәген тарихи җәһәттән өйрәнү эше үзенең башлангычында гына әле. Районда һәм, гомумән, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәгендәге уникаль табигать объектларын һәм тарихи мирас һәйкәлләрен барлау буенча төп эшләр, һичшиксез, алда булыр дип ышанасы килә. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

Лениногорск шәһәре төзелүгә 65 ел

Рәгать Хөсәенов: «Лениногорск – минем өчен дөньяда иң яхшы шәһәр!»

*(Лениногорск муниципаль районы башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры **Рәгать Галиәгъзам улы Хөсәенов** белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** әңгәмәсе)*

– Рәгать Галиәгъзамович, җитәкчелек таланты һәр кешегә дә бирелми. Сүзне шуннан башлыйк әле...

– Әти-әнием Чирмешән районыннан. Әти – Түбән Кәминкәдән, ә әнием – Туймәтнеке. Әтием Галиәгъзам күпбалалы гаиләдән була. Аның җиде класс белем алуы заманы өчен гаять дәрәҗәле санала. 17 яше тулганда, ул сугышка качып китә. Аны, Мәскәү янында эләктереп, Смоленск янында окоп казырга җибәрәләр. Ә инде 1942 елда ул фронтка китә. Әмма 1943 елның азагында авылга аның һәлак булуы турында «похоронка» килә. 1944 елның яз башында көтмәгәндә генә кайтып төшеп, бөтен авылны шатландыра ул. Әтием беркайчан да дан-дәрәҗәгә омтылмады, әмма гел алгы сафта булды. Колхоз эшендә дә хезмәт куйды, ветврач, укытучы да булды. Сугыштан соң ул, авыл яшьләрен җыеп, Свердловскига алып барып, заводта эшләде. Ә инде Лениногорск шәһәре

төзелгәндә, ул бирегә кайтып төпләнә һәм нефтьчеләр арасында техснаб җитәкчесе, склад мөдире булып эшли. Соңрак сәүдә хезмәтенә – РАЙПОга күчә. Әтиемнең кылган игелекле гамәлләре күп булды. Шәһәр халкы да аны кадерләп-хөрмәтләп торды. Әтием белән горурланмый мөмкин түгел!

Әнием Кәмар нибары 4 класс белем алган. Хәзер аңа 95 яшь. Яшь вакытында ул әби белән дуңгыз фермасында, колхозда эшли. Гаиләдә олы бала буларак, сугыш вакытында бар авырлыкны үз җилкәсендә күтәрә. Әнием: «Без, ач яшәсәк тә, ачтан үлмәдек, бакчада мөмкин булганны үстереп, үләннәр җыеп ашадык. Сыер, үгез җигеп, утын да ташыдык, җир дә сөрдек», – дип искә ала әлеге авыр елларны. «Свинарка и пастух» – аның иң яраткан кинофильмы. Аларның бакча башында иске генә мунча бар иде. Шуннан ерак түгел – дуңгыз фермасы. Әнием әлеге мунчада дуңгыз балаларын юып, чистартып, аларны авырулардан саклап калды. Шулай итеп баш санын арттырды, дәүләт планын арттырып үтәде. Әниемне, яхшы хезмәтләре өчен, Күтәмәдән ат караучы бер чуаш егете белән Мәскәүгә ВДНХга да алып баралар. Шунда ул башкаладагы халык алдында саф татар телендә чыгыш ясый. «Свинарка и пастух» кинофильмы башлануга, әнием: «Бу безнең турыда!» – дип, экранга ябышып карый иде. Энесен һәм сеңлесен тәрбияләү, кеше итү дә аның өстендә булды. Әниемне бер белмәгән кешегә, Лениногорскидан ат белән килгән бабайга утыртып, әтиемә хатын итеп алып кайталар. Алар, гаилә корып, өч ир бала тәрбияләп үстерде.

Әнием, гомер буе гади хезмәттә эшләсә дә, чыгышы белән укымышлы нәселдән – мулла оныгы. Үзе дә намазын калдырмый. Туган телне яхшы белүем фәкать әниемнән килә. Әтиәнием шәһәр читендәге йортта гомер

«

Әнием, гомер буе гади хезмәттә эшләсә дә, чыгышы белән укымышлы нәселдән – мулла оныгы. Үзе дә намазын калдырмый. Туган телне яхшы белүем фәкать әниемнән килә.

буе мал, кош-корт асрап яшәде. Әти, эштән кайтып, без башкарырга тиешле хезмәтне бүлеп китә торган иде: кемгә печән чабарга, кемгә малларның астын тазартырга, кемгә су эчерергә эләгә...

Бар иде шундый заманнар: русча белмәгәч, шәһәр урамына чыгарга ояла идек. Рәис исемле якын дустым, безнең өйгә кереп, мине урамга, малайлар арасына өстерәп диярлек алып чыга, уйнаганда үзенең командасына ала. Мин, 2 класс бетергән малай, русча бер сүз дә белми идем. Шулай итеп урам малайлары арасында рус телен өйрәндем.

Хәтта шундый вакытлар да бар иде: руслар арасында татар телендә сөйләшергә уңайсызландык. Шулай бервакыт Самарага туганнарга кунакка баргач, балконда татарча сөйләшә башлаган идем. Олы абзыйның: «Тукта-тукта, урамда татарча сөйләшмә! Ә-ә-нә, күршедә руслар тора, алар яратмый!» – дип әйтүе хәтеремә уелып калган. Хәзер, Аллаһка шөкер, ике телдә дә курыкмыйча, оялмыйча сөйләшергә, чыгыш ясарга мөмкинлек бар.

Армиягә кадәр нефтьчеләр арасында автослесарь булып эшләдем. Аннан кайткач, әти янына РАЙПОга эшкә урнаштым. Мәскәү кооператив институтын сәүдә икътисады белгечлеге буенча тәмамладым. Уналты ел сәүдә эшендә эшләгәч, 2000 нче елдан хезмәт юлымны район администрациясендә дәвам иттем. Биредә Исхак Әюпович

Садриев хакимият башлыгы булып эшләде. Ул мине төрле җитәкче урыннарда эшләтеп, сынап, район хакимияте дәрәҗәсенә кадәр үстерде. Ышанычын белдереп, шушы юлга бастырганы өчен, остазыма рәхмәтем чиксез.

– Лениногорск районында, татарлар һәм руслар белән бергә, башка милләт вәкилләре дә күпләп яши. Районда аларның милли мәнфәгатьләре ничек кайгыртыла?

– Чуаш авылларында – чуашча, мукшы авылларында мукшыча укытабыз. Бер милләтнең телен дә чит-ят итмибез. 1990 нчы елларда Кавказ һәм Урта Азиядән күпләп күчеп килделәр. Халыклар дуслыгы йорты оештырып, аларга да махсус кабинетлар бирдек. Һәр милләткә үз мәдәниятен, телен балаларга өйрәтү һәм район сәхнәсендә күрсәтү мөмкинлеге бар. Райондагы диаспоралар белән махсус тәгаенләнгән ярдәмчем эшли. Ул, дирижер кебек, һәр милләт белән аерым шөгыльләнә, мине аларны борчыган мәсьәләләр белән даими таныштырып бара. Проблемаларны бергәләп хәл итәбез, матур итеп бәйрәмнәрен уздырабыз. Алар да безнең бәйрәмнәрдә бик теләп һәм яратып катнаша.

Миңа башка милләтләр белән уртак тел табуы аеруча җиңел, чөнки үземнең хатыным башка милләттән. Мукшы авылына барам икән: «О-о-о, безнең кияү килде», – диләр. Рус авылына киләм икән, янә: «Безнең кияү!» – диләр. Хатынымның әтисе – рус, әнисе мукшы милләтеннән. Шулай итеп, һәр милләт үз итеп, яратып каршы алгач, эшләве аеруча рәхәт.

Хатыным белән динне бүлмәдек. Мин Коръән мәҗлесләре, ашлар оештырам икән, ул да кушыла, табын әзерли. Үзе дә сеңлесенә барып, христиан бәйрәмнәрендә катнаша. Оныклар киләләр дә миңа: «Бабай!» – диләр. Хатынга: «Бабуля!» – дип эндәшәләр. Ике якны да тигез күреп, татарча да, русча да яхшы беләләр.

Башка милләтләр синең мәдәниятеңне, динеңне аңлый һәм хөрмәт итә икән, бу – зур тырышлык һәм хезмәт нәтиҗәсе. Хатынга: «Мин сезнең дингә каршы килмим, үз динегезне, телегезне яратыгыз!» – дим. Район башлыгы буларак, чиркәүгә кереп, андагы кешеләрне бәйрәм белән котлыйм. Соңыннан халык: «Менә татар егете килеп, безне бәйрәм белән котлады!» – дип, зурлап искә ала. Анда рус кына түгел, чуаш, мукшы, әрмән, грузин һәм башка милләт кешеләре дә килә. Алар барысы да минем райондашлар. Һәркайсына хөрмәтем һәм ихтирамым чиксез зур.

«

Чуаш авылларында – чуашча, мукшы авылларында мукшыча укытабыз. Бер милләтнең телен дә чит-ят итмибез.





«

Шәһәребезнең 11 нче гимназиясендә татар телендә укытуга өстенлек бирә башлыйбыз. Бу авыллардан Лениногорскига күчеп килгән гаиләләр өчен аеруча кулай булыр дип уйлыйм.

Шәһәребезнең 11 нче гимназиясендә татар телендә укытуга өстенлек бирә башлыйбыз.

Бу авыллардан Лениногорскига күчеп килгән гаиләләр өчен аеруча кулай булыр дип уйлыйм. Безгә, киләчәк буын татар телендә сөйләшсен өчен, бар мөмкинлекне булдырырга кирәк. Бу – мәдәниятебезнең һәм киләчәгебезнең нигезе. Татарлар аңга килеп, үз балаларын әлеге мәктәпкә биреп, шунда чын милләт балалары тәрбияләсеннәр иде. Биредә үк кадетлар һәм шахматчылар сыйныфлары да эшли. Рус егетләре дә, кызыгып килеп, татар телен өйрәнсеннәр иде. Миңа калса, мондый милли мәктәпләр Татарстандагы һәр шәһәр һәм район үзәгендә булырга тиеш. Алар заманча, полилингваль булсын иде.

– Лениногорск дию белән, нинди мәшһүрләребезне искә алыр идегез?

– Язучы, «Батырша» романының авторы Җәмит Рәхимов! Аның хатыны Галия апа әле дә бик актив. Очраган саен, минем янга килә дә: «Менә шушы балаларны татар теленә өйрәттем, менә шуларны намазга бастырдым!» – дип, гел шатландырып тора. Хәзерге көндә Кәркәле мәктәбе Җәмит Рәхимов исемен йөртә. Габдерәхим Утыз-Имәни дә Шөгердә яшәгән, Тимәш авылында вафат булган. Бу авылның зиратында аның төрбәсе һәм кабер ташы бар. Ризаэддин Фәхреддин дә яшьлегенең иң матур елларын Түбән Чыршылы авылында уздырган, шунда мәдрәсә оештырып, шәкертләр тәрбияләгән. Татарстан Республикасының гимны якташыбыз Рамазан Байтимеров сүзләренә иҗат ителгән. Академикларыбыз Индус һәм Энгель Таһировлар – Иске Шөгер авылыннан. Профессорлар Рафаэль һәм Рамил Вәлиевләр дә – безнең район кешеләре. Аларның әтиләре Миргасыйм Гали улы Вәлиев районыбызда данлыклы укытучы, җитәкче иде. Якын дустым Римма Атлас кызы Ратникова да Юлтимердә туган. ТР Дәүләт Советында беренче чакырылыштан башлап эшләде, озак еллар Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинның урынбасары булып торды ул. Көрешкән саен, райондагы хәлләр, туган авылы белән кызыксынып, кайгыртып тора. Нефтьчеләр арасында да мәшһүр шәхесләребез бик күп.

– Түбән Чыршылы авылында булып, андагы табигатьне күргәч, күңелемә: «Бу – Татар Швейцариясе», – дигән уй килде. Андагы таулар, болыннар, урманнар искиткеч гүзәл! Калкулыкларда байбаклар тезелешеп утыра. Сине күргә, алар бер-берсенә хәбәр сала башлыйлар... Сез шушы игелекле җирнең кадерен белеп яшисез!

– Безнең төбәк – иң матур як! Биредә Урал тауларының итәге башланып китә. Дөрес, халыкның гына менталитетын, туган телгә, туган җиргә карашын үзгәртергә кирәк. Күптән түгел Чехиядә булдым. Анда агачлар арасын ничек яхшы чистарталар! Кисеп алсалар, шундый ук яңа агач утырталар. Һәр агачның үз «паспорт»ы, тамгасы бар. Безгә әле мондый дәрәҗәгә җитәргә бик ерак! Дөрес, Татарстанда халык бик уңган һәм тырыш. Киләчәктә без дә моңа ирешербез дип өметләнәм.

Үземнең район белән горурланам. Монда эшләвемә бик шатмын! Лениногорск – минем өчен дөньяда иң яхшы шәһәр! ■

Бәхет биргән авылым

3 сентябрьдә Лениногорск районының Зәй-Каратай авылы мәктәбендә Бөтендөнья татар конгрессы һәм район хакимияте төбәк тарихын өйрәнүгә багышланган конференция уздырды. Фәнни чараның темасы «Лениногорск районында һәм көньяк-көнчыгыш Татарстанда кеше һәм табигать. Зәй-Каратай авылы, Шушма-Зәй табигый-географик һәм тарихи-мәдәни зонасы: тарих һәм мәдәният проблемалары» иде.

Фоторепортажны тулысынча ***beznenmiras.ru*** *сайтыннан карарга мөмкин.*



«Хикмәт белән эшләргә кирәк!»

Районга хакимият башлыгы булып Рамил Хәмзә улы Муллин килгәч, Мөслим сизелерлек үзгәрде. Урамнар, парклар заманча итеп төзекләндерелде, «Кояшлы Ык» ландшафт паркы, «Йөрәк» скверы, «Фестиваль аланы», амфитеатр, балалар мәйданчыклары, «Печән базары» мәйданы, заманча бассейн, китапханә, музейлар һәм «Батырлар йорты» барлыкка килде. Мөслим гимназиясендә, лицеенда һәм Габдулла Тукай исемендәге урта гомуми мәктәбендә милли мәгариф һәм тәрбия юнәлешендә зур эшләр башкарыла.

21-22 сентябрьдә Мөслимдә Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре узды. Кунаклар, район белән танышканнан соң, «Тел. Милләт. Дин», «Тел һәм әхлак» темаларына багышланган «Түгәрәк өстәл»ләрдә фикер алышты.

Данил Салихов, *ТР Язучылар берлеге рәисе:*

– Милләтне әдәбият һәм дин саклап калган. Безгә телне саклау мәсьәләсендә башка милләтләр белән берләшергә кирәк. Һәр милләт үз телендә белем алуны сорасын иде. Бу бит безнең халыкка гына чабылган балта түгел! Татарга бәйле һәрнәрсә өчен көрәшергә тиешбез!

Төрек, кыргыз, үзбәк һәм казакъ телләрендәге иң матур язмаларны да балаларга һәм әти-әниләргә тыңлатырга кирәк. «Син балаңны бу телләрне аңларга ачкыч булган телдән –татар теленнән мәхрүм итмә», – дип әйтик без аларга. Бу милләтләр хәзер үсештә, әмма алар белән киләчәктә рус түгел, ә татар телен белгәннәр генә аралаша алачак!

Хатыйп Миңнегулов, *профессор:*

– Иң беренче нигезгә куелырга тиешле нәрсә – урта белемне үз телебездә алу. Кызганыч, татар телен тел-әдәбиятны укытуга гына кайтарып калдырырга телиләр. Әмма татар теле укытучылары гына тел мәсьәләсен хәл итә алмый. Мөмкин булган кадәр башка фәннәрне дә үз телебездә укытырга кирәк. Моның дистә еллар буе тупланган бай тәҗрибәсе бар!

Ата-аналарның күбесе милли мәсьәләдә маңкорт. Бигрәк тә шәһәр шартларында татар ата-аналары белән эшләү актуаль. Милләтнең киләчәген үзебезнең шәхесләр хәл итә. Халкыбыз хакында башка беркем дә кайгыртмаячак. Үзебез янмасак, үзебез көймәсәк, үзебез тырышмасак, алга китеш булмаячак!

Тәлгат Галиуллин, *профессор:*

– 11 сыйныфны бетергәндә БДИны татар телендә тапшыруга рөхсәт ала алмасак, тел турында сөйләшүләрдән бернинди файда булмаячак. Һәр районда диярлек татар телендә эшли торган педагогика, аграр яки медицина колледжлары булсын иде. Шул уку йортын бетергәннәр турыдан-туры югары уку йортларына керә алсын.

Без, татар дөньяның төрле илләрендә яши, дип мактанырга яратабыз. Араларында зур дәрәҗәләргә ирешкәннәр дә күп. Ник шунда берсе Европарламентка кереп: «Ни өчен тулы геноцид, милләтләрне бетерү сәясәте бара?» – дип, безнең проблемаларыбыз турында сөйләми? Күпме генә изсәләр дә, татар халкы яшәячәк һәм яшәргә тиеш!

Миләүшә Хәбетдинова, *галимә һәм тәнкыйтьче:*

– Хәзерге гаиләләрдә әбиләр юк, күбебез индивидуаль яшибез. Әбиләр киткәч, мәдәният тә китте! Әбиләр урынына татар теле укытучысы калды. Нинди генә мәйданчыклар булмасын, без анда үз мәдәниятебез, әдәбиятыбыз турында сөйләргә тиеш! Тел, милли символлар эшләргә тиеш! Китапларда, театрларыбызда, паркларыбызда милли бизәкләр күбрәк булсын иде! Бүген балалар фото, фильм төшерергә ярата. Бу өлкәгә дә татар телен кертергә кирәк! Татар телендә актуаль белем булырга тиеш. Татар, хәйләкәр булып, һәр җирдә үз эшен эшләсен! Сабыйларыбызга татар әдипләренең балалар өчен язган иң яхшы китапларын укытыйк. Нәкый Исәнбәтнең балалар өчен язган затлы-зәвыклы китаплары бар!

Ильяс хәзрәт Җиһаншин, *«Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры:*

– Мәдрәсәнең 30 еллык эшчәнлегендә уку фәкать татар телендә генә бара. Уку йортында телебезне беркем дә тыймый. Берәүнең дә, килеп: «Ник син татар телендә укытасың?» – дип әйткәне юк. Кайсы өлкәдән генә имам җибәрүне сорамасыннар, иң беренче чиратта, шәкертнең татар телен белүен таләп итәләр.

Тел милләткә бәйле булса, әхлакның дингә бәйле икәнен беләбез. Дин әһелләре, язучылар, дәүләт җитәкчеләре бердәм, үзара тотынышып эшләгәндә генә, киләчәгебез булыр. Татар классикларын, әдәбиятын белмәсәң, татар телендә өйдә сөйләшүдән генә мәгънә юк. Мөслимнең урамнарында, юл буйларында пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең хәдисләре язылган такталар куелган, мәктәпне гарәби хәрефләр белән язылган Тукай шигырьләре бизи. Милли мохит булдырылган. Бу бит Аллаһы Тәгаләнең Мөслим җиренә биргән нигъмәте! Әлеге казанышларны республикабызга үрнәк итеп күрсәтергә кирәк!

Нияз хәзрәт Сабиров, *«Апанай» мәчетенең имам-хатыйбы, тарих фәннәре кандидаты:*

– Телгә битарафлык бай мирасыбызны белмәүдән килә. Әгәр дә меңьеллык язма мирасыбызны өйрәнсәк, телгә мәхәббәтебез артачак кына. Туган телебезне аралашыр өчен генә түгел, ә әдәби хәзинәләребезгә төшенер өчен дә өйрәнергә кирәк. Аллаһка шөкер, халкыбыз китаплы милләт.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә: «Минем кушканнарымны үтәсәгез, тыйганнарымнан тыелсагыз, мин сезгә бәрәкәт бирәчәкмен, сезне саклаячакмын», – ди. Телне саклау – Аллаһы Тәгалә кушканны үтәү ул. Әгәр дә без Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтибез икән, Ул безгә, һичшиксез, ярдәм итәчәк һәм без милләт буларак сакланып калачакбыз.

Рамил Муллин, *Мөслим муниципаль районы башлыгы:*

– Бүген Мөслимне, авылларны төзекләндерү буенча зур эшләр башкарыла, әмма рухи дөньябыз сай. Җәйләрен шәһәр балалары күпләп авылга кайтты. Ләкин кайсыгыз, шул балаларны җыеп*, дини һәм милли җәйге лагерьлар оештырды? Кем безгә Аллаһның барлыгын, берлеген татар телендә җиткерергә, татарча сөйләшергә комачаулый? Татар китабын укуны кем тыя? Берәү дә комачауламый! Һәрнәрсәне хикмәт белән эшләргә кирәк. Без зур сәяси мәсьәләләргә батабыз да шуның ширмасы артына кереп качабыз! Дәүләтне, депутатларны гаепләргә керешәбез. Ә үзебез нәрсә эшлибез? Газиз балаларыбызга вакыт бирәбезме? Әти-әни буларак алар белән аралашабызмы? Әгәр дә без балаларыбыз алдына зур максатлар куймасак, аларга төпле тәрбия бирмәсәк, безнең киләчәгебез юк. Кеше ләззәтне аракыда, зина кылуда түгел, ә китап укуда, гыйлем-тәрбиядә табарга тиеш. Мөмкин булганча милли чаралар үткәрик. Битараф булмыйк! Татар һәрвакыт басылган, әмма ул хикмәтле халык булган. Шул сәбәпле генә дин, тел сакланып калган. Бүген дөньяның нигъмәтенә баттык, әмма хикмәт җитми.

Кешенең эчке дөньясы һәрвакыт бер, бары тик заманның инструментлары гына башка. Аллаһы Тәгалә безне бу заманга китергән икән, димәк, юкка түгел! Безнең фани дөньяда үз вазыйфабыз бар. Алдыбызга куелган бурычны ихлас күңелдән башкарсак иде. Шул очракта гына нәтиҗәләргә ирешербез, бәрәкәт тә булыр, иншәАллаһ.

Җәлил хәзрәт Фазлыев, *ТРның баш казые:*

– Туган тел – безнең үзгәрми торган тәкъдиребез. Ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән. Без аны сайлый алмыйбыз. Кыямәт көнне: «Син татар булдыңмы? Кайда тудың? Нинди телдә сөйләштең?» – дип соралмаячак. Әмма: «Син туган телеңне, туган җиреңне саклау, матурлау, әти-әниеңнең догасын алу өчен нәрсә эшләдең?» – дип соралачак.

Бер-беребезгә: «Ничә онычың белән татарча сөйләшәсең?» – дип сорау бирик. Бер әүлиядән: «Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте кимесен өчен нәрсә эшләргә кирәк?» – дип сораганнар. Ул: «Зарлан!» – дигән. Безнең зарланудан гына тел алга китә алмый! Ибраһим галәйһиссәламне утка ягарга җыенгач, бер кошчык, аны сүндерер өчен, томшыгы белән су ташый, башкалары, юләр, дип, аннан көлеп утыралар икән. «Син утны сүндерү түгел, сүрелдерә дә алмыйсың!» – дигәннәр аңа. Ул: «Әлбәттә, мин берни үзгәртә алмыйм, әмма Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә янына баргач, ут сүнсен өчен көчемнән килгәнне эшләдем, диярмен», – дип җавап биргән. Шулай итеп, безгә дә көчебездән килгән кадәр тырышырга кирәк. Әлбәттә, кешеләр дә, милләтләр дә, хәтта ноталар да тигез түгел. Һәркем үзенә бирелгән вазыйфаны Аллаһы Тәгалә риза булырлык итеп башкарсын иде!

Җир йөзендә бер генә проблема бар: ул – камил әхлаклы кеше тәрбияләү. Җир йөзендә бер генә төп һөнәр бар: ул – әти-әни булу. Башка һөнәрләр шуңа ярдәм генә итә. Бала тәрбиясе дигән нәрсә безнең барыбызны да берләштерә, бер урынга туплый ала. Һәркем үзеннән бераз гына булса да яхшырак балалар тәрбияләп калдырырга тиеш.

---

* «Түгәрәк өстәл»дә Мөслим районының мәктәп директорлары, авыл советы рәисләре дә катнашты. – ***Ред.***

*Фоторепортаж белән **beznenmiras.ru** сайтыннан танышырга мөмкин*

Фоат Садриев, *Татарстанның халык язучысы:*

– Без яңа җәмгыятьне төзедек, әмма ул башыннан ук урлашу белән башланды һәм бу бүген дә дәвам итә. Шул шартларда без әхлаклы балалар тәрбияләргә тиеш. Яхшылык – яхшылык белән генә, мәхәббәт – мәхәббәт, вөҗдан – вөҗданлылык белән генә тәрбияләнә! Бала шуларны күреп үсәргә тиеш. Без бүген бөтен җәмгыятьне тәрбияли алмыйбыз, ләкин мәктәптә шушы атмосфера булырга тиеш. Илнең бүгенге атмосферасы безгә әхлак тәрбиясе бирерлек дип әйтә алмыйм. Әлбәттә, дин әһелләре, укытучылар зур эшләр башкара! Без укытучыларны әнкәйләрдән дә ныграк ярата идек. Алар безне игелек белән тәрбияләде.

Зиннур Мансуров, *Татарстанның халык шагыйре:*

– Бездә өч баскыч бар: гаилә, балалар бакчасы, мәктәп. Соңгы 30 елда шушы өч баскыч та тетрәнү кичерде. Сабый бала ана теленә бик тә якын, әмма бездә аны туган телдән читләштерүче гаиләләр күбәйде. Мәскәүдән килеп, безгә берәү дә баланың теле русча ачылсын дип әйтми. Әни дә, балалар бакчасындагы тәрбияче дә, мәктәп укытучысы да үзен милләт анасы итеп тоярга, милләт баласын тәрбияләргә тиеш!

Зиннур Мансуров

Бердәнбер

Бәни адәм сайлый алмас ана затын,
Сайлап алмый тәнгә иңәр җанын да.
Безнең башка сыймый торган серле хисап
Башкарылыр гарше әгъля янында.

Туган илне сайлап алу мөмкин түгел –
Шушы хакта элгәрләрең яд кыла.
Ватан хакы җиде баба каны белән
һәрбер терек күзәнәккә языла.

Милләт телен сайлау ирке була алмый,
Сине варис санар өммәт бердәнбер.
Саташмагыз, карышмагыз, кизәнмәгез:
Ана, Ватан, телне Аллаһ биргәндер!

Харис Камалиев, *эшкуар һәм галим:*

– Быел җәй көне биш оныгымны зиратка алып бардым. Аларга: «Монда минем бабайның, әтинең һәм әнинең каберләре», – дидем. Шунда оныгым: «Нишлибез?» – ди. Моның кулына пумала тоттырдым да чардуганны буяттым. Әнисе, киемнәрен күрде дә: «Жалко!» – ди. Мин: «Жәлләмә! Ул, карт бабасының чардуганын буяп, зур эш башкарды», – дидем.

Авылымның тарихын өйрәнә башлагач, бабамның кулак булганын белдем. Кулак бит ул мескен түгел, ә булдыклы, төпле кеше! Оныкларны зиратка алып барып, каберләрне күрсәтсәк, аларның күңелендә горурлык, ата-баба рухына дога кылу теләге уяныр иде. Татар телен диннән аерып өйрәтеп булмый!

Хезмәт тәрбиясе дә мөһим. Агроном буларак, бакча эшен бик яратам. Быел җәй оныгыма җир кишәрлеге бүлеп бирдем дә шунда җиләк һәм кыяр үстерергә куштым. Бу бервакыт: «Бабай, бабай, минем җиләк кызарган, ә синең җиләгең кызарганмы соң?» – ди. Балалар хезмәт ярдәмендә матурлыкны тудырырга өйрәнә. Матурлыкны яраткан кешенең күңеле саф, туган телгә дә мәхәббәте була. Матурлык аша кешене үзгәртергә, матурлык аша инсанны тәрбияләргә мөмкин. Кешенең мие, уй-фикер агышы үзгәрә... Мөслимдә без моның бик яхшы мисалларын күрдек. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов


Токио. XX гасыр башы

Токогава китапханәсе

Японнарда мәгарифкә хезмәт итүне бар кеше дә үзенә изге вазыйфа итеп кабул иткән. Маркиз Токогава да шундыйлардан. Хөрмәтле укучыларым, биредә сезнең игътибарыгызга бу кешенең милләте өчен ачкан китапханәсе турындагы мәгълүматны тәкъдим итәргә уйлыйм.

Китапханәнең бинасы нәфис сәнгать үрнәге дип атарлык архитектура ысулы белән төзелгән. Моның бары тик бинасы өчен генә дә 300000нән артык йен сарыф ителгән, бу кырык мең лира дигән сүз. Хәзерге көндә берьеллык чыгымы исә 24000 йен тәшкил итә икән. Китапханә бөтен кешегә дә бертигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтә, иртәдән кичкә кадәр ачык. Уку, күчереп алу өчен бөтен мөмкинлекләре бар, хәтта бушлай кәгазь дә бирәләр.

Китапханәдә әлегә 60000нән артык китап бар. Күбесе – үткән гасырга караган матур китаплар. Китапханә хезмәткәренең әйтүенә күрә, биредә бу гасырга караган китаплар бик аз очрый. Борынгы әсәрләр арасында Кытай каһанлыгында яшәгән кешеләр тарафыннан язылган кулъязма әсәрләр дә урын алган.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Китаплардан тыш, китапханәдәге нәфис сәнгать әсәрләре рәтендә моннан 300 елдан артык элек Кореяда бронзадан коелган 24 сандык матбага (типография) хәрефләре дә бар. Бу хәрефләр бит-бит бәйләнгән һәм һәр сандыкка алты бит салынган. Китапханәдә әлеге хәрефләр белән басылган 50 том китап та бар иде.

Моннан шул аңлашылды: өч гасырдан артык элек Кореяда матбугат булган икән.

Мондый борынгы әсәрләр Япониядә бик күп. Хәтта кайбер авылларда да музей кебек җирләр бар. Минем фикеремчә, мондый борынгы әсәрләрнең саклануында да милләтнең алга баруы, үсеше өчен ниндидер бер чара булуы ихтимал. Ник дигәндә, кеше, боларны күргән саен, бүгенгенең үткәне дә булганын искә төшерә. Аннан милли хисе көчәя, тырышып хезмәт итүенә сәбәп була.

Акча бастыру йорты

Японнарның акча бастыру, акча сугу йортлары да искиткеч. Токиода урнашкан акча бастыру йортында бары тик кәгазь акча, затлы кәгазьләр, төрле-төрле ябыштыргыч тамга кәгазьләре, почта маркалары һәм акча урынына йөри торган кыйммәтле кәгазьләр – барысы да монда басыла. Алтын һәм көмеш акчаларны исә Киото шәһәрендә сугалар икән. Мин Токиодагы акча бастыру йортында гына булдым. Биредәге матбагаларның басу машиналары барысы да иң яңа система машиналары иде. Бу акча басу йортында 2400дән артык эшче эшли. Боларның чирек өлешен генә ир-ат тәшкил итә, калганнары хатын-кыз икән. Барысы да япон хатын-кызлары, чит ил кешесе юк. Бу акча басу йортындагы арулык мине шаккатырды. Биредә эшләүче эшчеләр һәм хезмәткәрләр башка фабрикаларда, эш җирләрендә эшләүчеләргә һич охшамаганнар иде. Мәктәп укучылары диярсең: шундый тәрбияле, шундый мөлаемнар!

Кытай хөкүмәте акчасы һәм кыйммәтле кәгазьләренең барысын да японнар бастырып чыгара икән. Болар аерым бер бүлемдә басыла, ләкин эшчеләр, хезмәткәрләр арасында кытайлардан беркем дә юк. Бары тик хәзинә бүлемендә бердәнбер кытай кешесе бар, кабул итү-тапшыру эшләре хезмәткәре икән.

Корея акчасы да монда басыла. Корея акчасы нәкъ Япония акчасы кебек. Бары тик өстендә корея телендә берничә сүздән гыйбарәт язу гына бар.

Японнарда өйләнү хәле һәм ир-хатын хокукы

Японнарда тормыш күп ягы белән гади һәм, Көнчыгыш милләтләренең гадәтләренә һәм ысулларына туры килгәнчә, өйләнү дә бик гади: ике як ата-ананың ризалыгына бәйле. Әйе, японнарда хиҗаб[1] юк, хатын-кыз шактый ачык киенә. Тик ирләр белән хатыннар Көнбатыш халыкларындагы дәрәҗәдә ачылып чәчелмәгән, тугарылмаган. Хатын-кыз карашында ир-атның билгеле бер урыны бар, хатыннар ирләргә һәрвакыт хөрмәт белән карарга мәҗбүрләр. Хатын өй эчендәге эш-хәрәкәтендә һәм яшәү рәвешендә беркадәр ирекле, ләкин ире рөхсәт итмәсә, ата-анасы йортына да бара алмый. Үз өендә дә хәтта кунаклар белән бергә утыра

[1] Хиҗаб – гарәп телендә күпмәгънәле булган сүзнең төп мәгънәсе – «пәрдә, япма». Башка халыкларда, күбесенчә, хатын-кызның бөтен гәүдәсен диярлек каплый торган кием мәгънәсендә кулланыла (тәрҗ. иск.).

алмый. Ире рөхсәт итсә, утыра ала, тик тагын да шул ук әдәп киртәләре эчендә калырга тиеш.

Өйдә бөтен эшне хатын-кыз башкара. Ни кирәк булса, шуны базарга барып алучы да – хатын. Кер юу, идән юу – һәр хатынның вазыйфасы. Кыз атасы-анасы ризалыгыннан башка, үз теләге белән генә кияүгә чыга алмый.

Мин Япониядә яшәгән вакытта илнең иң зур миллионеры Йуасатиның улы Хедийе бик чибәр, бик кыю, 28 яшьлек егет иде.

Бу егет Итанкати Тайски исемле бер фәкыйрьнең кызына өйләнергә теләгән. Тикава исемле бу кыз 17 яшендәге бик чибәр кыз иде. Кыз үзе дә, барлык туган-тумачасы да риза икән, тик кызның атасы ризалык бирмәгән дә, никах булмады.

Бу хәлне ишетеп, «Хоти Шимбон» газетасы мөхәррире үзе барып, кызның атасын күреп сөйләшкән һәм: «Ни өчен кызыгызны фәлән улы фәләнгә бирмисез? Сәбәбе нәрсәдә?» – дип сораган.

Кызның атасы: «Мин баламны акчага сатмыйм, үз капкабызга ярашлы кеше булырга тиеш», – дип җавап биргән. Менә бу хәлдән дә аңлашылганча, ата-ананың ризалыгы булмаса, никах та булмый.

Бу вакыйга турында газеталарда укыганнан соң, мин дә бу кеше янына, аның белән күрешеп сөйләшергә киттем. Чыннан да, фәкыйрь кеше иде, ләкин табигате белән затлы булуы, эчке зыялылыгы йөз-кыяфәтеннән аңлашылып тора иде.

Японнарда никахка охшаш йола бар. Менә шуны укыту бары тик ата-ана ризалыгы белән генә башкарыла. Бу яктан безнең йолабызга охшап тора. Тик японнарда никах өчен кызның яше 15 белән 20 яшь арасында булуы шарт. 15 яшеннән кечерәк кыз бала өчен никах рөхсәт ителми. 20 яшеннән олырак кыз өчен, ише чыкса, ата-ана ризалыгы шарт булып тормый.

Ирнең хатынына карата булган хокуклары

Хатынының эш-хәрәкәтеннән ир һәрвакыт хәбәрдар булып тора. Иренең рөхсәте булмаса, хатын бернинди мөгамәләдә була алмый. Бала тәрбияләү – ананың бурычы. Хатын, иренең рөхсәте булмаса, хәтта үз мөлкәтен дә тота алмый. Хатынның нафакасы[2] ирнең бурычы булып саналмый, мөмкинлеге булса, хатынын эшләтми яшәтә, булмаса – мәҗбүри түгел. Ир икенче хатынга өйләнә ала. Беренчесенең нафакасын тәэмин итеп, аны аера да ала. Бу очракта ике якның да ризалыгы алына, ике як ата-ана хөкем чыгара. Япон хатыннарының Аурупа хатыннары кадәр үк иреклe түгеллеге хак. Шул ук вакытта безнекеләр кадәр үк бикләнгән дә түгел. Гаиләле кешеләр арасында намуслылык, сафлык бик көчле саклана, әмма гаиләсе булмаганнар арасында әдәпсез хатыннар да күп очрый икән. Хәтта алардагы әдәпсезлекнең дә чиге-чамасы канун белән саклана икән.

> «
> **Японнарда никахка охшаш йола бар. Менә шуны укыту бары тик ата-ана ризалыгы белән генә башкарыла. Бу яктан безнең йолабызга охшап тора.**

[2] Нафака – гарәп телендә «(акча) тоту, сарыф итү» дигәнне аңлаткан бу сүз ислам дөньясында «ризыклаными өчен акча» мәгънәсендә, ире тарафыннан (ире сугышта вафат булса, мәсәлән, хөкүмәт тарафыннан) хатынына ашау-эчү, яшәү өчен түләнә торган акча мәгънәсендә кулланыла (тәрҗ. иск.).

Токио. XX гасыр башы

Элеккеге башкала – Киото

1868 нче – Императорлык елына кадәр Япониянең башкаласы Киото шәһәре булган. Бу шәһәрдә 400000гә якын кеше яши. Императорның сарае да ничек булган шулай саклана. Биредә, күпсанлы лицей мәктәпләреннән тыш, бер югары мәктәп тә бар.

800 – будда гыйбадәтханәсе, 80 Шинто[3] гыйбадәтханәсе бар. Бөтен япон императорларының каберләре бу шәһәрдә. Соңгы ике мең елдан артык вакыт эчендә император булып торган шәхесләрнең каберләре билгеле икән. Японнарның ышануына күрә, дөньяда шулчаклы озак вакыт яшәгән династиянең исемнәре һәм каберләре билгеле булу япон императорларыннан башка берәүгә дә насыйп булмаган. Императорда илаһилык сыйфаты бар дип санауның төп дәлиле дә бу икән. Моҗохито Кутай Саме, Тинси Саме династиясенең каберләре бөтенесе Киото шәһәрендә саклана. Боларның һәрберсенә аерым-аерым баралар, карыйлар. Саме – илаһилык сыйфаты. Аллаһ мәгънәсендә, Ками Саме, диләр.

Мин Киото шәһәрен дә гиздем. Бу үзәк булып тора, аңа якын урнашкан бик мәшһүр шәһәрләр бар. Болар – Коба, Авасаки, Нара шәһәрләре.

Киотога кадәр Нара шәһәре Япониянең башкаласы булып торган. Ул хәзерге көндә кечерәк кенә шәһәрчек булып калган һәм бик иске. Биредә Гайсә туганнан соң 607 ел үткәч салынган бер чиркәү бар. Борынгы заманнарда бу шәһәргә, «Наранодай Боҗо», дигәннәр. Бу шәһәрләрнең барысын да берәм-берәм карап йөрдем. Бик күп кеше белән таныштым. Коба шәһәрендә чыгышлары белән Һиндстан шигыйлары булган 25ләп мөселман кешесе бар иде. Авасакида да 3-4 һинд мөселманын очраттым. Йокохама шәһәрендә – өч мөселман, Нагасакидә – 5, болар да һинд кешеләре. Бөтен Япон утрауларында болардан башка мөселман кешесе юк иде.

[3] Китапта Шинто рәвешендә язылган бу сүз Синто булырга тиеш. Синто япон теленнән «Тәңре юлы» дип тәрҗемә ителә. Буддизм кереп урнашканчы, Япониядә ике гасыр буе яшәп килгән бу дин, будда дине, Кытайның Конфуций һәм Дао өйрәтүләре йогынтысында, ләкин үз юлы белән барлыкка килгән һәм шәкелләнгән була (тәрҗ. иск.).

Безнең мөселманнар арасында «Япониядә исламият» дигән төшенчәнең булуы бик киң таралган булса да, моның нигезе юклыгы аңлашылды. Тик моннан соң исламиятнең Япониядә таралачагы шик уятмый, чөнки япон милләте холык-табигате белән исламга бик якын тора. Ислам кагыйдәләре булып торган бик күп гүзәл һәм мактауга лаек әхлак сыйфатлары японнарда табигый яратылышларыннан ук бар. Арулык, намус, тугрылык, ышанычлылык һәм бигрәк тә юмартлык белән кыюлык японнарның холык үзенчәлекләренә әйләнгән. Йокохамада кунакханәдә яшәгәндә, миңа 16 һәм 18 яшьлек ике яшь кеше хезмәт күрсәтте. Китәргә җыенганда, бер кышкы пальто, итек кебек артык әйберләрем бар иде. Юлда йөк кенә булачак, җәй вакытына туры килгәнгә, кирәкләре дә юк дип уйлыйм. Бу егетләрнең берсе Йамата исемле иде, мин шуңа: «Менә, эшкә яраса, боларны Сезгә калдырыйм, алыгыз», – дидем. Ул исә дусты Сасакига: «Ибраһим миңа кайбер әйберләрен калдыра, син ал», – дигән. Бераздан Сасаки килде, миңа рәхмәт сәҗдәсеннән соң, киемнәрне алды. «Мин аларны алырга Йаматага әйткән идем», – дидем. Сасаки: «Әйе, миңа ул әйтте», – диде. Тагын бер тапкыр рәхмәт әйтте дә алып китте. Бер тапкыр күргәч, Йаматадан: «Ник ул әйберләрне кабул итмәдең?» – дип сорадым.

Йамата миңа: «Дустым Сасаки миннән фәкыйрьрәк. Атасы-анасы карт, ихтыяҗы минекеннән күпкә артык», – дип җавап бирде.

Сез шул холыкка карагыз! Мин калдырган киемнәрне базарга чыгарып сатса, һичшиксез, 5 көмеш акча эшләр иде. Ләкин хезмәтче егет аны дустына бирә. Дусты да – бары тик биредәге эш дусты гына, туганы-фәләне түгел.

Мондый хәлләрне күргәч, инсан углының холык-табигатендәге гүзәллеккә хәйран калмау мөмкин түгел.

Мәетләрне яндыру



114 нче биттә[4], шулай ук буддачы булган бурятларның үлеләргә карата мөгамәләсе һәм үлеләр турындагы ышанулары турында язган идем. Хәзер инде буддачы японнарның үлеләр хакындагы ышанулары белән аларга карата мөгамәләләре турында мәгълүмат бирәчәкмен. Һәр икесе дә будда динендә.

Токиода яшәгәндә, дусларымның берсе вафат булды. Җеназасына чакырып, миңа да хәбәр җибәрделәр.

Минем инде болай да күптән бу йолаларын күрәсем килә иде. Үлеләрне яндыруларын беләм, тик җеназаны барып күрмичә, ничек яндыруларын белү мөмкин түгеллеге ачык билгеле.

[4] Бу – хезмәтнең госманлы-төрек телендә басылган басмасының китап бите (тәрҗ. иск.).

Менә шул максат белән җеназага катнаштым. Башта, беренче көнне, үлгән кешенең туган-тумачасы бергә җыелышты, бу кешенең берәү белән дә бәйләнеше калмаганлыгын, берәр кешегә бурычлы булса, әлеге исәп-хисап белән бүгеннән башлап хатыны үзе шөгыльләнәчәген әйтте. Бу җәсәд Юклык иленнән китерелгән иде, иртәгә, Юклык иленә җибәрелер алдыннан, соңгы тапкыр җәсәден күрергә теләгән кешеләрнең иртәнге сәгать 9да өенә рәхим итүләрен үтенде. Туган-тумачага, билгеле бер рәвештә матәм билгесе итеп, ак төстәге кием кияргә кирәклеге турында да өстәп әйтте. Якыннарына соңгы бүләге итеп кайбер әйберләрен өләште.

«
Мәет яңа агач табутка салынган, табутның өсте шәл кебек бернәрсә белән капланган иде. Һәр килгән кеше, үленең йөзен ачып, бер тапкыр карый, ниләрдер әйтеп, кабат каплый. Сәгать тугыз тулырга ун минут кала сорнайда уйный башладылар, бар да табут янына җыелды.

Мин иртәгесе көнне сәгать 9да килдем, үленең янында дин кешеләреннән ике кеше бар иде. Хатыны миңа: «Сезнең рикшагызның номеры – 864, кайчан утырып китәргә теләсәгез, шунда китәрсез, һәрвакыт артыгызда торыр», – диде.

Мәет яңа агач табутка салынган, табутның өсте шәл кебек бернәрсә белән капланган иде. Һәр килгән кеше, үленең йөзен ачып, бер тапкыр карый, ниләрдер әйтеп, кабат каплый. Сәгать тугыз тулырга ун минут кала сорнайда уйный башладылар, бар да табут янына җыелды. Нәкъ тугызда табутны күтәреп өйдән алып чыктылар. Туганнары, якыннары булган берничә йөз кеше бар иде. Көлханәгә таба алып киттеләр.

Нәкъ сәгать 11дә көлханәгә килеп җиттек. Бу фабрика кебек бер җир иде. Яндыру урыны да дәрәҗәгә күрә икән, акча белән бәйле. Беренче дәрәҗәдә – 18 йен, икенче дәрәҗәдә – 12 йен, өченче дәрәҗәдә исә 5 йен түләргә кирәк.

Беренче дәрәҗәдә мич тулысынча аерым, махсус бер бина эчендә урнашкан, эченә бары тик ике табут кына кабул ителә. Кайчан теләсәләр, шунда яндырып бирәләр икән. Икенче дәрәҗәдәге исә шулай ук аерым мич һәм 12 табут кабул итә икән. Өченче дәрәҗәдәге мичләр ике яклы һәм 40-50 табут кабул итәләр. Без үлене икенче дәрәҗәдәге мичкә тапшырдык.

Мич – шул без белгән мич, уты гына астан кабызыла. Мич эченә рельслар өстендә йөри торган арба кереп-чыгып йөри, рәшәткәле өслеге бар, озынлыгы кеше буе. Мәетне шул өслеккә салдылар, арбаны этеп мичкә керттеләр, мичнең механизмлы капкачын яптылар, ике мөһер белән мөһерләделәр. Берсе – мич идарәсе мөһере, икенчесе – үленең якыны булган кешенең мөһере. Шунда сабуллашу догасы укылды да, кайтып киттек.

Шулай итеп үлене табуты белән мичтә калдырдык. Көне буе шул көнне мәете булган кешеләр килә, үләләрен бирегә китереп, үз көчләре дәрәҗәсендә мичләрнең берсендә калдырып, мөһерләп, өйләренә кайтып китәләр.

Төнге сәгать бердә бөтен мичләргә бергә ут кабызыла, тиешле дәрәҗәдә чыртлап яна. Кызулыкны күрсәтүче үлчәгече дә бар, фәнни күзәтү бүлегендә тора иде.

Иртәгесе көнне иртүк тагын үле чыккан өйгә килдек. Бүген бары тик туганнары гына килгән иде. Алар янында мин дә бар. Аннан, рикшаларга утырып, туп-туры

«

Инде бер очраклылык белән үле яндыру йоласын да күрдек. Бу күргәннәрем миңа бик нык тәэсир итте, башыма күптөрле уйлар килде. Кешенең хәле шундый: әҗәл бар.

көлханәгә киттек. Безне мөдир каршы алды. Кичә алган рәсми кәгазь белән мөһерне мөдиргә бирделәр дә, туры мичләр янына киттек. Башта мөһерләр чагыштырып тикшерелде. Аннары машинист килде, мич капкачын ачты. Өсте рәшәткәле арба мичтән чыгарылды. Барысының да кулында ике чыбык таякчык иде. Болар белән, көл арасыннан чүпләп, алдан ук әзерләнгән фарфор чүлмәккә сөякләрен җыеп сала башладылар. Үлгән кешенең хатыны кечкенә генә кара савыты кебек нәрсәгә аерым тешләрен җыеп тутырды. Башка мичләр янындагы кешеләр дә нәкъ шул рәвешле үз үлеләренең сөякләрен җыялар иде.

Чүлмәккә сөякләрен тутырып бетергәч, өйгә киттек. Туп-туры үленең өенә китерделәр.

Бу вакыйгадан соң инде, вакыт булуга, туган-тумачаның җыела алуына бәйле рәвештә, чүлмәкне кабергә күчерү йоласы үткәрелә икән. Ул кайчан үткәрелсә дә ярый, кабергә 3-4 ай соңыннан да күчерелергә мөмкин.

Менә җеназа йоласы шулай була. Инде бер очраклылык белән үле яндыру йоласын да күрдек. Бу күргәннәрем миңа бик нык тәэсир итте, башыма күптөрле уйлар килде. Кешенең хәле шундый: әҗәл бар. Бу көфер һәм мәҗүсилек җире – бик күп уйландым. Аллаһ сакласын, тәкъдир ителгән әҗәлем җитеп, биредә калсам, никадәр ачынырлык хәл булачак.

Японнарның мәзһәбендә үлене яндыру мәҗбүри түгел, кайберләре күмәләр дә. Буддизм төрле мәзһәпләргә аерылган. Кайберләре яндыра, кайберләре ыргыта, кайберләре күмә. Бары Япониядә генә дә буддизмның 35 юнәлеше бар, ләкин алар барысы да нигезе белән буддачылык булып санала.

Әгәр дөньяда дин һәм мәзһәп хакына башкарыла торган нәрсәләр турында киң итеп, тирән итеп уйлансаң, шуны күрергә мөмкин: бар да үзенә бертөрле итагать хис итеп башкара, сукырларча түгел. Калебләрендә гәүдәләнгән бер хис, тагын да төгәлрәге, рухи чакыру бар. Менә бу гамәлләрнең максаты шул чакыру иясенең ризасыннан башка берни дә түгел, утка да салыр, суга да. Максат ул – чакыруга итагать кылу.

Шулар турында уйланып, Имам Газали: «Һәр теләүченең максаты бер, хаталары булса да, алар да таләп итү юлында килеп чыга», – дигән. Югыйсә кеше ник үз ата-анасын яки улын-кызын утка ата?.. Шундый табигый бер итагать булмаса, берәү дә моны кабул итә алмас. Кол гаҗиз калган төп урын да бу, моны уйлагач, кеше акылы бөтен нәрсәне дә кабул итәргә мәҗбүр була. Иң динсез адәм баласы да бу урында дин хакына башкарылган нәрсәгә ризалаша.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Мәүлид ае – хәзрәти Мөхәммәд(с.г.в.)нең туган аедыр

(Вәгазь)

Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин



Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин туганы Гөлфирә һәм Миңзифа әби белән

Хәзрәтнең олы кызы Нажия Сәлимшина. Ул Октябрь шәһәрендә кибет директоры булып эшли, совет һәм аннан соңгы елларда ислам динен үстерүгә зур өлеш кертә.

Исмәгыйль Сәлимшах улы Сәлимшин (1893-1975) – Бөек Ватан сугышы ветераны, сугыштан кайткач, Татарстан Республикасының Ютазы районындагы Кәрәкәшле авылында – тегермәнче, Башкортстан Республикасының Октябрь районындагы Нарыш авылында балта остасы булып эшли. Ул гомеренең азагына чаклы, дин рәсми тыелган шартларда, мулла вазыйфасын да башкара, Коръән мәҗлесләре үткәрә, күпсанлы китаплар язып калдыра, әдәп-әхлак өчен көрәшә. Исмәгыйль хәзрәтнең кызы Нажия Сәлимшина-Газизҗанова (1926-1997) оештырган Мәүлид кичәсендә сөйләгән вәгазе аудиотасмада сакланып калган. Вакыты якынча 1960-1970 нче еллар белән тәгаенләнгән әлеге аудиомирасны сезнең хозурга да тәкъдим итәбез. Вәгазьне **beznenmiras.ru** сайтыннан да тыңларга мөмкин.

Әгүзү билләһи минәш-шәйтаанир-ражиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

И мөселман кардәшләр! Аллаһы Тәгалә дөньяны ислам нуры берлән (белән) яктыртыр өчен, бөтен җир йөзендә булган барча мөэмин вә мөэминә хатын-кызларны көфер караңгылыгыннан коткарып, ислам нуры белән яктырткан, дөнья-ахирәт вә сәгадәткә ирештергән пәйгамбәребез Мөхәммәд(с.г.в.)нең туган ае сәбәбе илә, бөтен Гарәбстан голәмәте бу айда, ягъни Рабигыл әүвәл аенда пәйгамбәребез(с.г.в.)нең туу көнен бәйрәм итәләр. Һәм махсус касыйдәләр укып, куркыныч Кыямәт көнендә шәфәгатен өмет итеп, салаватлар укыйлар. Һәм безләргә дә пәйгамбәребез Мөхәммәд(с.г.в.)нең туган аен хөрмәт итеп бәйрәм итү, аның махсус касыйдәләрен уку, вәгазь-нәсыйхәтләр сөйләү вә куркынычлы Кыямәт көнендә аның шәфәгатен өмет итеп, салават әйтүләр – һәрбарча мөэмин-мөселманнарның изге бурычыдыр. Менә бүген Наҗия үзенең балалары, үзләренең чын күңелләре берлән пәйгамбәребез Мөхәммәд(с.г.в.)нең туган аен хөрмәт итеп, күп мәшәкатьләр чигеп, безләрне чакырып мәҗлес ясады. Аллаһы Тәгалә аларның бу изге эшләрен кабул әйләсә иде.

И мөселман кардәшләр! Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә боерадыр: «Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз һәм һичнәрсәне Аллаһыга ширек (тиңдәш) итмәгез». Коръән аяте шушылай диде. И балалар (туганнар), Аллаһы сезне юктан бар кыйлды. Аналарымызның карнында яралтты, әгъзаларыбызны җанландырып, инсан кылып, дөньяга чыгар хәлгә килгәнче, сезне анда тәрбия кылды, сезне дөньяга чыгарды. Аналарыбызның күңелләренә шәфкать вә мәхәббәт салып, сезне тәрбия кылдырды. Аталарыбызның күңелләренә мәрхәмәт вә мәхәббәт салып, сезнең өчен мал җыйдырды. Шул рәвешчә, ата вә аналарыбызның мәхәббәт вә мәрхәмәт кочагында үстегез. Аллаһы Тәгалә сезләрне иң гүзәл сурәттә яралтты. Гүзәл сүзләр сөйли торган тел, файдалы эшләр эшли торган кул, кирәк урыннарга йөри торган аяк, гүзәл тавышлар ишетә торган колак, бөтен хәлне күрә торган күз, яхшы белән яманны, файда белән зыянны аера торган вә мәгыйшәтегез юлбашчысы була торган холык вә фәһем бирде. Дөньяда була торган нәрсәләрнең һәммәсен сезнең өчен яралтты. Әгәр сезгә берәрсе өй салып бирсә, яктылык керә торган тәрәзәләр куйса, түшәмнәрен яхшы буяулар белән буяса, кич караңгыда яктырта торган кандилләр (лампа) элсә, келәм-җиһазларын алса һәм, шул өйдә яшәү, ашау-эчү өчен кирәк булган нәрсәләрне хәзерләп бирсә, һич шөбһә юктыр: сез ул кешегә ничек тәшәккүр кылырга (рәхмәт әйтергә) белмәс, рәхмәт укып бетерә алмас идегез. Бу кешенең эше гадәттән тыш бүләк тоелып, ул кешегә гомер буе рәхмәт укуны җаныгызда гадәт итәр идегез. Хәлбуки, ул кешенең сезгә салып биргән өе – ут, җил, су, яңгыр белән һәлак була, заманнар узу белән туза торган өйдер.

И Адәм угыллары! Аллаһы Тәгалә сезгә гаять олы вә мөхкәм (нык) бина салган ки: ул бина ут, су белән һәлак булмыйдыр, җил вә яңгыр белән тузмыйдыр, заманнар узу белән бетмидер, бәлки, барган саен мөхкәмләнәдер (яхшырадыр). Аллаһы Тәгалә бу өйнең түшәмен гаять яхшы буяу белән буяган, алтыннан вә алмаздан ныграк ялтырый торган нурлы йолдызлар белән зиннәтләгән, гаять нурлы ай вә кояш кандилләрен (лампаларын) аскан, җирнең һәр тарафына татлы сулар агызган вә һаваны хушбуйландырган җилләрне йөрттергән…

Һичнәрсә өйрәнмәгән вә ялгызы читкә чыгып йөрмәгән, голәмәне күрмәгән, 40 яшенә кадәр гарәпләрнең үзләренең араларында торган, тугрылыгы вә ышанычлылыгы өчен яшь чагыннан ук Әл-Әмин ләкабе (исеме) белән мәшһүр,

гарәп углы булган хәзрәти Мөхәммәд (с.г.в.) гүзәл бер көндә бөтен дөньядагы халыкның диннәрен батыйл (кире кагып), яңа бер дингә өнди башлады. Авызыннан хикмәт вә мәгърифәт сүзләрен сөйләде. Моны күргәч, гарәпләр гаҗәпләнделәр. Гомерендә укымаган кешенең голәмәләрнең акылы җитмәгән, Тәүрәт вә Инҗилдә булган хөкемнәрне сөйләвенә галимнәр дә хәйран булды. Инсафлылар исламга килделәр, кояш чыккач шәмнәргә хаҗәт калмаган кебек, ислам нуры таралгач, башка диннәр тәгълиматына (өйрәтүенә) хаҗәт калмады. Ялгыз инсафсызлар гына, ярканат кояш нурын күрә алмаган кебек, хактан (хак сүзгә) күз йомдылар, төрле вәсвәсәләргә чумдылар. Ләкин, яктылык килсә, караңгылык тора алмаган кебек, хак дин килгәч, батыйл диннәр китте. Ислам бөтен галәмгә таралды. Әлеге нур, бу яктылык безгә дә җитте. Әлһәмдүлилләһ, Аллаһ без, гөнаһлы бәндәләрен, бу бөек дин белән бүләкләде һәм хәзрәти Мөхәммәд (с.г.в.) өммәте кылды.



Октябрь районындагы Нарыш авылында Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин яшәгән йорт

И мөселманнар! Аллаһ безгә никадәр гүзәл җирләрне вә күкләрне бирде. Моның кадәр матур дөньяда яшәгәндә, дөнья-ахирәт гыйлемнәрен өйрәтү өчен, Аллаһ безгә Мөхәммәд(с.г.в.)не юлбашчы кылган. Аллаһы Тәгаләгә никадәр тәшәккүр вә никадәр камәт вә санә әйтсәк тә, вә никадәр коллык кыйлсак та, аздыр. Инде һич булмаганда, боларның шөкеранасында гаҗиз икәнебезне беләек. Менә өстебездәге ай, ягъни Мәүлид ае – хәзрәти Мөхәммәд(с.г.в.)нең туган аедыр. Аңа хөрмәт кылыйк. Кыямәт көнендә куркуыбыздан җаныбыз бугазыбызга җиткән чакларда хәзрәти Мөхәммәд(с.г.в.)нең хөрмәте өчен Аллаһ безләрне кыенлыктан коткарыр. Вә хәзрәти Мөхәммәд(с.г.в.)нең шәфәгатенә ирешү насыйп булсын. Әмин!

Текстны басмага ***Сиринә Сәлимшина-Шаһимәрданова*** *әзерләде.* ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

Олуг мәгърифәтчебез Хәсән Хәмидулла

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы





Кайчандыр Евразиянең зур мәйданнарын биләгән, дөнья тарихында билгеле мәмләкәтләр корган, теле халыкара ареналарда яңгыраган татар-төрки каавеме тәкъдир-язмышның аяусыз җилләре аркасында көчсезләнә-зәгыйфьләнә бара, ахыр чиктә үзенең төп ватанына әйләнгән Идел-йортта да дәүләтсез, хокуксыз халыкка әверелә. Кремль хакимиятенең рәхимсез колониаль сәясәте, чукындыруга, урыслаштыруга юнәлтелгән эшгамәлләре йөзләрчә мең әби-бабаларыбызның кырылуына, чит-ят җирләргә, ерактагы һәм якындагы илләргә күчеп, качып китүенә сәбәпче була. Мөһаҗирлек язмышына дучар ителгән шундый затларның берсе – Хәсән Хәмидулла (1900-1988), аның ата-анасы, якыннары, күп кенә якташ-авылдашлары. Ул чыгышы белән күпләргә мәгълүм булган, татар дөньясына Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев кебек бөек җырчыларга гомер биргән Актук (Яңапар) карьясеннән. Бу авыл хәзерге вакытта Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районына керә. Хәсәннең бабасы

Хәмидулла (1836-1904) Финляндия тарафларына «вак товарчы» сыйфатында XIX гасырның 60 нчы елларында ук барып чыга. Туган төбәге белән дә араны өзми. Бераздан аның янына гаиләсе, бала-чагалары [шул исәптән булачак мәгърифәтченең әтисе Низамеддин (1862-1940) дә] күчеп килә. Кайбер авылдашлары да аларга кушыла. Мәгълүм ки, 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр Суоми (ягъни Финляндия) йөз елдан артык Россия империясе составында була. Бу хәл исә бер ил эчендәге күчү-күченүләрне чагыштырмача җиңеләйтә. Үсмер Хәсән дә әтисе, авылдашлары белән бергә Скандинавия тарафларына, бәлкем, баргалагандыр. 15 яшендә исә ул инде Финляндиягә тәмам күчеп килә.

«
Актукта тирә-юньдә мәшһүр булган татар мәдрәсәсе эшли. Хәсән шунда шактый төпле белем ала; үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен дә ярыйсы гына үзләштерә. Урысча да өйрәнә.

Актукта тирә-юньдә мәшһүр булган татар мәдрәсәсе эшли. Хәсән шунда шактый төпле белем ала; үз туган теленнән тыш, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен дә ярыйсы гына үзләштерә. Урысча да өйрәнә. Суомига күчеп килгәч, ниндидер «фин мәктәбе»ндә укуы телгә алына. Тиз арада финчә, шведча һәм өлешчә алманча да өйрәнә. Үзлегеннән күп укый. Истәлекләрдә, чыганакларда аның күптөрле һөнәрләргә ия булуы искәртелә. Матур итеп рәсемнәр ясавы, агач, металл эшләренә дә маһир булуы телгә алына. Аны еш кына «мөһәндис», ягъни инженер дип тә йөртәләр.

Хәмидуллалар гаиләсе әүвәл (һәм шактый озак еллар буе) Суоминың төньягындагы Кими (Кеми) каласында яши. Төп шөгыльләре – сату-алу. Баштарак йорттан-йортка, бер төбәктән икенчегә йөреп сәүдә итү. Бераздан үзләренең махсус кибетләрен ачалар.

1950 елның гыйнвар башларында Хәсәннәр гаиләсе Кимидән ил башкаласына күчеп килә. Биредә дә, нигездә, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Хәсән ага шушы ук калада 1988 елның 6 ноябрендә вафат була. Кабере – Хельсинкидагы мөселман зиратында. (Без фәкыйрегезнең анда берничә мәртәбә булганы бар.) Аның җәмәгате Өммегөлсем апа (вафаты 1986 елда) – Пенза ягындагы «Лановка» татары. Аларның уллары Гомәр һәм Хөсәен әфәнделәр белән миңа берничә мәртәбә очрашырга, сөйләшергә туры килде.

Хәсән ага сәүдә һәм кайбер башка эшләр белән төрле чит илләрдә дә була. Аның Ленинградка, СССРга килеп-китүе дә мәгълүм. Бу хакта «Милли юл» журналында (1929 елгы 9, 10… нчы саннар) «Совет Россиясендә кунакта» дип исемләнгән шактый күләмле сәяхәтнамәсе дә басылган. Бу тынгысыз зат ике мәртәбә хаҗга бара. Изге җирләргә сәфәрләре, юл тәэсирләре хакында аның кызыклы гына махсус язмалары да бар.

Бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйри кебек, Хәсән Хәмидулланың эшчәнлеге дә гаять күпкырлы һәм нәтиҗәле. Шунысы мөһим һәм гыйбрәтле: аның эшгамәлләре, язу-сызулары милләткә, үз халкына хезмәт итүгә юнәлтелгән. Үзенең тәүге шигырьләренең берсендә үк ул милләт «көен җырлауны» бурычы итеп куя, аның «саг»лыгын үзе өчен иң зур «байлык» дип саный. Һәм Хәсән Хәмидулла яшьлектә әйтелгән бу сүзләренә гомере буе тугры кала. Аның тау кадәрле эшчәнлеге, чыгарган гәҗит-журналлары, илледән артык китабы – моның ачык дәлиле. Хәсән Хәмидулла – шагыйрь, прозаик, драматург, тарихчы, фольклорчы,

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

дин белгече, нашир, журналист, мөгаллим. Ул – Скандинавиядә беренче булып татарча гәҗит чыгарган зат. Гарәп хәрефләре белән язылган, «Мәгърифәт» дип исемләнгән бу басманың тәүге саны Кими каласында 1925 елның 10 гыйнварында дөнья күрә. Кызганыч ки, «сәяси, милли вә әдәби» характердагы бу атналык гәҗит, 12 саны чыккач, шул ук елның 17 апрелендә цензура тарафыннан ябыла.

Хәсән ага 1943-1977 нче елларда әүвәл – Кимидә, аннан Хельсинкида «Шималь очкыннары» дип исемләнгән журнал чыгара. Ул – энциклопедия кебек гаҗәеп бай басма. Бу журнал милләтне әхлакый, тарихи, әдәби, эстетик һәм дини яктан тәрбияләүгә зур өлеш кертә. Андагы күпчелек материаллар мөхәррирнең үзе тарафыннан язылган.

Хәсән Хәмидулла 1943 елда (шулай ук Скандинавия дөньясында беренчеләрдән булып) «Коръән»не бастыра (20 мең данә) һәм аны мөселман әсирләренә бушка тарата да. «Яңа иман шарты һәм белемлекләр» исемле китабын (алты меңен) шулай ук төрки-татар әсирләренә һәдия кыла. Аның дини ихтыяҗларны күздә тотып язылган янә берничә китабы бар.

Төбәк (авыл, бистә, шәһәр) тарихын язу, нәсел шәҗәрәләрен төзү соңгы вакытта бездә киң колач алды. Бу аңлашыла да, чөнки алар аркылы милләтең, халкың тарихы ачыклана, милли үзаң тәрбияләнә. Әлеге хакыйкатьне тирәнтен аңлап, Хәсән Хәмидулла бу эшкә узган гасыр урталарында ук керешә.

> **«Хәсән ага 1943-1977 нче елларда әүвәл – Кимидә, аннан Хельсинкида «Шималь очкыннары» дип исемләнгән журнал чыгара. Ул – энциклопедия кебек гаҗәеп бай басма. Бу журнал милләтне әхлакый, тарихи, әдәби, эстетик һәм дини яктан тәрбияләүгә зур өлеш кертә.**

Аның 1954 елда Хельсинкида дөнья күргән «Яңапар тарихы» китабы (гарәп язуында, 82 бит) – җирле төбәк тарихын язуның классик үрнәге. Бу монографиядә күптөрле чыганакларга, мәгълүматларга таянып, авторның туган авылы, аның кешеләре, көнкүреше, мәгарифмәдәнияте яктыртыла. Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез, шулай ук авторның үзе хакында да кызыклы гына бүлекчәләр дә бирелә. Бу каләм әһеле халык авыз иҗаты әсәрләрен туплаган китаплар да чыгара.

Хәсән Хәмидулла әдәби иҗат белән яшьтән үк шөгыльләнә башлый. «Шигырьләремнең күпчелеге, – ди ул, – 1915-1917 нче елларда язылган». Тормыш мәшәкатьләре, төрле киртәләр булуга да карамастан, ул үзенең язу-сызу эшен гомере буе дәвам итә. Яше 70ләргә җиткәч, әдип мондый үкенечен дә белдерә: «Яшәгән һәм яшәп килгән мохитем минем башыма килеп, ачылып тора торган «илһам»нарыма бик каты киртә булып торганы өчен, әллә кайларга өскә һәм күкләргә менеп булмады… Бик зур эшләргә хәзер булган көчем вә кодрәтем йөрәгемә тулып таша торган заманда тыштагы манигълар *(киртәләр. – **Х.М.**)* рухны, тәмне, теләкне сүндерергә сәбәп булучылар – шул тартышуларыма киртә булдылар…»

Миңа 1990 елда Хәсән аганың Хельсинкида үзе төзегән йортында булырга туры килде. Диңгез култыгы янындагы бу ике катлы өй миңа чын мәгънәсендә матбага, китап музееен хәтерләтте. Анда – китап басу станоклары, язу машинкалары, типографик шрифтлар, күпсанлы китаплар, рәсем-сызымнар… Боларның бит һәммәсен Хәсән ага үзе булдырган. Язган (ә бит алар, әйткәнебезчә, 50дән

артык), баскан, төпләгән, милләттәшләренә үзе үк өләшеп тә йөргән, почта аркылы да җибәргән. Барысы да үз хисабына. Бу – асыл мәгънәсендәге фидакярлек, милләтпәрвәрлек!

Хәсән Хәмидулла бастырган китаплар төрле характерда, төрле зурлыкта. Кечерәкләре белән бергә, берничә йөз биттән артып киткәннәре дә бар. [Мәсәлән, «Илһам йимешләре» дип исемләнгән шигырь мәҗмугасы (1970) 310 битлек.] Бу каләм әһеленең мирасында төп урынны, әлбәттә, әдәби әсәрләр алып тора. Аларга жанр төрлелеге хас: шигырьләр (шул исәптән мәдхия-мәрсияләр), поэма-хикәяләр, повесть-бәяннар, сәяхәтнамә-сәфәрнамәләр һ.б. Арада хәтта драма әсәрләре дә бар. Аның, мәсәлән, 4 пәрдәлек «Хәйрелниса» пьесасы хәзерге тамашачыны да кызыксындырырлык. Әдип еш кына эпик әсәрләренә лирик элементлар да кертеп җибәрә. Тарих, табигать, дин, гаилә, белем-мәгърифәт, мәхәббәт, кавемара мөнәсәбәтләр, фәлсәфә… – боларның һәммәсе диярлек Х.Хәмидулланың каләменнән читтә калмый. Мөһаҗәрәттәге башка авторлар кебек, аның иҗатының да үзәгендә – милли тематика, татарның язмышы, теле, үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Ул, чын мәгънәсендә, татарпәрвәр. Әмма әдип үз халкындагы кимчелекләрне дә читтә калдырмый, аны, баласын яраткан ата-ана кебек, тәнкыйтьли дә. Милләтебездәге шактый гына җитешсезлекләрнең төп сәбәбен ул татарның ирексез, хокуксыз булуында күрә. Язмалары аркылы без бу әдипнең күңел дөньясын, тормыш-яшәеш турында уйлануларын, шатлык-кайгыларын, үкенеч-газапларын шактый тулы күзаллыйбыз.

* * *

Хәсән Хәмидулланың язма мирасы, гәрчә тиешле дәрәҗәдә булмаса да, хәзерге татар укучысына билгеле бер дәрәҗәдә таныш. Бу юнәлештә без фәкыйрегез дә узган гасырның 90 нчы елларыннан бирле азмы-күпме гамәлләр



кылып килә. «Бигрәк тә татар җанлы кеше иде (Хәсән Хәмидулла һәм аның тарих китабы)», «Хәсән Хәмидулланың шигъри иҗаты» һәм кайбер башка язмаларыбыз, шәт, аерым укучыларга таныштыр. Аларда әдипнең тормышы, күпкырлы эшчәнлеге, шул исәптән әдәби иҗаты хакында шактый гына факт-мәгълүматлар, фикер-күзәтүләр бар. Безнең тарафтан Х.Хәмидулланың гарәп язуындагы «Яңапар тарихы» хезмәте, хәзерге графикага күчерелеп, тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш мәкалә белән «Мирас» журналының 1998 елгы 8 нче санында (71-102 нче битләр) һәм безнең «Чит илләрдәге татар әдәбияты» монографиясендә дә (К., Мәгариф, 2007) дөнья күрде. Шул текст һәм аның Гөлсирә Гайнанова башкарган урысчага тәрҗемәсе 2008 елда, Актук егете Рифат Фәттахов тырышлыгы белән, китап рәвешендә дә нәшер ителде (Яңапар тарихы. История Актукова, 2008. – с. 128). Ул «Актук авылында туып үскән бөек татар җырчысы Рәшит Ваһаповның тууына 100 ел тулуга багышлана». Безнең «Чит илләрдәге татар әдәбияты» дигән китапка Х.Хәмидулланың өч дистәдән артык шигыре һәм әдәби иҗатын яктырткан махсус мәкалә дә кергән.

Тагын шунысын да искә төшерик: Финляндиягә 1990, 2000 елгы сәфәрләр вакытында без Хәсән Хәмидулланың берничә дистә китабын Казанга алып кайткан идек. Аларның күп өлеше Татарстан Милли китапханәсенә, Казан университеты китапханәсенә, кайбер музейларга һәдия кылынды.

Үзенең бер шигырендә бу мөхтәрәм зат болай дигән иде:

Сүәм мин бик татарлыкны, татар булып үлим, Раббым,
Сүгән бер эшне эшләү берлә мин гомремдә тәм таптым.

Хәсән Хәмидулланың бөтен эш-гамәлләре, барлык язганнары шушы изге рух белән сугарылган. ■

Утыз-Имәни һәм «Госман Коръәне»

Рәмил Исламов, филология фәннәре докторы

Лениногорск районының Тимәш авылында Габдерәхим Утыз-Имәни төрбәсе





Габдерәхим ибне Госман әл-Болгари Утыз-Имәни (1754-1834), күренекле шагыйрь, фикер иясе, дин белгече булуы белән бергә, үз чорының камилләшкән текстологы буларак та билгеле. Чөнки язма әдәбиятыбызның чишмә башы булган, гасырлар дәвамында әби-бабаларыбызның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндереп килгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасы нәкъ ул эшкәрткән текстан таралып, мәгълүм Октябрь түнтәрелешенә кадәр 70 тапкыр нәшер ителә. Әдипнең тормышында һәм иҗат эшчәнлегендә тагын бер мөһим вакыйга бар. Дәһриләр хакимияте вакытында, билгеле ки, ул читләтеп үтелде. Шуңа күрә әлеге могтәбәр зат хакындагы язмаларда да, аның 1986 елда нәшер ителгән «Шигырьләр, поэмалар» җыентыгында да ул хакта мәгълүмат китерелми. Ә элгәрге галимнәребез хезмәтләрендә аңа җитди игътибар бирелгән югыйсә. Бу – әдип Сәмәркандтa булган вакытында Хуҗа Әхрар буларак киң билгеле дин һәм дәүләт эшлеклесе Насыйретдин Гобәйдуллаһ ибне Мәхмүд Шаши (1404-1489) мәдрәсәсендә сакланган «Госман Коръәне» белән бәйле вакыйга.

Хәзрәти Госман – Коръән Кәримне таратучы

Хәер, мантыйкка муафыйк рәвештә сүзне әүвәл Изге китапның үзеннән башлыйк. Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.) (571-632) исән вакытта Коръән яттан сөйләнелеп, телдән-телгә тапшырыла, төрле әйберләргә языла. 632-634 нче елларда беренче хәлифә булган әс-Ситдыйк Әбү Бәкер Габдуллаһ ибне Госман әл-Корәйши (572-634), пәйгамбәр (с.г.в.) вафатына бер ел кала Коръән язылган әйберләрне билгеләнгән һәйәт тарафыннан туплатып-тикшертеп, аларны бер урынга җыйдырта һәм ул «Мосхәфе Шәриф» дип атала. Әлеге вакытта бердәнбер булган бу нөсхә Әбү Бәкердән соң икенче хәлифә Гомәрнең (Әбү Хәфыс ибне әл-Хаттаб әл-Гадәви әл-Корәйшигә (584-644), аңардан соң аның кызы һәм пәйгамбәрнең (с.г.в.) тол калган хатыны Хафсага (602-661) сакламага тапшырыла. Коръән Кәримне Шамда һәм Гыйракта ике төрле уку һәм ике тараф та берсен-берсе дөрес укымауда гаепләүне бетерү, чит кавемнәр ялгыш укымасын өчен, өченче хәлифә Госман ибне Гаффан әл-Өммәви әл-Корәйши (574-656) күрсәтмәсе нигезендә, пәйгамбәрнең (с.г.в.) якыннарыннан берсе һәм шәхси сәркатибе Зәед ибне Сабит әл-Әнсари (610-665) җитәкчелегендә Коръән белгечләре Габдуллаһ ибне әз-Зөбәер (624-692), Сәгыйдь ибне әл-Гас, Габдерахман ибне әл-Харис ибне Һашим, Әнәс ибне Малик, Габдулла ибне Габбас, Әбү ибне Кәгъб тарафыннан әнә шул нөсхәдән гомуми корәеш шивәсендә биш күчермә яздырыла. Аларның берсенә «Имам» дип исем бирелә һәм Мәдинәдә калдырыла, ә башкалары Мәккә, Димәшекъ (Шам), Күфә, Басра шәһәрләренә җибәрелә. Ә күчерү өчен файдаланылган нөсхә янә Хафсага кайтарыла.

Хәзрәти Госман тарафыннан: *«Моннан соң һәйәт тарафыннан күчерелгән яки шуларның рәсемнәренә муафыйк язылган мосхәф нөсхәләре генә дәстүрел-гамәл тотылсын!»*, – дигән фәрман чыгарыла. Шуңа күрә, күренекле дин белгече Ризаэддин Фәхреддин (1859-1936) язганча, «хәзрәти Госман «Җамигел-Коръән» түгел, ә «Наширел-Коръән», ягъни Коръән Кәримне таратучы.

Изге китап битләре кан белән таплана

Тарихта билгеле булганча, Госман хәлифә үзенең карамагындагы Коръәнне укып утырганда, кинәт җинаятьчеләр килеп кереп, аңа хәнҗәр белән кадыйлар һәм Изге китап битләре кан белән таплана. Ул алга таба «Мосхәф Госмани» яки «Госман Коръәне» дип атала башлый. Гәрчә Р.Фәхреддин аңлатмасы буенча, мондый билгеләмә бары тик «хәзрәти Госман тарафыннан тәгъйин ителгән һәйәт тарафыннан язылган мосхәф»кә карата гына әйтелсә дә. Әмма аның берничә нөсхәсе мәгълүм һәм аларның нәкъ кайсысы хәзрәти Госман шәһид ителгән вакытта булганлыгы гасырлар дәвамында ачык мәсьәлә булып кала.

Р.Фәхреддин мәгълүматына күрә, Госман хәлифә яздырткан нөсхәләрдән берсе 552 елда Кыртаба (Испания Әндәлесендәге Кордова) шәһәренең Җамигъ мәчетендә булып, 1248 елда Гали ибне әл-Могтазад Идриси Тәләсманга күчерттерә. Аңарда хәзрәти Госман шәһид ителгән вакыттагы кан бар дип сөйләнелсә дә, дөреслеге шикле икәнлеге әйтелә. Шамга (Сүриягә) җибәрелгән мосхәф 1259 елда Димәшекъ шәһәрендә «Бану Өммия» мәчетендә саклана. Мәккәгә җибәрелгән нөсхәнең язмышы хакында ике төрле хәбәр бар. Берсе буенча, ул язид гаскәрләре тарафыннан Кәгъбә яндырылган вакытта ут казасына дучар була. Икенчесе буенча, Димәшекъ шәһәренә күчерелеп, «Коббәтел-яһүд» дигән урынга куела. Мисырда саклана торган мосхәф хәзрәти Госман шәһид булган вакыттагы нөсхә дип фикер йөртелә.

Ул, габбасилардан булган Әбелфазыйль Җәгъфәр ибне Габдуллаһ әл-Мокътәдир Биллаһ (895-932) хәлифә хәзинәсеннән алынып, «Гомәр ибне әл-Гас» мәчетенә китерелгән һәм, аннан алынып, Хидиви китапханәсенә куелган. Ибне Батутта буларак киң танылу алган гарәп сәяхәтчесе Әбу Габдуллаһ Мөхәммәт ибне Габдуллаһ әт-Тәнҗи (1304-1377) Басра шәһәрендәге мосхәфнең «Әмирел-мөэминен Гали ибне Әбу Талиб» мәчетендә саклануы турында яза һәм *«Фәсәйәкфикәһум Аллаһу вәһуас-сәмигъуль-галим» («һәм Аллаһы сине алардан азат итә: Ул – ишетүче, белүче»)* аяте («әл-Бәкара» сүрәсе, 137 нче аять) битендәге кан эзләре булуын дәлил итеп, бу хәзрәти Госман шәһид ителгәндәге нөсхә икәнлеген әйтә. Әбу Габид әл-Касыйм ибне Сәлам Багдади хәзрәтләре мосхәфтәге кан эзләренең күбрәк «ән-Нәҗем» сүрәсендә булганлыгын белдерә. «Имам» дип билгеле булган Мәдинә нөсхәсе 735 елда Мәдинәи Мөнәвәрә шәһәрендә булган. Аны йөз яшенә ирешеп вафат булган Әбу Габид һәм тарихчы, дин белгече әс-Сәхави (1428-1497) исемле затларның күргәнлекләре турында риваятьләр сөйләнелә.

Гарәп әдәбияты белгече Габдулла әл-Мәгазинең мәкаләсеннән күренгәнчә, Шәмседдин Мөхәммәд әл-Җәзири үзенең «Ән-Нәшер» исемле китабында Госман хәлифәнең каны тамган Коръәнне Мисырда «Мәдрәси Фазлия»дә күргәнлеген яза. Пәйгамбәр (с.г.в.) сәхабәләреннән берсе, күп кенә хәдисләр тапшыручы Ибне Җәбир ибне Габдуллаһ әл-Әнсари (607-696) Мәдинәдәге Коръәннең Госман тарафыннан яздырылган мосхәф икәнлеген белдерсә дә, аның хәлифә шәһид булган вакыттагы нөсхә түгеллеген әйтә. Дин белгече, фәкыйһ Әбү Мөхәммәд Габдуллаһ ибне Котәйбә (828-889) аңлатканча, Госман хәлифә каны тамган Коръән аның улы Халидкә, аңардан соң аның балаларына кала. «Нөзһәтән-назарин» авторы Бөрзәнҗи язганча, Мисырда, Мәдинәдә, Мәккәдә булган нөсхәләрнең өчесендә дә кан эзләре бар, әмма аның берсе генә хәзрәти Госман алдында булган Кәлям Шәриф.

Сәмәрканд нөсхәсе

Болар арасында янә Сәмәрканд нөсхәсе дә бар. Аның күләме 353 бит, шуларның 284е пергамент (иләнгән тире), ә калганнары – кәгазь. Ул анда ничек пәйда булуы хакында кайбер мәгълүмат шәркыятьче Алексей Шебунинның (1867-1937) аңа багышланган тикшеренүендә китерелә. Төркестан генерал-губернаторы, генерал-адъютант Константин фон Кауфманның (1818-1882) күрсәтмәсе буенча, шәркыятьче, титуляр советник Александр Кун (1840-1888) Хуҗа Әхрар мәчете голямалары мулла Габделҗәлил һәм мулла Могыйни Мөфтидән язып алган риваять буенча, аны Хуҗа Әхрар мөритләренең берсе хаҗдан кайтышлый Румнан (Константинопольдән) алып кайта. Башка чыганакларда бу нөсхәне дин белгече Әбү Бәкер Мөхәммәд ибне Гали ибне Исмәгыйль әл-Каффул әш-Шаши (903-993) X гасырда Багдадтан; Әмир Тимер (1336-1405) 1402 елгы сугышта госманлы солтаны Баязит I Йылдырымны (1354 яки 1360-1403) җиңгәннән соң, Бурса шәһәреннән алып кайтканлыгы бәян ителә.

Рус шәркыятьчесе Владимир Тизенгаузенның (1825-1902) Алтын Урда турында гарәп чыганаклары тупланган китабында язылганча, мәмлүкләр Мисыры солтаны әз-Заһир Рөкнеддин Бәйбарс Бондыкдариның (1223-1277) сәркатибе Мөхиэддин Әбу әл-Фазыйль Габдуллаһ ибне Габдеззаһир (1221-1293), әмир һәм дәвадар Рөкнеддин Бәйбарс әл-Мансури әл-Мисыри (1245-1325) һәм Шиһабетдин Әбелгаббас Әхмәт Габделваһһаб ән-Нөвәйри (1279-1333) язмаларында Мисырдан илчелек белән Бәркә ханга (1209 тирәсе-1266) җибәрелгән күпсанлы бүләкләр

арасында «Госман Коръәне» дә булганлыгы күрсәтелә. Каһирә университеты профессоры Әмин әл-Холи (1895-?), танылган татар галиме, дин белгече, тарихчы Морат Рәмзинең (1853-1934) 1908 елда Оренбургта гарәп телендә нәшер ителгән ике томлык «Тәлфыйк әл-әхбар вә тәлкыйх әл-асәр фи вәкаигъ Казан вә Болгар, вә мөлүк әт-татар» («Казанда вә Болгарда булган вакыйгалар һәм татар мәликләре турында хәбәрләр») дигән хезмәтенә нигезләнеп, Сәмәрканд нөсхәсе әмир Тимер 1389-1395 нче еллардагы сугышта Туктамыш ханны (?-406) җиңгәннән соң Сарайдан алып киткән әнә шул нөсхә булу ихтималын белдерә.

Сәмәрканд нөсхәсе хакында иң әүвәл Зәравшан округы башлыгы генерал-майор Александр Абрамов (1836-886) белеп ала һәм Сәмәрканд бүлеге башлыгы подполковник Серовка бу турыда мәгълүмат җыю бурычын йөкли. Ул, нәтиҗәдә, мәчеткә 100 сум сәдака бәрабәренә Коръәнне алып, К. фон Кауфманга тапшыра. Генерал-губернатор, Халык мәгарифе министры исеменә юлланган 182 нче сан белән теркәлгән рәсми хат белән бергә, Изге китапны 1869 елның 24 октябрендә Санкт-Петербург Император җәмәгать китапханәсенә озата.

Утыз-Имәни «Госман Коръәне» хакында

Г.Утыз-Имәнинең бу нөсхәнең тузган хәлдә булуы, төзәтеп тәртипкә китерүгә, нинди ысул белән язылганлыгы, озынлык-киңлек, авырлык үлчәмнәре хакында язган шигыре Р.Фәхреддиннең «Асар» дип аталган биобиблиографик характердагы фундаменталь хезмәтенең 1 нче җилде 6 нчы кисәгендә (1904) китерелә. Менә аның документаль әһәмияткә ия тексты:

Укырда бер кичә мосхәфе Госман,
Өйнең сорахыннан керде дошман.
Орар хәнҗәр илә, бакмаз үзенә,
Акар каны ушал мосхәф йөзенә.
Рәсүлуллаһны дөшдә күрмеш иде:
«Бу көн безгә кәлүрсән», – димеш иде.
Сәяхәттә, бу мискин, йөрдекмедә,
Сәмәркандтә ничә көн тордыгымда,
Күребмән мосхәфе: бер җайда тормыш,
Вәраклары тузыб, бәнде өзелмеш.
Гаҗәиб хатты вардыр, һич ирсә,
Укый белмәз алыб бакыб күрерсә.
Кылыблар пуст аһудан вәраклар,
Җәли хаттыр, уникедер сәтырлар.
Олугдыр, катгый тула дүрт карышдин,
Дәхи гарза кылыбтыр өч карышдин,
Йуанлыгы улыр ике карышдин,
Агырлыгы улыр пәнеж сир дик.
Булашмыш канига берничә әүрак,
Хисаб итсәң, чыкар ундан зиядәрәк.
Тузыб китмеш вәракларны йигыбмән,
Ике такта арасига куйыбмән,
Дәхи мәхкәм йиб илә таза баглаб,
Куйыбмән такчага хуб агырлаб.
Сәмәрканд шәһәренә варсаң күрерсән,
Бинаи Хуҗа Әхрарадан сорарсән.
Улыр хәштдин кылан ак мәдарис,
Бинасы мәрфуг имәсдер, ирәр пәс.
Эчендә вәкыфханә хөҗрәи вар,
Табарсән шунда керсән, и таләбдар.

СҮЗЛЕК:
сорах – тишек; *ушал* – шул; *җайда* – урында; *вәрак* – бит; *хатт* – язу; *пуст аһу* – җәнлек тиресе; *җәли* – ачык таныла; *сәтыр* – юл; *тула* – буе; *гарза* – иңе; *әүрак* – битләр; *пәнеж* – биш; *сир* – авырлык үлчәме = 75 г; *зиядә* – артык; *йигыб* – җыеп; *мәхкәм* – нык; *йиб* – җеп; *баглаб* – бәйләп; *хуб агырлаб* – яхшылап чистартып; *хәшт* – яндырылмаган кирпеч; *мәдарис* – мәдрәсәләр; *мәрфуг имәсдер* – күтәрелмәгән; *хөҗрә* – бүлмә.

Ризаэддин Фәхреддин 1921 елгы ачлыкка багышланган «The Great Famine» («Коточкыч ачлык») фильмы кадрында. Ул анда АРА хезмәткәрләрен «Госман Коръәне» белән таныштыра.

Р.Фәхреддин текстны Г.Утыз-Имәнинең «Ахырзаман» дигән әсәреннән алуын күрсәтә. Миссионер, дин галиме Е.А.Малов (1835-1918) та әлеге китапны тикшерүгә багышланган бер хезмәтендә бу әсәрне шулай ук Г.Утыз-Имәнигә нисбәт итә. Билгеле булганча, «Ахырзаман» китабының үзендә андый шигъри юллар күзәтелми. Әдәбият галимнәре Гали Рәхим (1892-943) һәм Газиз Гобәйдуллин (1887-1937) «Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере» дигән китапта «Ахырзаман» китабын шагыйрьнең «Ахирәтнамә» әсәре белән буташтыру ихтималын белдерәләр.

Дөрестән дә, Г.Утыз-Имәнинең әле беркайда да басылмаган андый поэмасы бар һәм ул «Дөррәтел-фахирә» («Мактаулы энҗе») яки «Ахирәтнамә» («Ахирәт турындагы язма») дип атала. Шагыйрь аны, археограф Альберт Фәтхи (1937-1992) ачыклаганча, Шәрыкның күренекле философы, галим-теологы Әбү Хәмид Мөхәммәд ибне Мөхәммәд әл-Газалиның (1058-1111) «Дөррәтел-фахирә фи кәшфе гомумел-ахирә» («Ахирәт хәлләрен ачу юлында мактаулы энҗе») дигән әсәреннән файдаланып иҗат иткән. Хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университеты карамагындагы Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең Шәрык бүлегендә «Дөррәтел-фахирә»нең XIX гасырның башында һәм икенче яртысында күчереп язылган ике нөсхәсе саклана, ә тагын тасвирланмаган икесе Татарстан Республикасының Милли музее фондларында бар.

Әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов үзе төзеп бастырган «Габдерәхим Утыз-Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар» (1986) исемле китапта Р.Фәхреддин «Асар»да китергән утыз шигъри юлны әнә шул «Дөррәтел-фахирә»дән алуын яза. Ләкин ул аның эчтәлеген ачмый.

Р.Фәхреддин карамагында, күрәсең, «Дөррәтел-фахирә»нең ниндидер башка күчермәсе булган. Чөнки университет китапханәсендәге нөсхәнең берсе, А.Фәтхи мәгълүматына күрә, 1929 елда Татарны өйрәнү җәмгыятенең Чистай, Бөгелмә, Бәләбәй һәм Минзәлә кантоннарына ясаган экспедициясе вакытында М.Билалов тарафыннан Шөгер районының Тимәш авылында мәчет чормасында табылган, ә икенчесе «Ш.Хөсәенов вәрәсәләре» фирмасының архивыннан Г.Кәтиев тарафыннан 1936 елда тапшырылган.

Ахыры киләсе санда ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

Үткәннән ике рецензия

Әдәби калейдоскоп

Рәсемдә (сулдан уңга): язучы Гариф Ахунов, композитор Нәҗип Җиһанов һәм Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов. ***В. Зотов фотосы, Наилә Ахунова архивыннан***

Бу язмаларда авторның сиксәненче еллар ахыры-туксанынчы еллар башында иҗат ителгән әсәрләргә эчке бәяләмәләре тәкъдим ителә. Азатлык җилләре исеп, халкыбызның милли аңы уянып, милләт өчен янып-көеп, байраклар күтәреп урамнарга чыккан; күзләрдә киләчәккә өмет чаткылары уянган чорда әдәбият та гомуми күтәрелештән читтә калмаган, үз сүзен әйтергә ашыккан икән. Әлбәттә, сәнгати югарылыктагы әсәрләр җәмгыятьтә барган вакыйгаларны шул мизгелендә үк чагылдыра алмый, документальлек – журналистлар, сәясәтчеләр шөгыле. Шул ук вакытта илдә барган хәл-әхвәлләрнең шаһиты, катнашучысы – язучы да милләтенең язмышыннан читтә кала алмый, үзенең элегрәк язылган, шул көннәрдә төзәтелгән, яңартылган әсәрләрен матбугатка тәкъдим итәргә, ягъни өммәтенең киләчәгенә битараф түгеллеген җиткерергә ашыга. Татарстан китап нәшриятына кулъязмалар ул чорда бик күп тапшырылган икән, совет чорында кабул ителгән гадәт-традиция буенча, барысы да (хәтта Гариф Ахунов кебек танылган язучыларның җыентыгы да) рецензент-белгеч кулы аша үтәргә тиеш булган. Эчке бәяләмә киң җәмәгатьчелек өчен язылмый. Ул иҗатчының үзенә бирелә һәм нәшрият хезмәткәрләренә кулъязмага мөнәсәбәтне ачыклау өчен нигез булып тора. Максаттан чыгып, эчке рецензия гомуми фәлсәфи уйлануларны, шапырынып мәдхия яудыруларны өнәми, анда сүз күбрәк булачак китапны камилләштерү, җитешсезлекләрдән арындыру турында бара. Ул – үзенә бер ихласлы һәм кирәкле жанр. Кызганыч ки, хәзер бу файдалы һәм кирәкле традиция юкка чыкты.

Тәлгат Галиуллин

Рәшит Гәрәйнең «Син бер генә» исемле кульязмасына эчке рецензия

Рәшит Гәрәй. Балтач районы. 1973 ел

Р.Гәрәй әдәбиятка илленче елларның икенче яртысында килеп, аңа утыз елдан артык хезмәт итә. Беренче шигырьләре 1948-1950 нче елларда ук «Совет әдәбияты» журналында, газеталарда күренә башлый. Хәзер ул дистәдән артык шигырь китаплары авторы.

Р.Гәрәйнең төп темасы – туган як табигате. Туган авылының үткәне, бүгенгесе, киләчәге, гади кешенең рухи дөньясы, кичерешләре. Ул реализмга, халык җырлары традицияләренә, гади, самими стильгә өстенлек бирә. Р.Харис шагыйрьнең илле еллыгына багышланган мәкаләсен «Арыш тамырыннан җыр да шыта», дип, бөтен иҗади рухын исемгә сыйдырган иде. Р.Гәрәй, һәртөрле формаль эзләнүләр белән мавыкмыйча, яшьлегендә сайлаган менә шул юлына турылыклы кала алды.

> **«Туган авылының үткәне, бүгенгесе, киләчәге, гади кешенең рухи дөньясы, кичерешләре. Ул реализмга, халык җырлары традицияләренә, гади, самими стильгә өстенлек бирә.**

Менә аның «Син бер генә» исемле яңа кульязмасы. Нигездә, соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләрдән торган бу җыентыкта да ул күбрәк туган як матурлыгы, игенче хезмәтенең яме, фәлсәфи эчтәлеге, кешене яшәртә, күтәрә торган мәхәббәт хисе турында яза. Ирекле тәрҗемәи әсәрләргә дә өлеш чыгарылган. «Инешләрем», «Йолдызларым йокламаган», «Тауларым да иңгән», «Тургайларга сәлам биреп барам», «Ләйсән булып явар идем», «Көзге яфраклар» кебек шигырьләрдә табигатьне тирәнтен аңлау, аның белән рухи якынлык идеясе укучыны битараф калдыра алмас дип уйлыйм. «Куен дәфтәреннән» бәйләме стиль пөхтәлеге, хисенең самимилеге белән үзенә тарта.

Вакыйгалы сюжетка корылган шигырьләре иҗат диапазонын киңәйтеп, хисләр стихиясен тулыландырып, ачыклап, конкретлаштырып җибәрә («Исләремдә әле», «Ике иңемдә», «Буразналарым таныса», «Бер рәхәтлек биреп җаныма» һ.б.). Саный, күрсәтә калсаң, андый шигырьләр кульязмада аз түгел.

Р.Гәрәйнең шигъри осталыгы сүз-образны сиземләү сәләте үсә баруда ачык күренә. «Авылым төне» шигыренә элегик моң, туган табигать ямен аңлау, аны кешеләр күңелендәге матурлык белән бәйләп сурәтләү хас:

Көн буена дулкын кагып арган
Күлләр сихри нурда коена.
Безнең якта, никтер, йолдызлар да
Яктырактыр сыман тоела.

«Сүзләр эзләп чыгам»да табигать – шагыйрь өчен илһам чыганагы, яңа хисләр, фикерләр, сүзләр чишмәсе.

«Җиргә ятып тыңлыйм: колагыма яшь үләннәр сөйли серләрен». «Сат миңа гармуныңны» шигыренең «Йолдызлар чүпләмәк булам суда йөзгән болыттан» сынландыруы да күңелдә кала.

Р.Гәрәй фикерләү, дөньяны образлы кабул итү рәвеше буенча С.Хәкимгә якын тора. Шуңа күрә уртак мотивлар, табигатьне якын өслүбтәрәк сынландыру алымнары очрау табигый. Әмма якынлык-охшашлыкка күчкән очракларда кабатлану туа. «Арышларга күзем тимәсен» шигыренең «Көне буе җаным тыныч түгел, кырлардан бер урап кайтмасам», «Серкә очырырга әзерләнгән… Арышларга күзем тимәсен» кебек юлларны өлкән шагыйрьләр иҗатында укыган дигән тәэсир кала.

Р.Гәрәйнең шигырьләре, кагыйдә буларак, җыйнак-пөхтә, ритмикалары халык җырлары кысасында эшләнгән, рифмалары төгәл. Әмма шагыйрь вакыты белән ашыгыбрак куя. «Авылым кызларына» шигыреннән мисаллар алыйк. Сүз тормыш авырлыгын үз җилкәләренә салган, сыер, үгез җигеп көлтә ташыган җиңгиләргә хөрмәт хакында бара. Шагыйрьнең нәтиҗәсе: «Хәзер генә, никтер, кайберәүләр күбесенең кадерен белмиләр». Фикер ягыннан, стиль җәһәтеннән дә төгәл түгел дип саныйм мин бу җөмләне. Шунда ук «Теләкләре уртак һәркайсының өметләре уртак булганга» дигән юллар бар. Ният ачылып бетми: уртак теләк нәрсә ул?

«Икмәк, дияр идем» шигырендә дә «Бу нәрсәдән кыйммәт борыннарны кытыклаган арыш исләре» дигән юлларны төрлечә аңлап була.

Кульъязманың сыйфатын яхшырту юнәлешендә авторның мөмкинлекләре әле бар.

Төп фикер шуңа кайтып кала: конкрет эчтәлекле, вакыйгалы сюжетлы, үз биографиясеннән үсеп чыгып, ачык, төгәл фикер-тойгылар аша ачылган шигырьләр Р.Гәрәйгә, публицистик, артык гомуми, патетик характердагы шигырьләргә караганда, җиңелрәк «баш бирә». Җөмләдән, кульъязманы ачып җибәргән «Җирдә якты апрель» әсәрен уңышлылар рәтендә санап булмый (текстта күрсәтелде).

«Курганнардан калкып» шигыре уйланып бетмәгән. «Кадер-хөрмәткә ия син»дә тасвирчылык көчле. «Синдә бер кеше артса да» шигыренең оптимизмы ясалма (кызганычка каршы, авылда тәрәзәсе кадакланган йортлар бетеп бармый, ә елдан-ел арта). «Көтүдә» шигыренең үзәк идеясе, язылу мәгънәсе, умыртка баганасы табылмаган дигән тойгы кала.

Шахтерлар янына бару хисе дулкынында туган шигырьләрдә яңалык зур түгел. Әйтик, «Нигә әле җырлап үтмәскә» шигыренең мотивлары 30 нчы елларда М.Крыймов, М.Сөндекле һ.б. иҗатында ук яңгыраган иде инде.

«Икмәк исе – җирнең сулышы ул, Икмәк исе – тормыш сулышы» кебек афористик юлларга ия «Икмәк, дияр идем» шигыренең башын уйлап бетерәсе бар. Уңышсыз сүз уйнату килеп чыккан.

Кульъязмада төрле милләт шагыйрьләре әсәрләренә таянып иҗат ителгән бер көлтә шигырь бирелә. Ханты шагыйре Роман Ругинга һәм украин шагыйре Василий Горяиновка таянып иҗат ителгән «Килегез сез, кешеләр, шул утка», «Гармун тавышы» әсәрләре уңай тәэсир калдыра. Башкаларында яңалык юк, эстетик кыйммәтләре дә зур түгел.

Булачак җыентыкның композициясе турында уйланырга кирәк. Ул әлегә тематик яисә тышкы бер билге буенча төзелмәгән. Бөтен кульъязманы тоташтан уку кабул итүне кыенлаштыра. Шуның өстенә, бер үк мотивка багышланган әсәрләр кульъязманың башында да, соңгы кисәктә дә урын алган. Әйтик, «Инешем», «Басуларның арткан ямьнәре», «И, урманым, урманым», «Син бер генә» кебек шигырьләрнең үзәгендә туган җиргә, туган төбәккә, аның табигатенә мәхәббәт, ихлас күңелдән ташып чыккан

ихтирам хисе ята. Аннан соң автор башка темаларга күчә: «Яшь наратлар» көен җырлап үтә. Светловның атаклы «Гренада»сы мотивын яңарта, солдат язмышына кызыклы гына шигырьләр багышлый («Дозорда», «Лагерь таңы» һ.б.), үтеп киткән сугышны каһәрли («Утыз өч чакыру кәгазе»), әнисен сагынып искә ала («Үзең булмасаң да», «Әнкәм чалымнарын таныйм») һәм янәдән әүвәлге мотивка – туган ил образына әйләнеп кайта («Туган ягым», «Туган җир», «Туган якта» һ.б.). Соңгылары, гомумиләштерү җәһәтеннән килгәндә, киңрәк диапозонлы әсәрләр. Ә бит, гадәттә, шигъри җыентыклар нигезендә гомумидән конкретка омтылыш ята. Кыскасы, биредә эчке логиканы табып алуы, шигъри әсәрләрен төзегәндә авторның нинди принциплар белән эш итүен аңлавы кыен. Дөресрәге, ул әлегә юк, табылмаган, уйланылмаган. Шуңа күрә кайбер мотивлар элегрәк әйтелде бит инде, бу хакта алдарак сүз булды, шагыйрь кабатлана башлады дигән тойгы кала. Шигъри җыентыкның ачык, төгәл, акланган композициясе, бүлек һәм бүлекчәләре булырга тиеш дип уйлыйм. Юкса ул әлегә озын, сюжетсыз поэма булып кабул ителә.

Тулаем алганда, шагыйрь Рәшит Гәрәйнең яңа эзләнү-уйланулары уңай тәэсир калдыра. Чын-чынлап бер уйланып эшләп алса, кульязманың сыйфаты хәзерге таләпләр югарылыгына күтәрелер дип уйлыйм.

1987 елның июне

Рифкать Закировның «Йөрәк уты» исемле кульязмасына эчке бәяләмә

Рифкать Закиров

Р.Закиров исеме матбугатта 70 нче елларда күренә башлады. Газета-журналларда басылган шигырьләре, беренче җыентыклары укучының игътибарын җәлеп итте, тәнкыйтьнең миһербанлы хисләрен уятты. Аның шигырьләре турында уңай фикерләр дә әйтелде. Р.Закиров иҗатында татар поэзиясенең Х.Туфаннар башлап җибәргән Урал ягы, эшчеләр тормышы белән бәйле традицияләре уянып, яңарып китте. Икенче яктан, яшь авторның шигырьләре басылып чыккан елларда эшче темасы белән уйнау, шаяру модада иде әле. Бу яктан да Р.Закиров шигырьләре табынга кулай булдылар.

Һәм менә «Йөрәк уты» исеме белән ул нәшриятка яңа һәм, минемчә, әлегә иң тулы җыентыгын тәкъдим итә. Кульязманың игътибарга лаеклы ягы нәрсәдә соң? Шагыйрь башкаларны кабатламаска тырыша, үз индивидуальлеген эзли. Күңелдә уй-кичерешләр уята алырдай шигырьләр байтак: «Чиягә барсам», «Чия тавына», «Сине күреп», «Күршедәге ятим малай», «Эмигрант монологы», «Үги анага», «Кадерең арта бара», «Ялгыз йорт» шигырьләре реалистик рухлары, ачык эчтәлекләре, ритмик

үзенчәлекләре белән хәтердә калалар. Авыр язмышлы кешеләр тормышын үзәккә алган шигырьләре уңышлы, миһербанлы, заманча. Табигать турындагы парчаларының бер төркеме яңача яңгырый: «Әллә уйнап», «Көзге яңгыр», «Табигать йөзендә», «Кышкы иртә», «Кышкы юл», «Җәйге төн», «Ага чишмә». Мәхәббәт темасына багышланган шигырьләре арасында да олы хисне үзенчә, башкаларны кабатламыйча иҗат ителгәннәре аз түгел (андыйлары «+» билгесе белән текстта күрсәтелә барды).

Шул ук вакытта кулъязманың дәрәҗәсе тигез түгел. Әйбәт, сәнгатьчә камил әсәрләр янәшәсендә үк шактый төссез шигырьләр урын ала, стиль, иҗек чатаклыклары да байтак (соңгысына бигрәк тә игътибар итәргә кирәк, прозаизм, иҗек төгәлсезлеге Туфанга гына килешә иде). Бигрәк тә башлангыч өлештәге, гомумирәк характердагы шигырьләр ризасызлык хисе уята. Әйтик, «Яңадан туу» безнең көннәр өчен артык ясалма пафослы, «Чыныгу»ның оптимистик бетемен кабул итүе кыен. «Ветераннарга җавап» – искечә фикерләү үрнәге. «Күңел күзе»нең соңгы өлеше уйланылмаган.

«Улыма хат»та да вәгазь, үгет-нәсыйхәт өстенлек итә. «Кичәге күк, нәкъ бүген дә...» шигыренең күтәренке рухына да кушылуы кыен.

Башта – хезмәт, аннан инде
Бәхетем ишек какты минем, –

кебек юллар 30 нчы елларда язылган диярсең, «Киләчәк» шигыре дә шул чорда шытып чыккан.

«Язарбыз яңа дастан», «Безнекеләр» шигырьләре – шулай ук элеккечә язу үрнәге. Заманы өчен яраган «Шахтер идем», «Без – шахтерлар» әсәрләре дә хәзер

«

Ә инде Сталинның үлем машинасының, бернәрсә белән дә санашмыйча, мотивларны ачыкламыйча, миллионнарны кырганын хәзер беләбез. Бу әсәр сталинизмны аклау түгелме?

яңалык буларак кабул ителми. Шахтер халкы соңгы елларда алдынгы көч булып, үзен яклап чыга алган хәрәкәт булып калыкты. Шул рух шигырьләрдә сизелми. Бу яктан, гомумән, «Урал, Урал» циклын янәдән бер карап чыгасы бардыр. Күләме буенча поэмага якын «Нәфрәт җыры»н кабул итә алмадым. Бер мескен адәм озак еллар буена өй почмагында сугыштан качып ята, янәсе дезертир була. Ул болай да бәхетсез. Ә инде Сталинның үлем машинасының, бернәрсә белән дә санашмыйча, мотивларны ачыкламыйча, миллионнарны кырганын хәзер беләбез. Бу әсәр сталинизмны аклау түгелме? Нәфрәт җырын башка көчләргә юнәлтү вакыты җитмәдеме?

Шактый уңышлы, кыска күләмле табигать, мәхәббәт шигырьләре турында әйткән идек. Әмма биредә дә сыйфат дәрәҗәсе бер үк түгел, шактый төссез яисә гомуми хисле, балавыз сыгуга, шәхси тойгыны күтәрүгә корылганнары шактый. Берничәсен атап үтәм: «Озата барсаң», «Мәхәббәт җыры», «Сагынуларың әгәр чиктән ашса...», «Яңгыр явып торган перроннарда...», «Лирик хат», «Аңлашу», «Мәңге бакый», «Син – кояшым минем», «Кит», – дисең син», «Мин юкта», «Сагышларым минем төпсездер...». Башка теләкләр кулъязмада, шигырьләр янында күрсәтелә барды.

Әлбәттә, кулъязма матбугатка тәкъдим ителергә лаеклы. Әмма сыйфатны күтәрү өстендә ныклап эшлисе бар әле.

1990 елның феврале

Үткәннән хатлар

Язучы, тарихчы Җәмит Рәхимовның* гаиләсе архивында байтак язучыбызның үз вакытында әдипкә юллаган хатлары саклана. Шул хатларның берничәсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.



Фәннур Сафин – Җәмит Рәхимовка

«Җәмит абый!

Повестегыз белән таныштык. Әйбәт әсәр язгансыз. Һәм аны «Ялкын»га тәкъдим итеп бик дөрес эшләгәнсез. Ул журналда тулысынча биреләчәк. Башы апрель санында булыр. Шул хакта Сезгә хәбәр итәргә җөрьәт итәм, ашыгам ягъни.

Ихтирам белән,
әдәбият бүлеге мөдире Ф.Сафин.
1.02.77».

«Җәмит абый!

Хатыгызны алдык. Фотогызны җибәреп бик дөрес эшләгәнсез. Аны журналда бирербез. Җитмәсә, бик әйбәт, бик матур фото чыккан. Анысы өчен рәхмәт. Журналлар җибәрергә тырышырбыз. «Ялкын» киоскларыгызда да буладыр, бәлки? Игътибар итегез әле шуңа. Әгәр анда булмаса, шуны эшләп, оештырып булмый микән?

Ярый, сүз бетте кебек. Сау булыгыз.
Ихтирам белән, Фәннур.
24/II – 77. Казан».



Шамил Рәкыйпов – Җәмит Рәхимовка

«Хөрмәтле Җәмит!

«Девон хәбәрчесе» исемле повестегызны карап чыктык. Аңа рецензия дә яздырып алдык, редактор фикере дә бар хәзер. Шуларның һәммәсен искә алып, үзегезчә тагын бер кат карап чыксагыз иде.

Икенче әйберне 1978 елга тәкъдим итмәкче булабыз. Планнар әле каралмаган.

Сезгә уңышлар теләп, редакция мөдире: Ш.Рәкыйпов.
13 гыйнвар, 1977 ел».

---

* Җәмит Гата улы Рәхимов 1935 елның 13 гыйнварында Татарстан АССРның Лениногорск (элеккеге Шөгер) районындагы Иске Шөгер авылында колхозчы гаиләсендә туган. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1985). 1977 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде. 1996 елда вафат булды.





Гәрәй Рәхим – Җәмит Рәхимовка

«Җәмит абый!

Хатыгызга соңлабрак җавап бирәм. Повестегызны Ахуновтан ала алган юк әле, ник дисәң, әлегә мин монда яңа кеше, укып-танышасы әйберләр бик тә күп, номерга эшлиселәре тагы да күбрәк. Әлегә шул 1978 елның беренче яртыеллык планындагы әйберләр белән мәшгульмен. Архивтан алсам да, хәзер генә таныша башларга мөмкинлек юк.

Монда бертөркем хикәяләрегез дә ята, алар бик иске кәгазьләрдә, саргаеп та беткәннәр, без бик элек язылган әйберләрдер дип уйладык. Редколлегия членнарыннан Ә.Баянов укыды, барырлык әйбер юк, дип рецензия язды, мин үзем дә танышып чыктым, чыннан да, безнең журнал битләренә үк туры килмиләр бит. Алары ярар, повесть барырлык булса ярар иде, безгә бүгенге көн темасы бик кирәк. Менә шундый-шундый хәлләр. Егетләр ни хәлдә? Язаларны?

Барысына да сәлам белән, Г.Рәхим. 17. VIII – 77. Казан».

Разил Вәлиев – Җәмит Рәхимовка

«Иптәш Ж.Рәхимов!

Сез, бик тә хаклы рәвештә, «77 ел корчагинчылары» конкурсында җиңеп чыккан идегез. Шушы елның 14 декабрендә кичке сәгать 7дә Актерлар йортында (Казанда) әлеге премияләрне тапшыру тантанасы була.

Сезне шул мәҗлестә катнашырга чакырабыз.

Кичәнең концерт өлешендә чыгыш ясарга да әзерләнеп килсәгез иде.

Хөрмәт белән,

ВЛКСМ өлкә комитетының иҗат яшьләре белән эшләү Советы председателе Разил Вәлиев.

5 декабрь, 1977 ел. Казан».


Иптәш Ж. Рәхимов!

Сез, бик тә хаклы рәвештә, "77 нче ел корчагинчылары" конкурсында җиңеп чыккан идегез. Шушы елның 14 нче декабрендә кичке сәгать 7 дә Актерлар йортында /Казанда/ әлеге премияләрне тапшыру тантанасы була.

Сезне шул мәҗлестә катнашырга чакырабыз.

Кичәнең концерт өлешендә чыгыш ясарга да әзерләнеп килсәгез иде.

Хөрмәт белән,

ВЛКСМ өлкә комитетының иҗат яшьләре белән эшләү Советы председателе Р.Вәлиев /Разил Вәлиев/

5 декабрь, 77 ел.

Казан.

Фәрваз Миңнуллин – Җәмит Рәхимовка

«Хөрмәтле Җәмит туган!

Аксакаллар белән киңәшләшкәннән соң, «Казан утлары»ның быелгы 1-6 саннарында басылган очерклар хакында фикер әйтүне сиңа тапшырырга булдык.

Журнал тикшерүгә багышланган җыелыш сентябрь айларында булачак.

Сәлам белән, Фәрваз. Июнь, 1978 ел».

Әдип Маликов – Җәмит Рәхимовка

«Җәмит!

«Соц.Татарстан» газетасы «К.утлары» журналында басылып килгән очеркларга, публицистикага күзәтү бирергә җыена. Алар бүгенге көн таләбенә ничек җавап бирәләр? Нинди актуаль, кирәкле мәсьәләләрне күтәрәләр?

Сүз, башлыча, шул турыда барырга тиеш. Тел, әдәби детальләр, образлылык һ.б. турында да читләтеп узып булмый инде. Нәкъ син әзерләп яткан материал. Шамил Маннапов бу күзәтү-мәкаләне син язарсың дип өметләнә. Аның белән элемтәгә кер әле.

Барлык иптәшләргә, гаиләңә сәлам.
Хөрмәт белән, Әдип Маликов. 24/VII – 1978».



Мәхмүт Хөсәен – Җәмит Рәхимовка

«Җәмит дус!

Мин яңадан Кырымда. Ял итүе рәхәт, билгеле. Күршем – проф. Х.Госман. 10 августта кичен Казан радиосы минем «Мәхәббәт йөзеге» дигән әсәремне тапшыра. Тыңла һәм үз фикереңне язып җибәр. Шамилгә (Бикчуринга. – Л.Л.) күп сәлам. Мәхмүт. 5.7.72. Кырым».

«Яңа ел белән, Җәмит дус!
Тыныч булсын җир, ямьле.
Кырын карап исмәсеннәр
Сиңа илһам җилләре.
Сөйгәнең белән бергә
Тигез яшә гомергә.
Мәхмүт Хөсәен.
31.XII/75 ел. Казан».

*Хатларны басмага **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

ТАШ БАТЫР ТУРЫНДА РИВАЯТЬ

(Хикәят)

АЙДАРБӘК САРМАНБӘТОВ

Нахсын кыргыз пәһлеванына торган саен гаҗәпләнә барды. Дошманы янына бер ялгызы курыкмыйча килүе җитмәгән, атыннан төшеп, унлап яугир барлыгына да игътибар итмичә, тыныч кына гәпләшеп утыра. Ипле һәм тыныч сөйли. Аның бөтенесе дә шома гына бара. Чынлап та, пәһлеван бу! Ул каршында хөрмәтле кеше утыруына, аның ачыктан-ачык әйткәннәрен дөрес бәяли алуына, ни өчен килүләре хакында түкми-чәчми сөйләвенә ышанды. Әлбәттә, Нахсын барысы хакында да сөйләде, бары тик Хан сере – бу җирләрне Кытайга кушу турында гына берни әйтмәде. Ике еллык ясак артыннан килүен дә яшермәде. Монда калган калмык биләрен тикшерергә, үзләре карамагындагы яугирләрнең тормыш-көнкүреше хакында белешергә җибәрелүен дә, үзәндә яшәүче кыргызларның җан исәпләрен барларга җыенуын да әйтте. Кыргыз аны дикъкать белән тыңлады. Бермәл тын торды. Учакта кыздырылган ике ит калҗасын ике кинжалга кадап, шулардан берсен Дорбу пәһлеванга сонды. Ул сөякле калҗаны әдәпле генә итеп кулына алды да, авыз итеп тә тормыйча, бер читтә кулына йөгән чорнап, йокымсырап утырган малай тарафына ыргытты. Бик нык ачыккан малай үзенә таба очып килгән ит калҗасын шундук эләктереп алды һәм, аны, бик нык кайнар булуына карамастан, кулларында әвәли-әвәли өрештереп тә алгач, итне тешләре белән умырып алып ашый да башлады. Кыргыз пәһлеваны, малай тарафына кулы белән ишарәләп:

– Карагыз аңа, кыргыз баласына! – диде күңелсез генә. – Аның иреннәрендә әле сөт тә кипмәгән, ә сез аны ничек җәфаладыгыз! Ул гына да түгел, бер гаепсез ата-анасын үтердегез, ә хәзер кайгы кичергән, ачлы-туклы яшәгән малай-

---

Ахыры. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

дан ике еллык ясак алырга телисезме? Нәрсә бирә ала инде ул бәхетсез бала?! Тиресен салыр да сезгә тоттырыр! – Ул янындагы чиләкне ачу белән кулына алды, кыяфәтенә карасаң, менә-менә хәзер һөҗүм итә башлар төсле иде. Алга таба ыргылыш ясады да, ярсуын баса төшеп, туктап калды. – Торлактан куылган барлык кыргыз да бүген әлеге малай хәлендә – ач-ялангач. Бөтенесенең дә тәне вә күңеле җәрәхәттән генә тора. Ничек сез оятсыз рәвештә монда килә алдыгыз һәм безгә дәгъва белдерергә җөрьәт итәсез? Киресенчә, тыныч халыкны тар-мар иткәнегез өчен без сезгә дәгъва белдерергә тиеш! Моны белмәгән һәм аңламаган ханыгызның, мөгаен, акылы шуның кадәр генәдер…

Бурутның кыюлыгына һәм куркусыз булуына сокланып утырган Нахсын, әзмәвернең ханны мыскыл итәргә тотынуын күреп, кинәт ачу белән урыныннан торды:

– Безнең ханга тел тидермә, пәһлеван! Мин – аның яугире. Кирәксә, халкымның башлыгы өчен канымны коярга да әзермен!

Аның кыюлыгын һәм хак сүзләр әйтүен таныган хәлдә, ул беравык бер сүз дә эндәшмәде. Ханы өчен үзен куркыныч астына куйса да, калмык баһадиры хөрмәткә лаек, дип, үзен-үзе тынычландырды. Аны тынгысыз уйлар биләп алды. Күк йөзендә исәбе-хисабы булмаган йолдызлар яна, ай яктысы салмак кына җиргә төшә. Башлыкларының каты тавышын ишеткән яугирләр, төн кунарга әзерләнгән җирләреннән туктап, әңгәмәдәшләрнең икесенә дә хәвефле карашларын текәде. Кыргыз пәһлеваны аларга игътибар да итмәде.

– Син кире кайтып кит, баһадир, – диде ул күпмедер вакыттан соң, үзен хакимнәрчә тотып. – Чарасызлыктан туган җирләреннән китсәләр дә, кыргызлар, аз санлы булуларына карамастан, Ватаннарына тугры халык. Каннарын да, тормышларын да кызганмаячак алар. Миннән исән-сау китеп, юлыгызны дәвам итсәгез, сез беренче тау артында ук үлемегезне табачаксыз. Кабат монда килсәгез дә, шундый ук язмыш көтә. Без хәзер туган җиребезне беркемгә дә таптарга ирек куймаячакбыз! Торгул би ярдәменә өметләнмәгез дә! Ул инде кешелеген күптән югалтты. Теге вакытта талап алган байлыктан, әче кымыздан күптән башын югалтыр чиккә җитте инде ул: үз сугышчылары белән, бер дә айнымыйча, көне-төне бәйрәм итә. Ул сиңа тау-терәк була алмаячак. – Пәһлеван сакалын сыпырып алды да янә көр тавышын ишеттерде. – Теге юлы сез һөҗүм иткәндә, мин бик еракта идем, хәзер инде ул чактагы хатамны, һичшиксез, төзәтәчәкмен. Соңгы тамчы каным җиргә тамганчы көрәшәчәкмен, әмма дошманга изге җиремне таптарга мөмкинлек бирмәм. Әгәр алга таба барырга теләсәгез, үлемегезне миннән табарсыз. Хәзер үк кайтып кит, баһадир. Монда күргәннәреңне һәм ишеткәннәреңне ханыңа түкмичәчми җиткер. Әгәр монда кабат кире килергә һәм һөҗүм итәргә уйласагыз, белеп торыгыз: һәрбер тау сукмагында сезне поскын[1] көтеп торачак. Аз санлы булсалар да, әгәр сугыша башласагыз, алар да карап тормаячак, сезнең башыгызга кыяларны да, ташларны да коеп төшерәчәк. Тау башына омтылган киек шикелле, халык тагы да ераккарак китәчәк. Алар тау белән бер рухта. Кыргызларны һәрвакыт таулар яклый. Әгәр аларны эзәрлекләп барырга кыюлыгыгыз җитсә, хәлдән таячаксыз, кешесез тауларда тиктомалдан юкка чыгачаксыз. Әгәр кыргызлар җиңелә икән, алар барыбер туган җирләрен бирмәячәк. Шундый халык без. Берни белән дә исәпләшмәстән, алар газиз Ватаннарын кире кайтарып алачак. Безнең өчен ике нәрсә изге – безне Барлыкка китерүче һәм Ватан! Тагын бер мәртәбә әйтәм,

[1] Поскын – засада.

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

баһадир, барыгыз, кире кайтып китегез. Әгәр тыңламыйсыз икән, мин сезне беренче тау артында ук каршы алачакмын. Халкым өчен гомеремне дә кызганмаячакмын! – дип, кыргыз ашыгып торып басты. Өзәңгегә аягын куеп, атка менеп утырам дигәндә генә, ул, беразга тукталып, артына борылып карады һәм, сүзләрен йомшарта төшеп, дәвам итте:

– Син, бактың исә, бик нык ялгышасың икән, баһадир. Батыр-кыю кеше үзен хан өчен түгел, бәлки, халкы, Ватаны өчен фида кылырга тиеш. Хан да ирекле түгел, килә-китә, бирелә, бирешә, ялгыша. Ул мәңгелек түгел, аңа хезмәт итү – бәйдәге эт шикелле, хуҗаны саклау гына ул. Хак юлдамын, дип, үзеңне алдама. Үз-үзеңне асрау өчен ялагайланып яшәргә мәҗбүрсең. Халык, Ватан – изге, мәңгелек. Халкыңа, Ватаныңа хезмәт итү – һәр чын баһадирның изге бурычы. Бурычны үтәү батырлык санала. Барысын да төшенгән булсаң, әле соң түгел, баһадир! – диде ул һәм атына менеп атланды.

Нахсын, сихерләнгән кебек, аның артыннан иярде:

– Пәһлеван, исемегез ничек? Бер-беребезне искә алырбыз. Минем исемем – Нахсын. Сез – чын батыр, – диде ул чын күңеленнән.

Пәһлеван кыргыз, атын борып:

– Соно пәһлеван, диләр миңа. Дөрес, бу минем чын исемем түгел. Мин әйткәннәрне мыегыңа чорна, хәтереңә нык сеңеп калсын...

Шулай диде дә ул, караңгылык эченә кереп югалды. Малай исә аны кысып кочаклаган иде.

Инде күптәннән легендага әйләнгән, даны мангул-кытайларга ук барып җиткән баһадир исемен ишеткәч, Нахсын: «Һм, димәк, теге пәһлеван шул үзе икән», – дип уйлап куйды. Әйе, әлеге батырны бик күпләр белә. Аның куркыныч орышлар вакытында һәрвакыт алгы рәттә булуыннан да хәбәрдарлар. Дошман кем генә булмасын, аларның күпмелегенә карамастан, бөркет кебек өсләренә ташланыр һәм, дошман өере уртасына барып кереп, үз-үзенә нык ышанган батырларны бергә-бер сугышырга чакырып, һәммәсен юк итәр иде.

Хәзер нишләргә инде? Бурут әйткән белән килешергәме, әллә...

Төшкә генә керергә мөмкин булган усал йөзле кыргыз аңа бик нык тәэсир итте. Кыя-таудай кыяфәтен, бер ялгызы дошманы юлын кисүен күрсәң, чынлап та, исең-акылың китәр. Манас шикелле юлбарыс нәселеннәндер бу, йа, Хода! Ул, кыл өстендә торган гомере өчен түгел, бәлки, туган халкының ачы язмышы өчен борчылып, башын канлы сугышка китереп тыккан. Чын баһадирлар саф уйларга ия була һәм үлемнең күзенә туры карый ала, диләр. Кара син аның акыллы чыгышын! Таштагы сакланып калган эзләр шикелле, дәрья кебек тирән, ук сыман кире әйләнеп кайтмастай. Аның һәрбер сүзе баш миенә кадак кебек кадалды, кургаш кебек бәреп керде.

Нахсын йоклый алмады, тынгысыз, борчулы уйлар аңа йокларга ирек бирмәде. Бераз черем итеп булмасмы, дип, тирмәгә дә кереп тормады хәтта. Бая гына икәү гәпләшкән таш өстендә бик озак һәм хәрәкәтсез утырды ул. Кайнар күмергә баскандай, вакыт-вакыт сикереп торды, әрле-бирле йөренде. Таңны шулай каршы алды Нахсын... Чынлап та, ул гомер буе ялгышып яшәгән булып чыга түгелме соң? Ханга җаны-тәне белән бирелеп хезмәт итте, кемгә төртеп күрсәтсә, шуның башын кисеп төшерде, намусын саклап яшәргә тырышты. Бактың исә, бу рияланып, икейөзләләнеп яшәү генә булган икән.

Ханга сукырларча хезмәт итеп, көнчыгышта – мангуллар, найманнар, биредә – кытайлар һәм тибетлылар, төньякта исә кыргызлар, кайсаклар белән сугышып, гомерлек дошман булып яшәде, күпме халыкны юк итте ул, җирләрен талады. Бер гаепсез халыкка, батырларга китергән бәла-каза

өчен кем җавап тотарга тиеш? Ул үзенә күпме гөнаһ җыйды. Ә нәрсәгә иреште? Айлар, еллар буена үзенең торлагын күрмәде, эсседә пеште, суыкта туңды, күпме афәт кичте, ә моның файдасын бары тик хан үзе генә татыды. Тәнен яндырып торган яралардан һәм сагыш кимергән күңеленнән башка бернәрсәгә дә ирешмәде ул. Сугыш-орыш вакытында бер гаепсезгә каннары коелган батырларның, Нахсын гаскәре артыннан ач-ялангач калган халыкларның каргышын кем күтәрер хәзер? Үзе кылган гамәлне батырлык дип санады ул. Бактың исә, үз исеменә кара тап төшергән икән ләбаса! Әлеге каргыш, канлы тап хәзер аның нәсел-ыруына да төшәчәк. Исән калган токымны кан коючылар нәселе дип искә алачаклар, каргаячаклар. Әгәр үз халкың авыр хәлдә калса, башка халыклар аңа ярдәмгә килмәячәк, төркемнән аерылган эт шикелле куылачак. Һәлак булган батырларның уллары, нәселләре, әгәр үзе исән булмаса, балаларын эзәрлекләячәкләр. Һичшиксез, кыю-батырлар Нахсын токымыннан үч алачак! Кан коелачак!.. Ата кешенең кылган гөнаһлары газиз балаларына күчә икән, моннан да авыррак тагын ни булырга мөмкин?! Аның батырлык кылуыннан ни мәгънә?!.

Бераз гына да черем итмичә таң каршылагач, аз-маз капкалап алгандай итте дә карашын тирән күлгә төбәде. Шуннан соң кичәге шикелле, аларның юлын бүлеп, тау башында торараташ булып басып торган Соно пәһлеванның шәүләсен шәйләп алды. Пәһлеванның карашыннан усаллык бөркелә иде. Тау башына ул беркетеп куйган зәңгәр әләмдәге ярымай таң яктысында ялтырап күренә. Санташ тарафыннан ургылган җилдән әләм җилфер-җилфер килә. Әйе, таң беленә башлауга ук, пәһлеван үзенең әүвәлге урынына менеп баскан. Халкы өчен борчылудан ул да төн буе керфек какмаган, күрәсең. Биек тау башында мәгърур, нык басып торуы белән ул әлеге чикне үтәргә ярамаганлыгын аңлатып кисәтә кебек, кире кайтып китмәсәң, кан коячакмын, дип әйтә сыман. Аның орышка әзер икәнлеге бу юлы сизелеп тора иде. Кулындагы очлы озын сөңгесе биеккә-биеккә – иге-чиге күренмәгән күк йөзенә сузылган. Ялгыз. Берүзе ун яугиргә генә каршы тора алуы аның кыяфәтеннән ук күренеп тора. Кичә бит ул барысын да үз күзләре белән күрде, дошманының көчен, аның барлык мөмкинлеген күзаллап, бәяләп өлгерде ләбаса. Пәһлеван шул вакытта ук инде нишләргә икәнен хәл итеп куйгандыр. Үз гомерен саклап каласы килү түгел, ә Ватанының киләчәк язмышын хәл итәргә алынуы аңа бетмәс-төкәнмәс көч бирә иде. Шуңа да ул күтәренке рух белән басып тора. Бу горур һәм үтә зирәк пәһлеванга Нахсынның сөңгесе дә, кылычы да каршы тора алмаячак. Орышка керсә, Нахсын үзенең җиңел акыллы булуын гына күрсәткән булыр иде. Бары шул. Ә нәрсә, усал ниятле ханы өчен үлеп, хур булса? Юк. «Әгәр хакыйкатьне тапкан икән, юлдан язган кешенең гаебе юк», – ди ойрд[2] мәкале.

«Нәрсә югалттым мин монда, ни эзлим? Һөҗүм итеп нәрсәгә ия булам да нәрсә өчен үч алам? Кыргызларга дәгъва белдерүдән һәм үч аласы килүдән гайре минем халкымда тагын ни калды соң? Бернәрсә дә. Ә бит без кыргызлар белән борын-борыннан җирле ут күршеләр булып яшибез, гореф-гадәтләр – бер, йөтәкләр якын диярлек.

Мин исә бары астыртын, әрсез ханның усал максатын якладым. Шуның өстенә, узган яуда халыкны тар-мар итештем, ә хәзер менә аларның Ватанын коллыкка төшерергә һәм аны кытайларга бирергә дип килдем. Безне берни дә

[2] Ойрд – ойрат, төньяк мангулларны, калмыкларны, зөнгәр-җунгәрләрне (уңкул дигән мәгънәдә, алар кайчандыр Чыңгыз хан гаскәренең уң канатын тәшкил иткәннәр) элек шулай атап йөрткәннәр. Монгол сүзе, якын, янәшә дигән мәгънә белдерә. Ойратларны «урман кешеләре» дип тә йөрткәннәр. ***Тәрҗемәче искәрмәсе.***

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

бәйләп тормаган кытайларга! Монда минем ни хаҗәтем бар? Бернинди дә. Бу бары тик Доржуга гына кирәк. Барлык кыргыз халкының каргышы башыма бәла-каза булып төшмәсен тагы, Аллам сакласын! Минем аларга карата шәхсән бернинди начар уй-ниятем юк», – дип, Нахсын үзенчә төпле фикер йөртте. Аның күз алдына Соно пәһлеванның шәүләсе килеп басты. Ул шәүлә, кичәге көнгә ишарәләп, әйтә кебек: «Дөрестуры юлдан бар, баһадир. Кире кайт, әле соң түгел. Бу фани дөньяда, үзара кылыч болгаганчы, изге ниятләр белән бер-беребезне хөрмәт итсәк, яхшырак булыр. Чын егеткә тагы ни кирәк?» Әйе, әйтелгәннәрнең барысы да хак. Әмма аны үтәве кыен. Хакыйкатькә юл һәрвакыт авыр. Әгәр кире кайтып китсәң, кыргызлар да, калмыклар да аны куркак санаячак. Шулай булуы көн кебек ачык. Соно пәһлеванның берүзеннән куркып качкан, дип, мәзәк итеп сөйләячәкләр. Теләсә нәрсә сөйләсеннәр, шәхси батырлыкка караганда, ике халыкның дустанә яшәве күпкә өстенрәк, мөһимрәк. Әгәр Соно пәһлеван явыз ниятле булса, төнлә бирегә кабат килеп, арып-талчыгып йоклаган яугирләрнең барысын да кырып салган булыр иде. Ул алай итмәде бит. Димәк, аның чит-ят кавемнең канын тиктомалдан коясы килми. Әгәр без һөҗүм итсәк, ул кан коярга мәҗбүр булачак. Бәрелеш, һичшиксез, булачак һәм канкоеш вакытында беребез җанын фида кылачак. Башка юл юк. Кемгә кирәк безнең кан? Соно хак юлда, ул Ватанын яклап сугышачак, ә мин?.. Ә нәрсә, ханның хәйләкәр максаты өчен, бәлки, башны кистерергәдер? Юк. Ошбу мизгелдән башлап беркайчан да алай итмәячәк!.. Халык зирәк, акыллы: берберсен хөрмәт иткән ике баһадирның үзара орышка кермәвен хуплаучылар да, яклаучылар да табылачак. Әйе, бу вакыйга, бу сөйләшүләр тарихта калачак!..

«Нигә иртә кайттың? Мин бит күл тирәли әйләнеп чыгарга куштым. Минем боерыкны үтәмәдеңме?..» – якынча нәкъ шулай диячәк Доржу, котырачак. Күзләре атылып чыгар дәрәҗәгә җитәчәк, кыяфәте куркыныч булып күренәчәк…

Күл тарафын чамалап, куркыныч юлга кузгалыр алдыннан бер рәт булып тезелеп баскан яугирләр алдында торган Нахсын карашын көнбатышка таба – Соно пәһлеван шәүләсе шәйләнгән якка юнәлтеп алды да, атын кинәт кире борып, кичә килгән юл буйлап китеп барды. Бу хәлгә аптыраган сугышчылар, үз баһадирларыннан сорарга кыймыйча, тояк тавышларын дәррәү яңгыратып, аның артыннан иярделәр.

Тау үткелләре аша ике көн вә ике төнлек юл узып, үзләренең торлакларына кайтып җитүгә, Нахсын шундук хан янына килеп керде. Ниләр күргәнен сөйләп биргәч, ханга үз уй-фикерләрен дә җиткерде. Хаким, хәйләкәр күзләрен тагы да кыса төшеп, гадәттәгечә, эчтән этлек эшләргә әзерләнеп, йокымсыраган мәче шикелле тыңлап утырды. Нахсын, әйткәннәренә нәтиҗә ясап, болай диде:

– Хан, үзләре гомер иткән диңгез буен кыргызларның барысы да ташлап китмәгән. Ярасын ялап ятучы юлбарыс кебек төрле җирләрдә яшеренеп яталар. Тарлавыкларда күпләп җыелганнар. Барысы да яман ачулы. Безгә тынычланырга, ул халыкка һөҗүм итмәскә кирәк. Болай да ул халыкны байтак кырдык, учак көлен күп тараттык. Әгәр тагын һөҗүм итсәк, безгә афәттән котылу юк. Батыркыю халык. Алар туган җирләрен – Ватаннарын беркемгә дә бирмәячәкләр. Элеккеге шикелле, өер-өер тупланып, котырыналар, рәхимсезлек күрсәтәләр. Манастан кала, Бээжинны бер халык та яулый алмаган. Ничәшәр йөз ел буе ни Искәндәр Зөлкарнәй, ни Чыңгыз хан Ала Тауны буйсындыруга ирешмәгән. Хәзерге җиңүебез вакытлыча гына. Җиңү шатлыгыннан айный алмыйча, бәла-казага дучар булмыйк тагы.

Сыбан Доржу, Нахсын сөйләгәннәрнең асылына төшенә алмыйча, шактый озак уйланып утырды. Ышанычлы баһадирын җибәргән иде, ә ул исә, бөтенесен дә ачыктан-ачык сөйләмәсә дә, бер караганда, гаҗәпләнгән кебек күренә, икенче караганда, бурутларны яклаган сыман тоела, өстәвенә, йөзендә вакыт-вакыт усаллык чаткылары уйнап ала. Ник алай кылана ул, сәбәбе ни? Нәрсәдән яки кемнән курыккан ул шулкадәр? Бәлки, ул хәзинә тапкандыр яисә берәр хатын аның башын әйләндергәндер? Хатын дигәнең, Нахсынның ниятен белеп, ачыклап алгандыр да, аны киресенчә эшләргә үгетләгәндер. Бу кыю йөрәкле баһадир нәрсәдән бик курыккан соң алайса? Монда нидер бар… Кинәт хан, Нахсынга карашын җәһәт кенә төбәп алды да, мыскыллы елмаеп, алга таба тартылды:

– Минем баһадирымның йөрәге калтырый башлаган, ахры, – диде ул. Элек тә бу баһадирга әллә ни ышанып бетми иде, ниһаять, шикләнүе раска чыкты. Күр әнә, китүенә караганда кайтуы тизрәк булды түгелме? Хан, ачуына чыдый алмыйча, сүзләрен турыдан ярып әйтте: – Җир йөзеннән юк ителгән кыргыз өрәгеннән куркырга кирәк бит, ә?! Мин сине батыр кеше дип уйлый идем, ә син хәтта ир-ат та түгел икән. Нәрсә, үткелдә юлыңны бүлеп, дуамал Манасны ымсындыргыч шайтан итеп каршыңа җибәрделәрме әллә? Ул исә, давыл чыгарып, күзеңне тузан белән тутыргандыр. Ә син куркудан аңыңны югалтып егылгансыңдыр… Күзләрең бөтенләй башка синең, сөйләвең дә элеккечә түгел. Бар, хатының янына кайт, ихтыяр көчеңне тупла да кабат кил!..

Нахсынның җен ачулары чыкты, ул бит хан өчен гомерен жәлләмәде. Үз күзләре белән күргәнне ничек бар, шулай сөйләде, чын күңелдән кисәтте, ә аны дошман итеп кабул иттеләр. Ярсыды, тамырларында кан кайный башлады. Хатын-кыз белән чагыштырган була… Ир-атны явызларча мыскыл итү бу. Хәйләкәр хан орышлар вакытында Нахсынның гомерен дә кызганмыйча җиңүләр яулавын, аның данлы батырлыкларын искә төшерүдән дә тартынмады. Хан өчен ничәмә мәртәбә үлемнең күзенә бакты ул, башын үлем түмәренә куйды. Үз хакименең ахмаклыгын, мәкерле булуын ничек моңарчы сизмәде Нахсын?.. Аны күкләргә чөйде, ихлас хезмәт итте, бактың исә, баһадир үзенең канәгатьсез тормышын бары тик җилгә генә очырган икән! Ханның явыз ниятләре аркасында, күпме батырның, күпме халыкның җанын кыйды ул. Нахсын хәзер аларның торлакларын туздырганы, каннарын койганы өчен Аллаһ алдында мәңге юып бетерә алмаслык гөнаһ җыйды. Ни өчен алай эшләде соң ул? Аны алдадылар… Соно пәһлеванны очратуына ул сөенеп бетә алмады. Аның бер сүзе хакыйкатьне ачып бирде, Нахсынның күзен ачты. Әгәр бу хәл килеп чыкмаса, ул бу фани дөньядан дөм сукыр шикелле гаип булыр иде.

Шул көннән соң Нахсын, ихтыяҗ булмаганда, хан хозурына барудан туктады, купшы мәҗлесләрдә һәм тантаналы чараларда катнашмый башлады. Ул хәзер ут капкандай ашкынып чапмады, элекке вакыттагы кебек, үзенең көчгайрәтен күрсәтү өчен, дошман-мазар эзләп йөрмәс булды. Хан да аны оныткан булса кирәк, бер тапкыр да үзенә чакырмады. Мәсхәрә ителгән, гаепсездән гаепле булган баһадир һәрдаим хатыны һәм балалары янында булды. Еш кына аны очы-кырые күренмәгән уйлар биләп алды. Хәзер исә җавабы булмаган бер генә уй борчый иде: аңлы һәм аңсыз рәвештә кылган гөнаһлары, аның тарафыннан җаннары кыелган рухлар өчен Аллаһ алдында ул кайчан һәм ничек җавап тотачак? Гаепсез балаларына, нәселне дәвам итәргә тиешле токымга төшәчәк каргышны ул хәзер нинди дә булса юл белән юып төшерә аламы? Кайчандыр куркудан дер калтыраган

дошманның күзләренә туры карый алган Нахсын бүген балаларының угыз кебек чиста, саф күзләренә, энҗе шикелле ап-ак йөзле хатынының якты карашына туры карый алмый. Алар алдында ул бары тик үзен гаепле итеп кенә тоя. Ә бит хакыйкать барыбер бер өскә калкып чыгачак. Мондый газапларны, мондый җәфалануларны ир-ат кавеменә күрергә язмасын!

Бервакыт, җәйге эсседән качып дигәндәй, өендә тыныч кына яткан Нахсынга этләрнең бертуктаусыз өргән тавышы ишелде. Әйтерсең лә, дошман килә. Кем булыр бу? Аның алты яшьлек малае абына-сөртенә өйгә килеп керде:

– Атай! Атай! Бик күп җайдаклар килде. Анайдан синең турыда сорыйлар...

Чакырусыз кем килде икән дип уйлап, Нахсын урамга чыкты һәм әүвәл сугыш атына атланган, хәйләкәр күзләрен өзлексез хәрәкәтләндергән ханны күреп алды. Аны күпсанлы яраннары әйләндереп алган иде. Баһадир, уң кулын йөрәгенә куеп һәм башын ия төшеп, ханга ихтирамын белгертте:

– Саулык телим, ханым...

Хан бу юлы элекке шикелле ашыкмыйча гына атыннан төшеп тормады, һәм, әлбәттә, рөхсәт-фәлән сорап тормыйча гына Нахсынның өенә узмады, кыскасы, үзенең батырына хөрмәт күрсәтеп тормады. Тиктормас аты өстендә ачулы кыяфәтендә утыра бирде.

– Җә, баһадир, хатын белән генә яшәү туйдырмадымы әле? Халыкны, үз ханыңны тәмам оныттың, ялгыз бүре шикелле берүзең генә булырга уйлаган идеңме? Тизрәк җыен да юлга чык! Яраларын ялап ятучы кыргызларны үз ояларында юк ит!

Нахсын үз колакларына үзе ышанмады. Ни сөйли ул? Бу дөнья болгаткыч тагы ни майтармакчы була икән инде, тагын нинди бәла-каза китермәкче? Әллә яңадан бөтенесен болгатмакчы буламы, таларга чыгарга җыенамы, яисә мине башкалар алдында сындырып, үзенең өстенлеген күрсәтмәкчеме? Әллә чынлап та, исән калган кыргызларны кырып бетереп, аларның җирләрен кытайларга бирергә җыенамы? Ала Тауны кичүгә, Нахсынны юлына каршы төшкән Соно пәһлеван белән бәрелеш көтә. Ул чагында үлемнән котылу юк. Икейөзле Доржуга шул гына кирәк тә! Нахсынның Соно пәһлеванга ничек кулы күтәрелсен инде, булмаганны!

– Нәрсә аптырап торасың? Акылыңны җуйдың мәллә? Әллә Соно пәһлеваннан яхшы хәбәр алдыңмы? – Төртмәле сүзләрне ишетеп, Нахсын ханга тиз генә карап алды. Кыргыз пәһлеваны белән очрашуы турында ул аңа бер сүз дә әйтмәгән иде бит. Каян белгән? Димәк, яугирләренең берсе аны саткан.

– Нәрсә дип әйтүегез бу, хаким!

– Сөйлә, баһадир, теге бурут үз ягына сине ничек аударды? Нәрсә, ул сиңа караганда көчлерәкмени? Җебеп төшкәнсең! Ай йөзле яшь кызларын сиңа бирергә вәгъдә бирдеме әллә? Ха-ха-ха...

Хан янындагылар, ялагайланып, дәррәү көлеп җибәрделәр. Буласы булган инде, нәрсәгә хәзер акланып торырга дип уйлады ул, ачуыннан тешләрен кысып. Дәшмичә торды. Акланып, түбәнсенеп тору баһадирларча түгел. Аның серен каян белгәнен хан үзе сөйләсен.

Ясалма көлүеннән кисәк туктап, Сыбан Доржу, бер урында басып тора алмаган атын типкеләп, баһадирга ташланды.

– Ник дәшмисең? Мин бит сиңа бөтен күл тирәли әйләнеп чыгарга куштым. Кайда ясак? Бер буруттан курыктыңмы? Әгәр шулай икән, син булдыксыз бәндә. Димәк, син – хатын-кызга охшап баручы баһадир!

Хакимнең беркайчан да аны болай мыскыл иткәне булмады. Бигрәк тә ят кешеләр алдында. Күрәсең, яугирләрнең берсе аны сатып кына калмаган, карал-

тырга да тырышкан. Кайсысы шулай бик каты ялагайланды икән?

– Хөрмәтле хан, Сезне яклап күпме орышта катнашканым өчен рәхмәтегез шушымы? Мин ишетмәдем, Сез әйтмәдегез...

Аның бу кыю сүзләренә хан тирәсендәгеләрнең исе китте. Хан, аты белән Нахсын тирәсендә әйләнә-әйләнә:

– Әгәр мин әйтсәм, син нишли аласың соң? Кайчандыр миңа һөҗүм иткән егетне юк иткәнең өчен мине бурычлы саныйсың... Андый ахмак егетне хатын-кыз да җиңә. Миңа хәзер синең кебек куркак хыянәтче кирәкми! Ал кулыңа кылыч! – дип үкерде. Хәзер барысы да аңлашыла. Бактың исә, ул ялагайлары белән аны үтерергә килгән. Соң инде. Баһадирны хатын-кыз белән чагыштырды. Моннан да зуррак түбәнсетү булуы мөмкин түгел. Нәрсә эшләргә инде хәзер? Котылуның берәр юлы бармы? Әгәр кораллары белән ханга каршы бара икән, алардагы гадәт буенча, җәзаны ул үзе генә түгел, аның балалары, хатыны, якын туганнары татыячак – аларның да башлары очачак. Баһадир үзе турында түгел, ә бәлки, туганнары, якыннары язмышы өчен борчылды. Аларның коелган каны өчен дә Нахсынга җавап бирергә туры килерме икәнни? Хәйләкәр Доржу бу хакта бик яхшы белә һәм шулай булуын тели дә. Ул ахмакны Нахсын үзенең кылычы белән бер кизәнүдә юк итәр иде югыйсә. Кырылыш кырык ел барса да, әҗәле җитмәс, чебен дә үлми, диләр. Күпме бәрелешләрдән исән чыккан Нахсынның да үлем сәгате сукты. Бу гөнаһлы дөньяга кемнәр генә килмәгән дә, кемнәр генә китмәгән. Ул да шуларның берсе.... Берәү дә мәңгелек түгел. Дошманнар белән орыш вакытында үлмәвең кызганыч, бу ахмак кулыннан китүең – үкенеч, әлбәттә. Ятакта үлүеңә караганда, яуда үлүең хәерлерәк. Үлемнән курыкты, димәсеннәр, башны горур тотып китәргә кирәк... Нахсын, карашын ханга төбәп, кырыс кына әйтеп куйды:

– Нәрсә, Доржу, минем серемне беләсең киләмени? Мин синнән курка торган кешеләрдән түгел. Куркытуыңны ташла. Сине халыкның юлбашчысы, акыллы кеше дип уйлап, сиңа ияреп барып ялгышканмын икән. Соно пәһлеван, дошман булса да, күзләремне ачты. Элек сукыр булганмын, хәзер менә сине үтәли күрәм. Якын-тирәдә һәм еракеракта яшәүче күпме халыкка, гомер бакый ут-күрше булып дөнья көткән бурутларга әледән-әле һөҗүмнәр оештырып, аларның дәүләтләрен тармар итеп, байлыкларын, җирләрен тартып алдың. Үз мәнфәгатеңне кайгыртып, башка халыкны гына түгел, үз халкыңны да, аның батыр улларын да юк иттең. Синең кебек хан булмаган булса, яхшырак булыр иде. Ә хәзер кыргызларны кытайларга... – Нахсын ханның мәкерле серен әйтеп бетерә алмады. Нинди үкенеч! Корыч кылыч, һаваны ярып, көтмәгәндә аның башын кисеп төшерде. Җиргә төшкән баш алма шикелле тәгәрәп китте. Нахсынның пәһлевандай көченә кызыккан һәм аңа ачу саклап йөргән әзмәвер Замун, ялагайланырга җай чыкканга шатланып, алдан сөйләшеп куелганча, арттан килеп, Нахсынның башын чабып төшерде. Бәһасез баш үлемгә буйсынырга мәҗбүр булды.

Нахсынның җир катыш канга баткан башы бераз тәгәрәп барды да туктап калды һәм ачулы карашын ханга төбәп, авызын бер ачып, бер ябып нидер әйтмәкче булды. Кызганыч ки, бугазыннан кисеп төшерелгән баш, канга тыгылып, гырылдау авазлары гына чыгарды. Бәлки, ул, ахмак хан мәнфәгатьләрен кайгыртып, гомеренең бушка узуын аңлагандыр. Бәлки, ул үзе белгәннәрне башкаларга җиткерә алмавына кайгыргандыр. Баһадирның әйтелмичә калган соңгы сүзен беркем дә, беркайчан да ишетмәячәк...

Башсыз калган олпат гәүдә, алга таба омтылып, кулларын ханга сузып, аның биленнән эләктерде дә, муенынннан алсу кан сиптереп, җиргә мәтәлде. Җиргә таянып тормакчы булды, ләкин тора алмады... Фани дөнья. Агарып каткан Сыбан Доржу мондый куркыныч күренештән өркеп читкә ташланган яраннары яныннан, бертуктаусыз атын камчылый-камчылый, бер читкә томырылды. Аның битен һәм кулларын Нахсынның кайнар каны яндыра иде. Хан Нахсынны үтерергә теләп ташланган вакытта, баһадирның хатыны белән малае ярдәмгә килеп җиткән иде. Бик каты елаучы бу икәүне яугирләр этә-төртә амбарга кертеп, тыштан сөңге белән терәп куйдылар. Җаннары никадәр янса да, алар берничек тә ярдәм итә алмадылар. Ишек ярыгыннан карап торган малай, кайнар яшьләрен сөртеп, тавышсыз гына еламсырый иде. Иренең башы гәүдәсеннән аерылганын күргән хатын, куркыныч тавышлар чыгарып, еламсырап торган малае янына кисәк авып төште һәм тынып калды.

Малайның батыр йөрәгендә атасы өчен үч алу тойгысы кабынды...

Легендага әверелгән Санташка искиткеч гүзәл Кыркырдан күтәрелгәч, күл тарафына ат белән юыртып барганда, иң әүвәл кечкенә бер алан уртасындагы тирмәне хәтерләтеп торган зур йомры таш күзгә ташланыр. Кайчан, каян барлыкка килгән ул һәм кем, ни өчен тәгәрәтеп китергән – билгесез. Әллә кайчаннан бирле тора инде ул. Санташ тарафыннан җәен дә, кышын да җелеккә үтәрдәй булып туктаусыз искән җилдән саклану өчен, юлчылар һәрвакыт шул таш тирәсенә сыена, шунда алар ял итеп, тәгамнан авыз итеп, янә көч туплап ала. Һәр елны җәй башында чәчәк ата башлаган лаләләр, үзәнлеккә генә сыеша алмыйча, бөтен җиргә таралып, дулкынланып торган кызыл диңгезне хәтерләтәләр. Үзләренең ямьсез-котсыз җирләреннән килгән кытайлар, мондагы искиткеч гүзәллекне күреп, кызыл диңгезне хәтерләткән үзәнлекне Кызыл Үзән дип йөртә башлады. Аларның бу җирне үзләренеке итәсе килә иде. Күп сулар акты, әлеге гүзәл җирләрне пыранзаран китерүчеләр инде күптән бу якты дөньяда юк. Аларны халык та хәтерләми инде. Үзәнлек кенә һаман шул көе.

Байтак вакытлар узгач, әзмәвер кеше, әлеге йомры таш янына килеп, тезләнеп утырган дөяне хәтерләтеп чүгәләде дә, ике учын ачып, кемгәдер багышлап Коръән укыды. Бу кеше даны еракларга таралган Соно пәһлеван иде. Нахсынның һәлак булуы турындагы хәбәрне ишетүгә, аның белән булган бердәнбер очрашуны һәм күзгә-күз карап сөйләшүне исенә төшереп, аны искә алу һәм Нахсын баһадирга багышлап Коръән уку нияте белән, калмык яугире төн чыккан урынга килде. Бер күрүдә үк бер-берсенә хөрмәт белән караган, бер-берсен сүзсез дә аңлаган бу икәүнең берсенең икенчесенә соңга калып булса да ихтирам күрсәтүе – бердәнбер хак юл иде. Кеше үлгәч, аны якты уйлар белән искә алалар, аңа багышлап Коръән укыйлар һәм Аллаһтан аңа җәннәттән урын бирүен сорыйлар. Үлгән кешегә дога гына кирәк – бары шул.

Яргаланып беткән учларын ачып, Коръәннән озын сүрә укыгач, Соно пәһлеван, уйлары аша булса да, Нахсын баһадирга рәхмәт хисләрен җиткерде. Аның каршы чыгуы аркасында, хан кыргызларга яуга чыгудан бер елга гына булса да тыелып торды, кыргыз халкы шул арада гына булса да тыныч тормышта яшәп калды.

Ук кадалган бүре кебек яралы халык хәзерге вакытта тагын бер һөҗүмне күтәрә алмас иде. Бер елдан соң – анысы бер хәл... Әлеге очракта бер ел бер гасырга тиң. Бер ел эчендә халыкның тән җәрәхәте төзәлер иде. Качаклар, туган җирләренә кайтып, бер-берсен табышыр һәм бераз булса

да хәл алып, бар булган ихтыяр көчен туплап, берләшергә өлгерер иде. Качаклардан аерылып калган бер иш халык исә таулар арасындагы үткелләрдә, көтүлекләрдә адашып йөргән, сыктап-сыкрап яшәгән бер мәлдә дошман янә һөҗүм итәргә уйласа, алар бернинди каршылык күрсәтә алмас иде. Ватаннарын ташлап китә алмаган кешеләр, гомерләрен куркыныч астына куеп, дошманга каршы күтәрелер анысы, әмма ул чакта алар күпләп һәлак булырлар яисә тагы да ераккарак качарлар һәм кеше аяк басмаган таулар арасында каңгырып йөрерләр һәм, мөгаен, үзләренең торлакларына кабат кайтып та тормаслар иде.

Күп җәфалар кичкән халыкта бүтән кыю уллар табылмаганлыктан, һичьюгы ул берьялгызы дошманга каршы чыгып, кабат яу белән килмәүләрен таләп итеп, аларны кире бора алды.

Әйе, Соно пәһлеванның кыюлыгын калмык баһадиры күрде, аның изге ниятен аңлады, шул сәбәпле кыргызларга һөҗүм итмәде. Шуның белән ул да Сононыкына тиңдәш кыюлык күрсәтте. Хөрмәткә лаек дошманны ихтирам итү – киң күңеллелек билгесе…

– И Аллам, аның урыны оҗмахтан әйләсәң иде!

Пәһлеван, авыз эченнән генә дога укып, берникадәр вакыт уйчан кыяфәт белән утырды. Берничә мәртәбә үз халкына – муллык, иминлек, Ватанына исә тынычлык сорады. Ала Тауда гомер итүче кыргызлар дошманнардан котыла алмады. Алар җиренә кызыгучылар күп шул… Соно пәһлеванның дошманнарны берьялгызы кире борып җибәрүе хакында хәбәр таралгач: «Юк-юк, алай булмады, мин түгел, киресенчә, аларның баһадиры дошманнарны безгә яу чаптырмады», – дип, халыкка аңлатырга тырышты ул. Менә хикмәт, болай да була икән, дип гаҗәпләнде кайберәүләр. Инде әлеге хәбәрләрнең хак булуы расланды. Нахсынның үлеме бу сорауга нокта куйды. Ул, үз халкы өчен һәлак булып, ниһаять, мәңгелек хөрмәткә лаек булды…

Олпат пәһлеван, күпмедер вакыттан соң, утырган җиреннән акрын гына күтәрелеп, торып басты. Эчке киеме эченнән үзе белән кадерләп саклап алып килгән тукыма кисәген алып, аны корыган агачка бәйләп куйды да авыз эченнән генә пышылдады:

– Бу агач Нахсын баһадир хөрмәтенә изге урын булсын!.. Ватанымда тынычлык урнашсын…

Сатнаш тарафыннан искән җил әле генә бәйләп куйган зәңгәр тукыманы әләм шикелле җилфердәтергә кереште…

Тирмәне хәтерләткән йомры таш үз гомерендә күпне күрде, күпне кичерде. Бу фани дөньяда күпме олы мәҗлес, күпме кайгы-хәсрәт, сыкранулар шаһиты булды ул. Йомры таш күпне кичергән дәрвишләр өчен дә, җирдә Киек Каз юлын хәтерләткән Ефәк юлы буйлап көнбатыштан-көнчыгышка һәм, киресенчә, көнчыгыштан-көнбатышка юл тоткан яңгыравык кыңгыраулы кәрванчылар өчен дә ышыклану урыны булды. Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән бала табарга вакыты җиткән яшь хатыннарны, җилдән һәм ятлар күзеннән саклап, үзенә сыендыручы да иде ул. Дошман угыннан яки кылычыннан яраланган батырлар да, дин әһелләре дә, мәкерле ханнар да, ярлы-ябагай да шушында сыену урыны тапты. Барысына да бердәй ярдәм итте йомры таш. Әгәр без аның гүләгән тавышын ишетә алсак, мөгаен, аның ни сөйләгәнен аңлаган яки һичьюгы гөманлаган булыр идек. Ул безгә бихисап михнәтле тарихны, без хәбәрдар булмаган күп кенә вакыйгаларны бәян итәр иде. Һәм, әлбәттә, кан һәм нәселе башка булса да, үйтеләкләре белән бер-берсенә үтә лаек ике баһадир хакындагы әлеге хикәят тә шуңа бер дәлил… ■

Урысчадан ***Ләбиб Лерон*** *тәрҗемәсе*

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)



БАБИЧ ШӘЕХЗАДӘ (1895-1919)

Татар шагыйре. Уфа губернасының Бөре өязендәге Әсән авылында мулла гаиләсендә туган.

Башкорт гаскәре кызылларга кушылгач, бертөркем хәрбиләрне (шулар арасында шагыйрь Бабич та була) «Вакыт» типографиясе машиналарын алып кайтырга Оренбургка җибәрәләр, кайтып килгәндә, кызыллар отряды аларны туктата. Кызыл командир башкортларның кызылларга кушылганлыгы турында бихәбәр булганмы, әллә махсусмы, типография машиналарын алып кайтучыларның барысын да атып үтерәләр.

БАИМБӘТОВ ГЫЙЛЕМДАР (1886-1933)

Татар язучысы, драматург, сәясәтче.

Милләтчел контрреволюцион оешма коручы, дип ялган гаеп тагып, аны кулга алалар һәм атып үтерәләр. Кабере билгесез.

БАЙКИН ҖӘЛӘЛ (1886-1954)

Татар артисты, режиссер. Әстерхан татар театрын оештыручы. Әстерхан, Казан, Азәрбайҗан, Кырым, Үзбәкстан театрлары спектакльләрендә баш рольләрне башкара.

1944 елда Байкин Җәләл Кырымнан Урта Азиягә сөрелә.

БАЙКИНА САРА (1895-1972)

ТАССРның – халык, Кырым АССРның һәм РСФСРның атказанган артисткасы. Җәләл Байкинның хатыны.

Әстерханда туган.

1944 елда Сара Байкина Кырымнан Үзбәкстанның Әндиҗан шәһәренә сөргенгә җибәрелә.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

БАЙЧУРИН РАФИК (1915-1980)

Көнчыгыш Төркестан Республикасы гаскәренең хәрби хезмәткәре. Полковник. Колҗа (Кытай) шәһәрендә яшәүче татар гаиләсендә туган. Шундагы татар урта мәктәбен тәмамлый.

Нылкы шәһәре янында кытай хакимиятенә каршы көрәшүче партизан төркеменең командиры була.

Сәяси мохит үзгәргәч, аңа Казахстанга качып китәргә туры килә. Ватанынннан еракта җирләнгән.

БАТТАЛ АБДУЛЛА (1916-1944)

Журналист. Казан губернасының Спас өязендәге Зур Тигәнәле авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туган. Язучы Салих Батталның энесе.

Абдулла Баттал фашистлар камалышында калып, әсирлеккә эләгә. Анда Муса Җәлил һәм Гайнан Кормаш оештырган яшерен оешма эшендә катнаша. Яшерен оешманың эзенә төшкәч, фашистлар унбер татарны, шул исәптән Абдулла Батталны да үлем җәзасына тарталар. Кабере билгесез.

БӘКЕР КӘБИР (1885-1944)

Татар театры тәнкыйтьчесе, драматург, газета журналисты.

Оренбург өлкәсенең Зубачы авылында мулла гаиләсендә туган. 1912 елда Төркия ягыннан Балкан сугышында катнаша. Санкт-Петербургта тупланган шәфкать туташлары командиры була. Балкан сугышыннан соң, Урта Азиягә күчеп китә.

НЭП вакытында алтын-көмеш белән сату итә башлый һәм шул рәвешле байый.

Спекуляция белән шөгыльләнүдә гаепләп, аны кулга алалар һәм бөтен малын конфискацияләп, Себергә озаталар. Өч елдан соң ул иреккә чыга. Ләкин пантюркистлыкта гаепләнеп, Соловкига җибәрәләр. Кабат иреккә чыкканнан соң, ул газета эшенә кайта. Аның эшендә сәяси хата табып, янә зинданга ябалар. 1944 елда ул үз үлеме белән дөньядан китә. Самарадагы татар зиратында җирләнгән.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

Туфан Миңнуллин юксындыра

(Хатирә)

Илзирә Вәлиуллина

«Мондый гына мулла кызында да була»

Нәҗибә апа белән бакчада. 2016 ел

Моннан нәкъ 15 ел элек кишергә су сипмәү серенә дә Туфан абыйлар бакчасында төшенгән идем мин, авыл кызы булып та, шуны белмәгәнмен. Язмамда, алга китеп булса да, шул хакта ассызыклап китим әле...

Татарстанның халык артисткасы Нәҗибә апа Ихсанова белән мине бу бакчага Туфан ага Миңнуллинның бертуган энесе Альберт абый алып килгән иде. Туфан абыйның капкадан безне каршы алуы бүгенгедәй хәтеремдә. Нәҗибә апаның өйдән бавыр пешереп килүе, ашагач, чәйләп алгач, аларның мине кайда нәрсә үсүләре белән таныштырып йөрүләре... Ул бәрәңге, кишер, суган, әнис, петрушка, сарымсак, карлыган, чия дисеңме... Ничек гел бирегә килергә вакыт табып, бу хәтле әйберне карап үстерәләр икән бу ике бөек шәхес дип гаҗәпләнгән идем ул чакта. Туфан ага гел хезмәттә, иҗатта, күпме пьесалар иҗат итә, әле быел да 10 томлыгы дөнья күрде, Нәҗибә апа данлыклы театрны җигелеп тарта дигәндәй... Вакытында су сипмәсәң, чүбен утамасаң, бернәрсә дә үсмәве, уңыш булмавы көн кебек ачык, дип, ике күренекле шәхеснең бакчасы уртасында соклану хисләре кичереп басып торганымны анык хәтерлим. Беренче көнне без биредә әллә ни эшләмәсәк тә, икенче көнне Нәҗибә апа үзе өй җыештыру, идән юу белән мәшгуль булып, миңа карлыган җыярга кушкан иде. Ә Туфан ага, кулына чалгы алып: «Менә үлән гел үсеп тора бит, сыер асраучыларны әйтәм әле, берсе дә чапкан үләнне алып чыкмый, дия-дия, үскән үләннәрне чапты. Аннан Туфан абый миннән: «Илзирә, утын кисә беләсеңме?» – дип сорады. Мин, беләм, дигәч, зур пычкы, ягъни пила алып чыкты әдип. Менә мунчага эскәмия ясый идем, бу юан бүрәнәне кисеп алыйк әле, әйдә, дип, ул мине үз янына чакырды. Без, пычкы тоткасын икебез ике яктан тотып, кисәргә керештек. Суын алыштырырга чыккан Нәҗибә апа, миңа көлемсерәп карап алгач: «Ерактан гел минем апамның кызы Миләүшәгә охшагансың», – диде. Туфан абый билгеләгән, дөресрәге, карандаш белән сызган эздән туры иттереп кисәргә тырышсак та, берсе бераз кыеграк киткән иде. Туфан абый исә: «Ярар, андый гына мулла кызында да була», – дип

елмайды. Шул рәвешле ике бүрәнә кисәгеннән дүртәү хасил булды. Аннары мин карлыган җыюымны дәвам иттем. Ул арада эшен тәмамлап чыккан Нәҗибә апа кишерләргә су сибеп алу ниятен белдерде. «Кирәкми, сипмә, су сипсәң, кишер үсми ул, аңа утырткач кына тернәкләнеп китәр өчен сибәләр суны, хәзер кирәкми, – диде Туфан ага. – Су сипмәсәң, кишернең тамыры дым эзләп аска китә, су сипсәң, өстә генә тора». Әйткәнемчә, бу минем өчен яңалык иде. Туфан абый шуннан соң такта кисәкләре кисте, кадаклады, нидер ясады, мин, алдарак язганымча, карлыган җыю белән мәшгуль булдым, Нәҗибә апа исә чүп утады, чәй эчәргә җиләкләр җыйды. Әлбәттә, без сөйләшә-сөйләшә эшләдек.

Яшелчәләр, дигәннән, әлеге күренекле иҗат әһелләренең Толстой урамындагы фатирларында «Садовая» исемле сок чыгарткычлары бар иде. Туфан ага безне, иртүк торып, кызыл чөгендер, кишер, алма, кабак, сарымсак кушып чыгарылган сок белән сыйлый иде. Кайвакытта лимон да өсти иде әле. Үзем дә, бу эчемлекне бик ошатканга, алардан күреп, шундый сок чыгарткыч алып куйдым. Туфан ага белән Нәҗибә апа янәшәсендә узган әлеге мизгелләр минем өчен иң бәхетле мизгелләр иде, чөнки кайчандыр шундый дәрәҗәле вә хөрмәтле шәхесләр бакчасында йөрү, аларның өендә кунак булу түгел, аларның янәшәсендә басып торуны да күз алдыма китерә алганым юк иде бит...

Балыкта

Моннан нәкъ 13 ел элек булган бер истәлек-хатирәне дә укучылар хозурына ирештерүне мәслихәт санийм. Җиһанда мул уңышлы көз хакимлек иткән сентябрь ае иде ул. Чаллыдан Казанга кайтышлый, Туфан абыйлар бездә тукталды. Әдипнең балык яратканын Нәҗибә апа Ихсановадан ишетеп белгәнгә, итле бәлеш янына күп итеп кетердәп торган Зәй елгасы балыкларын да кыздырган идек. Шуларны тәмләп, мактый-мактый ашады хөрмәтле кунагыбыз. Алдагы килүләрендә дә Туфан аганың, Зәй елгасын күрәсем, шунда балыкка барасым килә, дигәне бар иде. Көне дә кояшлы-матур, нәкъ «Әбиләр чуагы»ндагы кебек булганлыктан, сәгать бишенчеләрдә җыендык та өчәүләп җәяү генә балыкка киттек. Болынга җитүгә, Туфан ага, Зәй елгасына орынып диярлек торган мәгърур тауларга карап, соклануын белдерде. Бер менәрбез әле бу тауга да, диде ул, шул таулардай горур кыяфәте белән. Абый малаеның алдагы көннәрдә басмадан шактый гына балыклар тотып кайтканын әйтеп, кунакларыма да асылмалы агач басмага кереп басып кармак салырга тәкъдим иткән идем. Туфан ага, ярар, шунда керербез, дип ризалашкан иде дә, тик такталары кубып, җимерелә үк башлаганлыгын, бигрәк тә уртасына

Балыкта. Тоба, Зәй буе. 2007 елның сентябре

җитәрәк бер генә агач такта эләгеп торуын күргәч: «Илзирә, без монда кермик әле», – диде. Зәй кырыйлатып балык тотар өчен кулай берничә урынны карагач, җайлаштырылган бер җиргә тукталасы иттек.

– Әйбәт урын бу, – диде Туфан ага, кармак җебен сүтә-сүтә. Бераздан: – Монда чиртә дә, суы да бер урында бөтерелеп тора, – дип тә өстәде, чираттагы кукуруз орлыгы эләктерелгән кармакны суга атканда.

Менә тиздән,бөек әдипнең сүзен дәлилләп, бер бәртәс балыгы да эләкте. Туфан абый: «Бар монда балык, бар!» – дип сөйләнә-сөйләнә, балыкны кармактан ычкындырды да кире суга атты. Бәләкәй булганга, күрәсең: «Бар, үсә тор», – диде ул балыкка. Мин исә янәшәдә генә балык тотучы өченче юлдашыбыз – Ришат абый янына барып күз салып алам, әле аңа бер балык та эләкмәгән. Суалчанга да тотып карадылар, чиртүен чиртә, тик тотып булмый. Туфан абый әйтмешли, без рәтен белеп бетермибез, ахры, балык тотуның да үз нечкәлекләре бардыр, ягъни кармак чыбыгын кайчан, ничек тартып алырга… Балык капканын хәйран озак көтеп утыргач, Туфан ага, шаяртып:

– Теге маймыч, төшеп, бөтен балыкларга да, анда күзлекле бандит утыра, капкынга эләгә күрмәгез, дип әләкләде, ахры, – ди.

Без кайтканда, күкне караңгылык каплаган иде инде. Мин, кызганыч, Туфан ага, бер балык та эләкмәде, дигәч: «Балык кабудамыни хикмәт! Аны тоту процессы үзе бер ял», – диде әдип. Зәйдән кайтканда, сүзебез әдәбият өлкәсе тирәсендә кайнашты. Рәис Биляев турындагы романыгызны язып бетермәдегезме әле, Туфан ага, дип кызыксындым мин аннан. Бу турыда әдипнең «Утырып уйлар уйладым» исемле китабыннан укып белә идем.

– Юк әле, мин бит роман язучы түгел, мин пьесаларны җиңел һәм тиз язам, ә бу бөтенләй икенче нәрсә, – дип җавап бирде ул. Әдип миңа, мисал итеп, Әмирхан Еники, Галимҗан Ибраһимовларны китерде. – Менә, мәсәлән, ишек төбенә килдем дә, бикле йозакны ачып, өйгә кердем, дип язарга да була. Ә шуны Галимҗан Ибраһимов ничек итеп сурәтләр иде, ягъни хикәя, повесть һәм романнарда һәрнәрсәне нечкәлеге белән сурәтли белү аларда шулкадәр көчле. Мин Рәис Биляев турында әкрен генә, күңелем тулышканда гына язам…

Әдип белән әңгәмәбез өйдә шигъри кичә буларак дәвам итте. Аккош турындагы поэмамны хупламаса да, яңа шигырьләремне тыңлаган Туфан ага, бу язганнарың тегеләренә (алдагы китаптагыга) караганда көчлерәк, диде. Ә инде Туфан Миңнуллинның робагыйларын үзе укуында тыңлап утыру нинди илһамландыргыч мизгелләр икәнен чамалыйсыздыр!.. Дикъкать белән тыңлап утыручы әниебез дә: «Менә шулай язарга кирәк аны!» – дип, миңа ымлады. Бу килүендә дә Туфан абыйның автографлы робагыйлар китабына ия булу бәхете тәтеде.

«Галәмең – кылган гамәлең»

Әдәбият классигы Туфан ага Миңнуллинның үзе исән чагында Түбән Камага килеп караган соңгы премьерасы – 2011 елның 27 мартында куелган «Нәзер» белән бәйле истәлек-хатирәләремне дә, тарих буларак, ак кәгазь битенә төшерүне лязем таптым. Гадәт буенча, олпат язучыбыз, кесә телефоныма шылтыратып: «Илзирә, без сезнең авылны узып барабыз, син кайда?» – дип сорады. Мин инде алдагы көнне танылган актриса Нәҗибә апа белән телефоннан сөйләшкәнлектән, Туфан аганың премьерага безгә киләсен белә идем. Спектакль тәмам булгач, Туфан ага

Туфан ага Илзирә Вәлиуллинага автографлы «Тормышым-булмышым» китабын бүләк итә. Тоба, 2011 елның март ае

үзенә бирелгән чәчәк бәйләмен: «Мә, монысы сиңа, Илзирәгә», – дип, миңа сузды. Премьерадан соң әле алар театр режиссеры Рөстәм Галиев белән шактый гына фикер алыштылар.

Шуннан соң бергәләп авылыбызга, безгә кайтып киттек. Юлда кайтканда, Туфан ага, «Семь дней» тапшыруына җитешсәк иде, анда фикерләремне ишеттерергә тиешләр, карарга иде шуны, дигән теләген белдерде. Үзенең дистә елдан артык йөрткән ышанычлы шоферы Ришат машинаны куа башлагач: «Артык кызулама, Ришат, юл бозлавык, җитешербез», – диде. Аннары миңа: «Әниеңә – әйт әле, Илзирә, башланса, «Семь дней»ны карый торсын», – дип өстәде. Әйтүен-әйтәм хәзер, Туфан абый, тик,тапшыру рус телендә булганлыктан, әни бар җөмләләрнең дә мәгънәсенә төшенеп бетмәс шул, дидем мин. Әлбәттә инде, әнигә Туфан абыйның гозерен җиткердем, юлда икәнлегебезне дә әйттем. Ул арада Туфан ага, телефоннан кызы Әлфиягә дә шылтыратып: «Юлда булганлыктан карый алмыйм, син кара әле, кызым, «Семь дней»ны», – диде. Юлда кайтканда, Туфан абыйга һәр премьераны карагач бирә торган «Үзегезгә ошадымы соң?» дигән соравымны бирдем. Ул чакта менә нәрсәләр сөйләде драматург: «Хисмәт бүгенге заманның төрмәсеннән чыккан зекны уйный. Ул бит зек түгел, аларны бит төрмәдә яткырмыйлар, алар алтын приискасында эшлиләр, кәмиткә корылганрак килеп чыккан. Рухы сынып кайткан кеше башкачарак уйнарга тиеш, ә монда ыржаеп утыру бар. Икенче пәрдәдә әйбәт китә, Хисмәт әйбәт уйный. Оренбурглар куелышында карап туймый торган спектакль килеп чыкан. Боларда уйнау бар, монда уйнарга кирәкми, яшәргә генә кирәк...»

– Булган хәлләргә таянып язылган әсәрме соң? – дип тә сорыйсы иттем Туфан абыйдан.

– Булган хәл, егерме ел элек Чүпрәле районы кешесе сөйләгән иде. Спектакльне караучылар, бездә дә булды мондый хәл, дип мисаллар китерәләр. Бу бит тормыш мәҗбүр иткәнгә, нәзер әйткәнгә килеп чыккан хәлләр. Мин аны башта хикәя итеп

язган идем, ул «Утырып уйлар уйладым» исемле китабымда да чыккан иде. Оренбург театры режиссеры Рөстәм: «Туфан абый, безнең репертуарга бик күп кеше катнашмый торган сәхнә әсәре кирәк», – дигәч, мин аңа шушы хикәяне пьеса итеп язып бирдем. Аны Рөстәмнең кызы куя башлады да юл һәлакәтенә очрап вафат булды. Әтисе кызының үлемен шулкадәр авыр кичерде, бүлнистә ята әле. Оренбург театрында биш артист уйнады. Бер карт сөйләп тора, калганнар уйныйлар. Спектакль беткәндә Маһирәнең: «Ә миңа җиңелме?» – дип әйтүе дә үзәкләрне өзгеч... Спектакль турында юл буе фикер алышып, өебезгә кайтып җиткәнне сизмәдек тә.

«Семь дней» башланган иде, шунлыктан Туфан абый, өйгә килеп керү белән, телевизор каршысына утырды. Үзенең фикерләрен ишеткәч: «Кыскартып бетергәннәр, моның өчен генә сүз әйттереп...» – диде. Шуннан соң инде ныклап күрешү, хәл-әхвәлләр белешү китте. Туфан ага, әнине иңнәреңнән кочып алып:

– Әле Илзирә, телефоннан Нәҗибә апасы белән сөйләшкәндә, әни авырыбрак тора, картаебрак та китте, дигән иде, болай булгач, болай йөргәч, әйбәт әле, әйбәт, мин инде бик борчылган идем, – дип сүз башлады.

Бу күрешүнең истәлеге булып Туфан абыйның имзасы салынган «Тормышымбулмышым» афоризмнар китабы һәм фотосурәтләр калды. Туфан ага аны миңа бүләк иткәндә берничә битне ачып укып күрсәткәннән соң: «Әйдә, монысын махсус ачам, сиңа нинди сүзләр язылган бит туры килер икән», – диде. Бөек шәхес ачкан биттә әдипнең: «Галәмең – кылган гамәлең», «Хакыйкать – утлы күмер, учыңа алма – пешәрсең» дигән канатлы сүзләре язылган иде.

Ул вакытларда мин Түбән Каманың «Кама таңнары» әдәби берләшмәсен юридик оешма итү артыннан йөри идем, берничә барып та, кәгазь эшләре тәмам булмаганлыктан, миңа янә Казанга Юстиция министрлыгына барырга кирәк иде, анда барырга сөйләшенгән көнем дә Туфан агалар китәсе көнгә туры килү сәбәпле, мин дә, аларга утырып, башкалага юл алдым. Капка төбенә озатырга чыккан әнинең дә Туфан аганы соңгы тапкыр күрүе иде бу... Һич онытмыйм, киткәндә Туфан ага миңа: «Бүген син депутат бул әле», – дип, машинада алгы урынны тәкъдим итте. «Ю-у-ук, Туфан абый, артка гына утырам», – дип уңайсызландым мин. «Юлда, бәлки, ятып та алырмын, шуңа артка утырыйм әле», – дигәч кенә, артык сүз дәшмичә: «Аңладым, Туфан абый, рәхмәт», – дип, утырырга тиешле урыныма «кунакладым». Әйе, әдип юлда бераз ятып та алды, сөйләшеп тә бардык. Ул үзенең бу тормышта бик күп юллар үткәнен, кайларда гына булмавын, бары тик ул аяк басмаган Әгерҗе районы гына калганын җиткерде. «Яшь вакытларыгызда үзегез эшләгән чирәм җирләрен сагынасыздыр әле?» – дигән соравыма: «Әйе, менә быел җәйме, киләсе елгамы бер урап кайтасым килә әле шул җирләрне», – дип җавап кайтарды.

Туфан Миңнуллин Илзирәнең әнисе белән. 2007 елның сентябре

Ярты юлда кибеткә суга сугыласы итте әдип. Үзем генә кереп алып чы-

гыйм, диюемә ул: «Үзем керим әле, ату сатучылар, нишләп Туфан абый үзе кермәде икән, диеп, прогул куярлар», – дип елмайды.Тиз арада әйләнеп чыккан Туфан ага миңа әле ул вакытларда чыгып кына килә башлаган зу-у-ур «Аленка» шоколадын сузды... «Юлчыны сыйлавыгыз әҗер-саваптан китсен, Туфан абый», – дип тели-тели, аны кулыма алдым. Ул шоколадның тәмлелекләрен белсәгез икән! Нәкъ менә Туфан абый Миңнуллин биргәнгә шулай тәмле булгандыр да инде! Ә бит, нигездә, Туфан ага белән шулай якыннан аралаша алуымның сәбәпчесе яраткан артисткам Нәҗибә Ихсанова булды. Ул мине үз итмәсә, Туфан ага да шулай якын күреп, кешеләр белән таныштырганда: «Нәҗибәнең дусты», – дип әйтмәс иде. Бу уңайдан мин Нәҗибә апага рәхмәт хисләремне һәрчак җиткерә килдем. (Язмамда Туфан агага бәйле истәлекләрнең кайберләрен генә бәян иттем, театр галәмендә исеме алтын хәрефләр белән язылган халык артисткасы Нәҗибә Ихсанова хакындагыларын, насыйп булса, киләчәктә укырсыз әле.)

Шуннан... Көннәр үткән саен, безнең әни каты авырый башлады, аның белән озаклап хастаханәләрдә ятулар, авыруы сәбәпле борчылулар, үз хуҗалыгыбыз белән торгач, каралты-курадагы эшләрнең күплеге дисеңме... Борчылуларым мине, ничектер, иҗаттан, шигърияттән читләштерде. Вакытны мин өстәл артында нидер язып утыруга түгел, ә әнигә, аның сәламәтлеген кайгыртуга багышладым. Арабыздан китәсе елны 8 нче март көнне бәйрәм белән котлап шылтыратканда, соңгы тапкыр телефоннан сөйләшүебездә Туфан ага миннән: «Язасыңмы?» – дип сорады. Республика газета-журналларында бастырылган язмаларымны, шигырьләремне күзәтеп барып фикерләрен әйткәләгән әдипнең тел төбен сизеп, хәл-әхвәлләремне сөйләп-аңлаткач, әниемнең каты авырганын әйтеп, тәмам җебек булып мышкылдап та җибәргәч, Туфан ага миңа: «Тормыш без дигәнчә генә бармый, кайбер нәрсәләрне салкын акыл белән кабул итә белергә өйрәнергә кирәк. Без беребез дә бу дөньяда мәңгелек түгел бит», – дип әйткән иде. Иҗатның биек кыясына исемен алтын хәрефләр белән яза алган әдипнең нәкъ менә шул сөйләшүдә: «Язуыңны ташлама!» – дигән соңгы сүзе мәңгегә хәтеремә уелса да, ул чакта каләмем кулдан төшүен яшермим. Хәтта бер айдан соң Туфан абыебыз кинәт кенә мәңгелеккә арабыздан киткәч тә, аны юксыну хисләрен бик озак еллар ак кәгазь битенә төшерә алмадым. Гәрчә бу бик зур югалту булса да. Туфан аганың вафатын ишеткән әнинең дә, авыр сулап: «Туфан хәтле Туфан үлгәч, безгә ни кала!» – дип уфтанганы бүгенгедәй күз алдымда...

Әйе, нинди әҗер-саваплы, бөек, кабатланмас Туфан ага! Әҗер-саваплы дигәннән, язмамны бөек әдибебезне җир куенына иңдергәндә, хәзрәтнең: «Җир йөзендә яшәүче халыкның күбесе 60ка хәтле генә яши, 60тан соң һәр ай, һәр ел Аллаһының бүләге. Нәрсәгә, нинди кешегә бүләк бирә, үзегез беләсез. Менә бу 17 елны Туфанга Аллаһы Тәгалә бүләк итеп бирде.

Кайберәүләр кешене, намаз укыймы, дип әйтәләр. Аллаһының соңгы пәйгамбәре (с.г.в.): «Аллаһы Тәгалә гыйбадәтне 7 өлешкә бүлә, 5 өлеше эш белән», – ди. Әгәр дә без намаз укырга, ураза тотарга өлгермәдек икән, эшләребезне Аллаһы риза булырдай, туганнарыбыз риза булырдай итеп башкарырга насыйп итсә иде, бу да әҗер бирә. Хәзер Нәҗибә ашата алмый Туфан җанын, Туфан эшләгән әҗерләре аны ашата, ягъни Кыяматкә кадәр җанын тәрбия кыла. Шуның өчен исән вакытта әҗерне күп эшләргә кирәк», –дип әйткән сүзләре белән тәмамлыйсым килә.

Әйе, хәзрәт тикмәгә генә болай сөйләмәгәндер. Туфан аганың гаиләсенә, туган авылына, кешеләргә, милләткә, халкына эшләгән игелекле эшләрен күз уңында тоткандыр ул... ■

Истә, һаман да истә!

Скульптор Илдар Хановның тууына 80 ел



Рәссам, монументаль сәнгать остасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968) Илдар Мәснәви улы Ханов 1940 елның 3 ноябрендә Казан янындагы Иске Аракчино бистәсендә туган.

Ул 1960 елда – Казан сәнгать училищесын, 1968 елда исә Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтын тәмамлый.

1975 елда Чаллыда аның Бөек Җиңүнең 30 еллыгына багышланган беренче скульптурасы («Ватан-ана») ачыла.

И.Ханов 2013 елның 9 февралендә вафат булды.

Галим Энгель Нигъмәтуллинның тууына 90 ел

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты, СССР Язучылар берлеге әгъзасы Энгель Галимҗан улы Нигъмәтуллин 1930 елның 6 ноябрендә Казанда туган.

1948 елда Казандагы 19 нчы мәктәпне тәмамлагач, В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый, аннары Алтай крае, Новосибирск, Казан мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1968 елда ул, читтән торып укып, М.Торез исемендәге Мәскәү чит телләр институтын да тәмамлый.

1972 елда филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклап, Казан университетының Рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасына ассистент итеп билгеләнә. 1977 елда шул ук кафедрада доцент вазыйфасын башкаручы итеп раслана.

Э.Нигъмәтуллин 2001 елның 16 июлендә вафат булды.

Язучы Эдуард Касыймовның тууына 90 ел

Язучы, фольклорчы галим, филология фәннәре кандидаты, СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1964) Эдуард Салихҗан улы Касыймов 1930 елның 7 ноябрендә Киров өлкәсенең Слободский районындагы Карино авылында укытучы гаиләсендә туган.

Ул, 1953 елда Казан дәүләт университетын тәмамлагач, Татарстанның Азнакай район үзәгендә, аннары Киров өлкәсендәге Түбән Шөн авылы мәктәбендә укытучы булып эшли.

Әдипнең кайбер китаплары: «Кызыл маяклар» (1959), «Кояш көн дә чыга» (1963), «Гомер ике килми» (1964), «Сорбонна профессоры һәм без» (1971), «Һаваларда тургай» (1973), «Чулман – оныклар дәрьясы» (1984), «Шиңмәсен гөлләрең» (1986) һ.б.

Э.Касыймов 1986 елның 21 мартында Чаллы шәһәрендә йөрәк авыруыннан кинәт вафат булды.

Композитор
Ифрат Хисамовның
тууына 90 ел

Композитор, курайчы Ифрат Нигъмәт улы Хисамов 1930 елның 14 ноябрендә Татарстанның Азнакай районындагы Сарлы авылында туган.

Хәрби хезмәттән соң, И.Хисамов Балтач районы мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшли башлый, шунда академик хор оештыра. Хор өчен «Таң атканда», «Ай, былбылым« кебек татар халык көйләрен эшкәртә.

И.Хисамовның кайбер әсәрләре: «Ак каеннар» (М.Хөсәен сүзләре), «Хөршидә-Мөршидә» (Г.Зәйнашева), «Агыйделкәй», «Утыр әле яннарыма» (Ш.Галиев), «Ромашка» (М.Харисов), «Үти-үти, үрдәкләрем (Н.Арслан), «Флейта һәм фортепиано өчен сонатина» (3 кисәкле), «Симфоник оркестр өчен сюита» (4 кисәкле), «Флейта һәм оркестр өчен концерт» һ.б.

И.Хисамов 2000 елда вафат булды.

Актер
Шамил Бариевның
тууына 70 ел



Актер һәм педагог, ТАССРның атказанган артисты (1986), М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты (1988) Шамил Мәсгуть улы Бариев 1950 елның 14 ноябрендә Саба районының Олы Арташ авылында туган.

1969 елда Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кино институтына укырга керә. 1972 елда исә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист булып эшли башлый. 1980-1991 нче елларда – Казан театр училищесында, ә 1991-1994 нче елларда Казан мәдәният институтында укыта. Ш.Бариев уйнаган кайбер рольләр: Крутицкий («Күктән яуган акча», А.Островский), Кияү («Кияү белән кәләш», М.Байҗиев), Офицер («Ике сәгать – бер гомер», Р.Хәмид), Ирназар («Ахырзаман», Ч.Айтматов) һ.б.

Ш.Бариев 1994 елның 11 мартында Казанда вафат булды.

Композитор
Фәтхерахман Әхмәдиевнең тууына 90 ел

Композитор Фәтхерахман Әхмәдиев 1930 елның 15 ноябрендә Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Тәберде Чаллысы авылында туган.

Ул, Салих Сәйдәшев киңәшен тотып, Казан музыка училищесына укырга керә һәм аны тәмамлагач, туган ягына кайтып, Котлы Бөкәш мәктәбендә музыка укытучысы булып эшли.

Ф.Әхмәдиев иҗат иткән җырларның кайберләре: «Җәйнең матур аяз таңнарында» (Ә.Ерикәй), «Кама буе – туган як» (Р.Әхмәтҗанов), «Чистай вальсы» (Ф.Әхмәдиев), «Мин килермен каршыңа» (Ш.Рәкыйпов), «Сине сөйдем, гүзәлем» (Ф.Әхмәдиев), «Мәңге яшисе килә» (Ф.Әхмәдиев), «Бер карадым күзләреңә» (З.Нури) һ.б.

Фәтхерахман Әхмәдиев 1981 елның 3 сентябрендә вафат булды. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Безнең мирас №11 ноябрь 2020

Җәмит Рәхимовның фотомирасы

*(Фотолар язучының хатыны **Галия Рәхимова**дан алынды.)*

Җәмит Рәхимов

Җәмит Рәхимов хатыны Галия һәм онығы Ренат белән

Каләмдәшләр: Җәмит Рәхимов һәм Альберт Хәсәнов (уңда)

Җәмит Рәхимов (уңнан беренче), Разим Вәлиуллин (баскан), Рамазан Байтимеров, Шамил Бикчурин, Альберт Хәсәнов (сулдан беренче)

Җәмит Рәхимов дуслары белән

Ике якташ, ике каләмдәш – Җәмит Рәхимов һәм Шамил Бикчурин (уңда)

Чыгыш ясаучы – Җәмит Рәхимов, президиумда – әдипнең каләмдәшләре һәм район җитәкчеләре

Борынгы татар милли музыка уен кораллары

Ринат Гыйләҗев, «Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

«Сорнай» фольклор ансамбле ТАССРның 100 еллыгына багышланган «Поле чудес» тапшыруы студиясендә

Ансамбльнең иҗади тәҗрибәсеннән

1982 елда Казан шәһәре Сәүдә хезмәткәрләре мәдәният йорты каршында «Сорнай» фольклор-этнографик ансамбле оешты. Дүрт-биш ай бик тырышып эшләгәннән соң, ансамбльнең үзе генә чыгыш ясый алырлык репертуары булдырылды. Ансамбль белән эшли башлаганчы ук инде миндә фольклор материаллары байтак тупланган иде. Тик менә бернәрсә борчыды: аерым җыр-бию, уен коралларын ничек бербөтен шоу-тамаша итеп күрсәтергә? Әлеге тамаша заманча да, халыкка үтемле дә булсын, тәрбияви белем дә бирсен. Һәр композицияне ничек булдыруыбыз турында кыскача мәгълүмат җиткерәсем килә.

Ахыры. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

«Болгар хатирәсе»

Әлеге күренешнең максаты «Сорнай» ансамбленең концерт программасын яисә һәр чыгышын башлап җибәрү өчен төзелгән. Пәрдә ачылып, тамаша башланып китүгә үк, тамашачы без тәкъдим иткән тарих мизгеленә кереп китәрлек булсын дидек. Концертыбызны тарих чоңгылыннан, борынгы Болгар чорыннан башларбыз дип планлаштырдык. Шуңа да иң беренче яңгыраган көйләр, музыка кораллары, киемнәр, ут бизәлеше, режиссура да шушы ансамбльгә, шушы чор өчен генә хас булырга тиеш дип фикер йөрттек. Чөнки шушы мизгелдән ансамбльнең үз йөзе формалаша башлый. Кемнедер кабатлау яхшы гамәл түгел.

1982 елда Әгерҗе районыннан сорнай уен коралын табып алып кайттым. Шуннан соң күңелдә аның көчле, үзенчәлекле тавышын ничек итеп беренче тапкыр халыкка ишеттерергә дигән сорау туды.

> «
> **Бер сорнай – көй, икенчесе тоник тавышны уйный. Инде хатның үрнәген кайдан табарга?**

Элек илдәге һәр яңалыкны, боерыкхәбәрне халык алдында кычкырып укый торган булганнар. Ә халыкны җыйнау, чакыру өчен көчле тавышлы барабан, чаң, быргы кебек уен коралларын файдаланганнар. Шушы күренешләрне күздә тотып, нигә әле шундый көчле тавышлы сорнайны кулланмаска дип фикер йөрттек. Тик менә нинди көй уйнарга? Борынгы үрнәкләр сакланмаган. Берничә чакыру (позывной) музыкасына туры китереп язып, уйнап карадык. Эзләнә торгач, Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсында кулланган вариантына тукталдык. Тагын да үтемлерәк булсын өчен, без аны ике-өч сорнайда башкарабыз. Бер сорнай – көй, икенчесе тоник тавышны уйный. Инде хатның үрнәген кайдан табарга? Ул елларда мин күренекле галим Марсель абый Әхмәтҗанов белән таныш идем. Гомумән, ул миңа татар фольклорының бик нечкә, бәхәсле, каршылыклы моментларын аңлатты, гомеремә җитәрлек киңәшләрен бирде. Мең рәхмәтләр булсын, Марсель абый! Аның чакыруы буенча, мин Фәннәр академиясенең кульязмалар архивында булдым. Андагы рухи мирасны күреп, исем китте. Заманында Казан ханына чит мәмләкәтләрдән килгән, мин эзләгән хат үрнәкләренең ниндиләре генә юк архивта. Әлеге хатларны элек «табугъ сәлам», ягъни «олылау сәләме» дип йөрткәннәр. Хатның үзебезгә кулай булган иң матур үрнәген сайладык һәм, ансамбльгә яраклаштырып, тарихи төсмерләрен үзгәртмәскә тырышып, өр-яңадан ясатып алдык. Ә инде һәр чыгыш алдыннан укылачак текстны, тамашачыларга багышлап, гел үзгәртеп яза идек. Чөнки чит мәмләкәтләргә барганда, һәрвакыт барлык Татарстан халкыннан котлау сәламе җиткерә идек.

Ниһаять, пәрдә ачылып китә. Сәхнәдә 5-6 кешелек ансамбль музыка уйнап утыра. Алар алдына өч егет чыга һәм өч сорнайда уйный.

«Хәбәр»

Хәбәр музыкасын ике тапкыр уйнагач, «Болгар кызлары җыры»на кереш музыка башлана. Егетләрнең икесе артка китеп утыра, кулларына музыка коралларын алып, кушылып уйный, берсе җыр барышында биленә кыстырган хатны укый. Әлеге хатны «Сорнай» ансамбленең иң беренче чыгышы өчен, Болгар чоры әдәбиятына туры килсен дип, галим-шагыйрь Рафис Әхмәтовтан махсус «Кыйссаи Йосыф» кысаларында яздыртып алдык.

«Табугъ сәлам»

Тыңлагыз, тыңлагыз!

Меңьеллык данлы тарихы булган бөек татар халкының һич тутыкмас вә күгәрмәс раушан көзгесе булган үлемсез җырларын, йолаларын, музыка коралларын табып, торгызып, җырлатып-биетеп көн күргән «Сорнай» ансамбленең котлау сәламе ошбудыр:

Сәлам улсын сиңа, олуг Болгар иле,
Мең ел аша кага җанга саба җиле.
Канатлары моң бит аның, җырлы-көйле,
«Әллүки»не, «Тәфтиләү»не көйли имди.

Йосыф китабын кемсә генә укымаган,
Кол Галигә рәхмәт илә баш ормаган.
Имәни вә Мәрҗанине хозурлаган,
Көе шанлы, киләчәге данлы имди.

Мәңге сулмас саф җаннарда – Илһам җыры,
Онытылмас Сәйдәш моңы, Тукай теле.
Сезнең алда бүген сорнай моңы,
Сәламләп вә алкышлап алың имди.

«Болгар кызлары җыры»

Мин Болгарга килеп учак яктым,
Балык тоттым Идел суыннан.
Яшь чирәмгә иелеп чалкан яттым,
Чал гасырлар узды уемнан.

Вокализ.

Әлеге җырны сайлау да бик ансат кына булмады. Болгар чорыннан сакланып калган җырларны каян алырга? Күп эзләнә торгач, характеры белән туры килә торган берничә халык җырына тукталдык. Нәтиҗәдә, шагыйрь Гамил Афзал шигыренә «Болгар кызлары җыры» туды.

Җырның вокализ өлеше башлангач, театраль тамаша буларак, бер егет белән кыз, үзләре дә белмичә, сәхнәгә (Болгар хәрабәләренә) йөгереп чыгалар. Сәхнәдә утырган артистларны шартлы рәвештә Болгар хәрабәләре дип күзаллыйк. Егет һәм кыз җыр барышында, һәр уйнаучы янына барып, уен коралларын карыйлар, гаҗәпләнәләр, сокланалар. (Вокализ беткәч, курайчы курайда көй уйнап җибәрә.)

Кыз. Чү, ишетәсеңме нинди сихри моң!.. Каян агыла ул? Шәһри Болгарданмы, әллә Биләрдәнме?

Егет. Суар каласыннанмы, әллә серле Сарайданмы?

Кыз. Их, тарих пәрдәсенең бер генә читен ачып карыйсы иде. Әтил, Чулман һәм Җаек буйларын, Кыз тауларын, Хан сарайларын, дала-кырларны тибрәндергән музыка коралларының моңлы тавышын ишетәсе иде бер. Ничек яшәдең син, олуг халкым, ничек көн күрдең, нинди иде синең хыялларың, уйлаган уйларың, җырлаган җырларың?

Болгар чорына караган кием үрнәкләрен булдыру да бик ансат кына булмады. Беренче тапкыр мех киемнәр киеп сәхнәгә чыккач, бу бит башкортныкы, бездә мондый мех киемнәр булмаган, диделәр. Бу хакта уйлап караучы да юк иде. Ә без куркып калмадык, тагын да тирәнрәк эзләндек. Башка коллектив җитәкчеләренә бу юнәлештә дә күпме яңа фикер бирде ансамбль, күпме сәхнә киеме төрләләнде. Сорнай уен ко-

«Сорнай» фольклор ансамбле ТАССРның 100 еллыгына багышланган «Поле чудес» тапшыруы студиясендә

ралын күргәч тә, бу урысларның жалейкасы ич, диделәр. Монысы да музыка тарихын белмәү галәмәте. Шушы күренеш вакытында гына да тамашачы сәхнәдә әлегә кадәр барлыгын да белмәгән күп кенә уен коралларын күрде. Халкыбызның шушы рухи байлыгын бергә туплап бер музыкаль әсәр итеп күрсәтергә кирәк дип таптык.

«Сәламләү»

Әлеге инструменталь, җырлы-биюле әсәрдә тамашачы беренче тапкыр сорнай уен коралының үзенчәлекле тембрлы тавышын һәм кыска бию көйләрен шулай матур итеп, өздереп уйнап була икәнлеген аңлады. Ул беренче тапкыр думбыра, көтүче быргысы кебек уен кораллары белән танышты.

Минемчә, «Болгар хатирәсе» – бик уңышлы, акыллы төзелгән күренеш. Шушы кыска гына вакыт эчендә күпме мәгълүмат бирелә тамашачыга. Шуңа да ул «Сорнай» ансамбленең иң озын гомерле сәхнә әсәре булды. Менә 40 ел инде ансамбльнең һәр чыгышы шушы әсәр белән башлана. Иң гаҗәпләндергәне – без үзебез дә аннан туймыйбыз, яратып башкарабыз. Хәзер генә ул барысы да бик гади, шулай булырга тиеш кебек.

Безгә «Сорнай» ансамбле репертуарында фольклор аз, дип әйтүчеләр бар. Бик мөмкин. Шуңа да әлеге анализны бик тәфсилләп язарга тырыштым. Чөнки алда язганнардан күренгәнчә, нәрсәдән башларга икән дип торган вакытта, юктан бар ясап, өр-яңа юнәлеш алып, фольклор ансамбле оештырырга материал туплау өчен күпме тырышлык, хезмәт кирәк. Биредә һәр хәрәкәт, күренеш чын фольклор әсәре дип аталырга хаклы. Инде исемнәре дә онытылган күпме уен кораллары, күпме җырлы-биюле уеннар яңадан сәхнәгә, тормышка кайтты. Инде 40 ел вакыт үткәч, әлеге уен кораллары да, җырлар, йолалар да беркемне дә гаҗәпләндерми. Шулай итеп кайчандыр фольклор материаллары булып саналган әлеге ядкярләр фольклор булудан туктый. Акрынлап алар сәнгать әсәрләренә үсеп җитәләр, халкыбызның рухи мирасы булып санала башлыйлар. Бу – табигый күренеш.

Борынгы татар милли музыка уен кораллары турындагы мәгълүматны безгә әле киңәйтәсе дә киңәйтәсе. Киләчәктә яңа эзләнүләр, яңа табышлар насыйп булсын дигән теләктә калам. ■

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

Филармония солистлары

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Резеда Галимова

- Татарстанның Чистай шәһәрендә туган;
- 1986 елда Түбән Камада С.Сайдашев исемендәге музыка училищесын тәмамлый;
- Тавышы – лирик сопрано;
- Түбән Кама шәһәренең 3 нче Балалар музыка мәктәбендә 11 ел фортепиано классында укыта;
- «Вокал сәнгате – академик җырлау» белгечлеге буенча Мәскәүдә Гнесиннар исемендәге Россия Музыка академиясен тәмамлый;
- 1997 елда Татар дәүләт филармониясенә Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестры солисты булып эшкә килә;
- 1996 елда С.Сайдашев исемендәге вокалистлар бәйгесендә лауреат була;
- 2000 елда Мәскәүдә узган Халыкара Делфия уеннары бәйгесендә «Академик башкару осталыгы» номинациясендә җиңү яулый;
- 2001 елда «Татарстанның атказанган артисты» исеменә лаек була;
- 2003 елда Италиядә «Гранд Прайс» Халыкара вокалистлар конкурсында җиңү яулый;
- Җырчының репертуарында татар, рус һәм чит ил композиторларының 300дән артык әсәре бар;
- 2005 елда «Казанның 1000 еллыгы» медале белән бүләкләнә;
- 2009 елда «Татарстанның халык артисты» исеменә лаек була; Россия Оборона министрлыгының махсус медале белән бүләкләнә;
- 2011 елда Татарстан Президентының Рәхмәт хаты һәм «Мәдәнияттәге казанышлар өчен» күкрәк билгесе белән бүләкләнә;
- 2013 елда Франциянең Страсбург шәһәрендә «Европа Сарае»нда солоконцерты белән чыгыш ясый һәм 2013 елда Казанда узачак XXVII Универсиаданы тәкъдим итә;
- 2012 елда җырчыга Татарстан Республикасы «Яңарыш» фондының Рәхмәт хаты тапшырыла;
- 2013 елда « XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы» истәлек медале белән бүләкләнә;
- 2016 елда Р.Галимовага Татарстан Президентының Рәхмәте белдерелә;
- 2018 елда ул «Россия Федерациясенең атказанган артисты» исеменә лаек була.

«Нефтьче» мәдәният сарае. Концерттан соң. Уфа, 2004 ел

Гастрольдә йөргән чак. Сулдан уңга: И.Кыямов, Ә.Авзалова, И.Шакиров, Р.Галимова, Р.Вәлиев

Г.Тукайга багышланган концерт. 2012 елның 19 апреле

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

Сәхифә «Тәртип» радиосында чыгып баручы «Саф вә рашан күзгә» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.

Шахта
(Татар халык җыры)

Китә җаныем, китә җаныем,
Китә җаныем Донбасска;
Ул китә инде Донбасска,
Сүз бирдек ташлашмаска.

Шахталарга син төшәрсең,
Җырлап күмер кисәрсең;
Әмма мине бик сагынсаң,
Бик саргайсаң, нишләрсең?

Әгәр мине бик сагынсаң,
Йөрәккәең тынмаса,
Сагынуларың чиктән ашса,
Чакыртырсың Донбасска.

Татарлар арасында шахтерлар бихисап булган. Донбасс, Кузбасс, Караганда һәм Урал шахталарында эшләүчеләрнең күпчелеген татарлар тәшкил иткән. «Шахта» җыры – моның ачык мисалы. Галим Илбарис Надировның «Татар халык җырлары» китабында аның 14 куплеты урнаштырылган. «Шахта» көенә шагыйрь Шәйхи Маннурның да махсус шигырь язуы мәгълүм.

«Шахта» – гармунчылар иң яратып башкара торган көй. Аны уйный белмәгән гармунчы элек гармунчыга саналмаган.

ТАТАРСТАНГА ТӘРТИП КАЙТА!

Казан 93.1 FM

Яр Чаллы 90.2 FM

Тәртип радиосы 93.1 FM

Көлке куа килә...

Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

Саран бабай

(Пародия)

Күзләр үтте.
Инде мине
Икенче кыз бәхетле итте.
Ул бәхетне тапмас идем,
Ярый әле ташлап киттең,
И чибәр кыз.

Роберт Миңнуллин

Кыярларым өлгерсен дә,
Берсен сиңа бирәм, дидең.
Мин ышанып көттем һаман,
Мин беркатлы,
Мин яшь идем.
Саран бабай...

Күзен әби
Бирде шалкан:
– Мә, тыгын, – дип, – елак шайтан...
Ә син кыяр биргән булсаң,
Ләкмәс иде, бәлки, шалкан,
Рәхмәт сиңа,
Саран бабай.

Гамил Афзал (1921-2003)

Казан шагыйрьләре

Син гади Гаффар,
Мин гади Саттармын,
Син мине якла,
Мин сине яклармын.
Син мине макта,
Мин сине мактармын:
Син даһи Гаффар,
Мин даһи Саттармын...

безнең мирас №11 ноябрь 2020

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Сезнең авылда

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Сезнең авылның аңгыралары арасында яшәп, акыллы булып булмый.

* * *

Сезнең авылның кайбер кешесе белән сөйләшкәннән соң, борча белән кандаланың икесен берьюлы кочаклап үбәрдәй буласың.

* * *

Сезнең авылга барган идем, урам тулы исерек, аек булуымнан оялып, кайтып киттем.

* * *

– Сезнең авыл кызлары шәһәргә килеп төшкәннең беренче көнендә нишлиләр?

– Чәчләрен кистереп ташлыйлар да исемнәрен йә Гуляга, йә Раяга, йә Фаяга алыштыралар.

* * *

Сезнең авыл күлендәге балыкларны йөзәргә безнең авыл бакалары өйрәткән.

* * *

Сезнең авылның ирләре, иреннәрдән үбә алмас хәлгә җиткәч, кул үбеп юаналар.

* * *

Сезнең авыл эте чакырган кунакны безнең авыл мәчесе озатып куйган.

* * *

Сезнең авылда хатыннар күбәйгән саен, безнең авылда кызлар кими бара.

* * *

Сезнең авыл кешеләре – яңгырдан куркып суга сикерүчеләр.

* * *

Сезнең авыл кешеләре бигрәк мескеннәр икән – дошманнарыбыз юк, дип мактаналар.

* * *

Сезнең авылның кешеләре баеган саен хәерчеләнәләр.

* * *

Сезнең авыл кызларының өсләрен япмый калдырганнар.

* * *

Сезнең авылның тавыгы суга керми дип, безнең авылның балыгы судан чыксынмыни?

* * *

Сезнең авыл ишәгеннән егылганны безнең авылда атка атландырмыйлар.

* * *

Сезнең авыл егетләренең йөрәгенә гашыйк була-була, сөял чыккан.

* * *

Безнең авыл кешеләренең намусы кендектән югары, сезнекеләрнең – кендектән түбән.

* * *

Безнең авыл чебене – балга, сезнең авылныкы тизәккә куна.

* * *

Безнең авыл кешеләре әдәп саклап утырганда, сезнең авыл әдәпсезләре бәхетебезне урлап киткәннәр.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1990)

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

ОКТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Сентябрь ахыры-октябрь башында Буа дәүләт сатира театры җитәкчесе Раил Садриев һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Алтай Республикасының башкаласы Горно-Алтайскида эшлекле сәфәрдә булып, П.В.Кучуяк исемендәге Алтай милли театрында (директоры – С.Н.Пешперова, баш режиссеры – Э.А.Иришева) һәм Алтай Язучылар берлегендә (рәисе – Б.Бедюров) театр әһелләре һәм язучылар белән очрашты.

● Октябрьдә күренекле галимә, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы Резеда Кадыйр кызы Ганиевага (1932-2020) багышланган «Профессор Резеда Ганиева» дигән китап дөнья күрде. Китапның төзүчесе – филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре Зөфәр Зәйни улы Рәмиев.

● 3 октябрьдә Тәтеш районының Кече Әтрәч авылында «Әтрәч укулары» булып узды. Чарада дин әһелләре, язучылар, төбәк тарихын өйрәнүче галимнәр һәм эшмәкәрләр катнашты.

● 4 октябрьгә каршы төндә татар телевидениесенең легендар дикторы Илфат Абдрахманов вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде туган ягында – Яшел Үзән зиратында җирләнде.

● 6 октябрьдә «ТАТМЕДИА» бинасының 3 нче катындагы киңәшмәләр залында балалар матбугаты хезмәткәрләре, балалар өчен иҗат итүче язучылар белән бергә, эшлекле сөйләшү уздырды. Чарада «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Ш.Садыйков, Татарстанның халык шагыйре Р.Фәйзуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Д.Салихов, балалар әдәбияты остаханәсе җитәкчесе Л.Лерон, язучылар һәм шагыйрьләр З.Хөснияр, Э.Шәрифуллина, Ф.Мөслимова, Л.Шәех, Ф.Яхин, А.Юнысова, Р.Корбан, Р.Сәлах, Р.Арсланова, Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты редакциясе мөдире А.Галиәхмәтова, «Ялкын», «Сабантуй»

һәм «Салават күпере» журналларының баш мөхәррирләре И.Фазуллин һәм З.Хөснетдинова катнашты һәм чыгыш ясады.

● 12-13 октябрьдә Буа дәүләт сатира театры (директоры һәм сәнгать җитәкчесе – Р.Садриев) К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры һәм Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе биналарында Казан тамашачыларына М.Әмир һәм З.Кадыйрова әсәрләре буенча куелган «Фатыйма» һәм «Бәхеткә юл кайдан?» спектакльләренең премьераларын тәкъдим итте.

● 13 октябрьдә «Звезда Поволжья» газетасының баш мөхәррире, татар милләтенең асыл улы Рәшит Әхмәтов 66 яшендә вафат булды.

● 15 октябрьдә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон һәм җаваплы мөхәррир Л.Гобәйдуллин, Лениногорск районында булып, хакимият башлыгы Рәгать Галиәгъзам улы Хөсәенов белән эшлекле сөйләшү уздырды. Шулай ук алар «Батырша» романы авторы Җ.Рәхимовның хатыны Галия ханым һәм улы Ленар белән очрашып, райондагы төбәкне өйрәнү музеенда булып, журналның алдагы саны өчен материаллар туплап кайтты.

● 16 октябрьдә бертөркем зыялыларыбыз Яңа бистә зиратында көндезге сәгать 1дә мәшһүребез Илһам Шакиров каберенә таш кую чарасында катнашты. «Апанай» мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров бөек җырчыбыз рухына багышлап Коръән укыды.

● 18 октябрьдә Казанның К.Тинчурин урамында, милләтпәрвәр зыялыларыбыз һәм фидакяр шәхесләребез катнашында, Хәтер көне чарасы үтте. ■

МИРАСВОРД

Фәхрелислам ... (балалар язучысы)

... Йомагулов (башкорт актеры, драматург)

Коеп ява торган яңгыр (диал.)

Әмирхан ...

Кайбер Шәрык илләрендә монарх титулы

... Зөлкарнәй

Язучы ... Гыймадиева

Сугышта зур батырлык күрсәткән кешегә бирелгән бүләк (бор.)

Камыштан ясалган үзбәк курае

Агачтан ясалган кечкенә кисмәк, мичкә

Ауга өйрәтелгән ерткыч кошның күзен каплый торган күн башлык

һәвәс, оста, маһир (иск.)

... Мирзаянов

... бүкәне

Гурий Тавлин трилогиясе

Драматург ... Вахит

Николай Гоголь повесте

«... хикәяләре» (Ибраһим Салахов)

Кубрат ханның улы

Кояш ... Тимбикова

«Тын ...» (Михаил Шолохов)

Телсез (диал.)

Суз (иск.)

Нурминкә елгасының уң кушылдыгы

Соры корт (диал.)

Умартада кәрәз җимерелмәсен өчен куелган аркылы агач

... барда кулың тый

... Бикчәнтәева

Шагыйрь ... Кари

«Ялт-...» (1910-1918 нче елларда Казанда чыккан журнал)

Борынгы грек шагыйре

Оҗмах чишмәсе суы

Башкортстандагы район

Америка җырчысы

Шагыйрь ... Давыдов

... Декарт

... Сакаева

Каты тау токымы төре

Мифик зат, гном

Мишәр абзые

... Юзиев

Филүс Каһиров туган авыл

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: караим, Максуд, Садә, маил, Икар, ом, Рәми, Ясәви, Лаисов, кын, сәнә, иләмән, Ра, чум, ригая, Нил, Саттарова, әзи, Мар, Огове, лира, Венер.
Өстән аска: Якимов, Айсылу, Әмир, әнәчә, «Зар», Камалов, Сирай, мишәр, кси, ният, аксакал, Уда, Салахов, Мөдәррис, рия, ген, әсәр, нойон, монар, Лев, шивә, талер.

***Рәис Габдулла** төзеде.*

«Безнең мирас»
елъязмасы / ноябрь

Татар журналистлары Ульяновск өлкәсенең Зөябаш авылындагы Акчуриннар утарында. 2016 ел

190 ел элек (1830)

Атаклы татар бае, фабрикант Әсфәндияр Акчурин (1830-1903) дөньяга килә.

115 ел элек (1905)

26 ноябрьдә Җаек (хәзерге Уральск) каласында татар телендә беренче демократик «Фикер» газетасы (1905-1907) нәшер ителә башлый.

100 ел элек (1920)

21 ноябрьдә Казанда «Татар мәдәнияте эшчеләре һәм фән ияләренең киңәш мәҗлесе» уздырыла. Мәҗлестә Татар җөмһүриятенең сәясәте, бередәге телне, гореф-гадәтләрне һәм Шәрык мәдәниятен өйрәнү мәсьәләләре кузгатыла. Азакта «Шәрык академиясе»н оештырып, анда эшләргә татар милләтенең зыялы катлавын җәлеп итәргә дигән карар чыгарыла.

80 ел элек (1940)

17 ноябрьдә күренекле тел галиме, профессор Хуҗа Бәдигый вафат була.

55 ел элек (1965)

11 ноябрьдә татар совет шагыйре Зыя Мансур (1916-1965) дөньядан китә.

22 ноябрьдә Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» пьесасы режиссер Хөсәен Уразиков куелышында тәүге мәртәбә сәхнәгә күтәрелә.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Ноябрь 2020

И останется в мире слово моё...: Джавдет Дарземан.

Историческое наследие: «Пройденные пути». Х.Хисматуллин; «Зай-Каратай: история дореволюционная». Ж.Рахимов; «Перебирая ценное наследие». Л.Гайнанова; «Галимзян Ибрагимов и его журнал «Аң». Р.Гайнанов; «Газета «Аваз». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин; «Древние эпитафии деревни Маматхужа». И.Хадиев, Р.Марданов; «Исторический родник и берега Зая». А.Бурганов.

Татарский мир: Рагать Хусаенов: «Лениногорск – для меня самый лучший на свете город!»; «Деревня, подарившая счастье».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Великий просветитель Хасан Хамидулла». Х.Миннегулов; «Литературный калейдоскоп». Т.Галиуллин; «Письма из прошлого».

Литература братских народов: «Легенда о каменном богатыре». А.Сарманбетов.

В глубинах памяти: «Тоска по Туфану Миннуллину». И.Валиуллина; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязев; «Татарская государственная филармония в истории 100-летней ТАССР». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Әтрәч тәңкәләре

- **Әтрәч укулары:** болгар-татар нумизматик мирасы
- **Археографик көндәлекләр.** Миркасыйм Госманов
- **XVI-XIX гасырларда Кама аръягы тарихы.** Нәкыйп Гафиятов
- **Шәмсуар йолдызлыгы...** Фәүзия Бәйрәмова
- **Бәрәңге хәзинәләре – Казан университетында.** Әлфрид Бостанов

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Әдип авылы — фотоларда

Җәүдәт Дәрзаман туганнары белән. Лениногорск районының Сугышлы авылы, 1977 ел

Фотолар язучының хатыны Тәслимә Дәрзамановадан алынды.

Терлекчеләр китап укый. 1962 елның феврале

5 яшьлек Җәүдәт сеңлесе Хәмидә һәм әнисе Сәгыйдә белән. 1950 ел

Җәүдәт Дәрзаман классташлары белән.
Лениногорск районының Шөгер мәктәбе, 1962 ел

Ротонданың совет чорындагы эчке күренеше

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ



Ротонданың хәзерге тышкы күренеше

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.